КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№8 (135)
20 февраль
1998 ел

...5 елның июленнән
башлап чыга

Атналык гәзит

بسم الله الرحمن الرحيم

Бүгенге санда:

2 **Минтимер ШӘЙМИЕВ.** Әгәр дә башка юнәлешкә бассак, без халыкны, дингә ышанучыларны диннән үз кулыбыз белән читләштерүе без мөмкин.

5 **Мирфатыйх ЗӘКИЕВ.** ...тарихчылары, татар тарихын рәтләп өйрәнмәгән килеш, татар монгол-татар яуларыннан калган халык, басып алучы халык, дип яздылар. Урыс һәм Көнбатыш

17 **Фәйрузә МӨСЛИМОВА.** Әдәбият дөньясыннан шактый ерак торган гап-гади механизаторлар, инженерлар арасыннан көндәлек матбугаттан иң элек шигырь эзләп укый торган бик күп кешеләрне бе... ләм.

18 **Нури КАМАЛ.** Явызлыкны яшерсәң, ул тагын да зурая, кешеләрне газаплый, җаннарны кыя, дөньяга сыймаслык булып кабара.

...би булыйк, әни булыйк — яшь-яшь калыйк:
Матурлыкка гомер буе сәҗдә кылыйк!..

Минтимер ШӘЙМИЕВ:

Ислам динен тоткан башка халыкларга үрнәк күрсәтик

Татарстан Президентының республика мөселманнары корылтаенда ясаган чыгышы

Бисмиллаһир-рахманир-рахим!
Хөрмәтле мөселман кардәшләр!
Хөрмәтле корылтай делегатлары һәм кунаклар!

Без сезнең белән бүген ничәмә-ничә гасыр вакыт узганнан соң беренче мәртәбә Татарстан мөселманнары корылтаена җыелдык. Бу – чын мәгънәсендә тарихи вакыйга. Бүгенге корылтайда уртага салып сөйләшәсе сүзләребез күп, аларның иң мөһиме – уртак теләк нигезендә берләшү, туплану. Корылтайны ачып җибәргәндә дә, барышында да бу хакта бик матур, дөрес сүз әйтелде. Шушындый уңай нәтиҗә белән гамәл кылсак кына без халкыбыз тарафыннан өстебезгә йөкләнгән бурычны тормышка ашырдык дип горурланып әйтә алыр идек. Шуңа күрә үз исемемнән, Дәүләт Советы һәм Хөкүмәтебез исеменнән сезнең барыгызны да шушы тарихи корылтайның эшли башлавы белән тәбрикләргә рөхсәт итегез. Сезгә исәнлек-саулык, иминлек, корылтай эшендә уңышлар телим.

Бу корылтайга килү юлы озын, бик сикәлтәле, бик киеренке, катлаулы булды. Тирәннән уйлап карасаң, без бит моңа динебез тар-мар ителеп беткән чордан, алай гына да түгел, телебез бетә язган чорлардан киләбез. Революциядән соң ике мәртәбә әлифба алыштырып, телебезне югалта язган халык бит без. Ул елларда безне күпме генә кимсетергә, безгә нинди генә басым ясарга тырышучылар булмаган. Әле кайчан гына безгә менә шулай җыелып сөйләшүне күз алдына китереп була идемени? Без бүген сезнең белән иркенләп, шикләнмичә, горур төстә, беркемнән курыкмыйча, үзебезне кеше итеп тоеп, рухи байлыгыбызны аякка бастыру, динебезне яңарту мәсьәләләрен карарга җыелдык. Бу – безнең тормышыбызда соңгы елларда бара торган үзгәрешләрнең бик зур, гүзәл бер нәтиҗәсе. Нинди генә авырлыклар аша узарга туры килмәсен, менә шулай иркен сулыш алу мөмкинлеге, бергә-бергә динебезне аякка бастыру мөмкинлеге туу – хәзерге чорыбызның зур казанышы. Шуңа күрә безгә бу мөмкинлектән зирәк акылга таянып, тирәннән уйлап файдаланырга кирәк. Аны кулдан ычкындыру безнең мөселманнарыбыз, халкыбыз алдында мәңге гафу ителмәслек хата булыр.

Бүгенге чор, бүгенге көн, бүгенге вакыйга безнең өстебезгә әнә шундый зур җаваплылык йөкли. Соңгы елларда сәясәттә, җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне мин җиңел булды димәс идем. Без бит бөтен яшәү рәвешебезне үзгәртәбез, яңа җәмгыять төзибез. Хәтерегездәдер, моннан 5-6 ел элек кенә республикада нинди генә сәяси вакыйгалар булмады. Нинди генә партияләр, төркемнәр, хәрәкәтләр барлыкка килмәде? Ә шулай да җәмгыять асылы үзгәргән тарихи чорда болар барысы да гадәти нәрсә дип әйтер идем. Менә, күреп торабыз, тормыш әкренләп җайга салынып бара. Ислам диненең аякка басуы шушы чорга туры килгән икән, корылтайны ачып җибәргәндә, бик дөрес әйтелгәнчә, бүген сүз кемнедер гаепләп, кемгәдер үпкәләп, аны читкә кагу, юкка чыгару турында барырга тиеш түгел. Моңа кадәр аңлашылмаучылыклар очраган икән, аларны, тәртәгә кереп китәр алдыннан дип әйтимме инде, була торган вакыйгалар дип карарга кирәк. Хәзерге көндә мөселманнарыбыз арасында бердәмлекнең зарурлыгын, кирәклеген, минемчә, беркемгә дә әйтеп торасы юктыр. Чөнки без сезнең белән Татарстан халкына, Татарстан җөмһүриятенә хезмәт итү бурычын өстебезгә алган кешеләр бит.

Белгәнебезчә, без Тәлгать хәзрәт Таҗетдин һәм Габдулла хәзрәт Галиулла белән изге Рамазан аенда Казан Кремлендә очрашкан идек. Уртага салып сөйләшкәннән соң, чыннан да, "Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар", дигән әйтемне истә тотып, киләчәктә болай итеп яшәргә ярамый, берләшергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килдек. Фәрит хәзрәт белән Габдулла хәзрәт, ике нәзарәт әгъзаларын шул ук көнне җыеп, оешу, берләшү корылтаен бөтен Татарстан мөселманнары вәкилләре катнашында уздырырга кирәк, дигән фикергә килделәр. Бу – уртак фикер. Шуңа күрә әлегә кадәр тормыш, вакыт тудырган нинди генә каршылыклар булмасын, боларны җиңеп, без бер максатка – берләшү максатына омтылырга тиеш булабыз. Бу, минем уйлавым буенча, кемнеңдер теләве-теләмәвенә кайтып калырга тиеш түгел, чөнки, һәрвакыттагыча, без барыбыз да халык мәнфәгатьләреннән чыгып эш итәргә бурычлыбыз.

Сез беләсез, соңгы елларда Татарстаныбыз, аның халкы үзенең дәрәҗәсен һәрьяклап күтәрде. Бөтен дөнья халыклары арасында дип әйтикме, бөтен Русия халыклары арасында диикме, без зирәкләрчә акыл йөртергә сәләтле булуыбызны, язмышыбызны үз кулыбызга алып, тормышыбызны матур итеп корырга сәләтле икәнебезне күрсәттек. Әле күптән түгел Дәүләт Советы утырышында без узган берничә елга йомгак ясап, икътисадта һәм сәясәттә булган эшләребез турында сүз алып бардык, киләчәккә яңа бурычлар билгеләдек. Сез, күп өлкәләр, күп республикалар белән чагыштырганда, Татарстанда икътисад мәсьәләләренең шактый әйбәтрәк хәл ителүен беләсез.

Шуңа күрә халкыбызның, республикабызның дәрәҗәсен күтәрерлек эшләребез бар икән, мөстәкыйльлек юлын сайлап алганбыз икән, без, мөселманнар, җыелышып, менә шушы эшкә бердәм тупланып, кулга-кул тотышып киләчәктә дә туган җиребез Татарстанга, халкыбыз мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә тиеш булабыз. Бүгенге тарихи вакыйга республикабызны тагын да алга илтү, халкыбызның рухи байлыгын тагын да ишәйтүгә юнәлтелгән бик зур бер гамәл булып тора. Һич шигем юк, безнең бу эшне матур иттереп башкарып чыгарга акылыбыз җитәчәк. Мин моңа ышанам.

Соңгы елларда дин тотарга мөмкинлекләр туганнан соң, халкыбызның моңа ничек сусаганын барыбыз да күрдек. Рухи байлыгыбызның күпме югалганын без шуннан гына сиздек. Минем әлегә без тиешле бәя дә биреп бетерә алмый торган бик күркәм эш турында әйтәсем килә. Бездә хәзер көн саен дип әйтимме, ай саен димме, кая карама, мәчетләр үсеп чыга. Берәр районга бер-ике ай бармый торсаң, яңадан барып төшкәндә манаралар саны инде күпкә арткан була. Минем бу эшне башкаруда үзенең өлешен керткән хакимият башлыкларына, дин әһелләренә, эшмәкәрләребезгә, бөтен авыл һәм шәһәр халкына бик зур рәхмәт әйтәсем килә. Бу киләчәктә дә шулай булыр дип өметләник. Шул ук вакытта мин мәчетләребез эшен, аның эчтәлеген баетырга кирәк дип уйлыйм. Чөнки мәчет төзеп куеп кына эш бетми. Динебезне тирәнәйтеп, бөтен мөселманнарны эзлекле рәвештә тәрбия юлына бастырыр өчен бай эчтәлекле тәрбияви эш алып барырга кирәк. Мәчетләр – безнең рухи байлыгыбыз, алар әхлак чыганагына әйләнергә тиешләр, һәм моңа бәйле рәвештә көн тәртибенә гыйлемле, яхшы әзерлекле үзебезнең мөселман руханиларын укыту килеп баса.

Сез – бүгенге корылтай делегатлары – халкыбыз хөрмәтенә лаек кешеләр. Сез чыннан да менә бу чорда кулыгыздан килгәннең барысын да эшләргә тырышасыз. Ә замана үзгәрә тора, Ислам да яңарыш чоры кичерә. Көн таләпләренә туры килә торган руханилар әзерләү мәсьәләсе бүген төп бурычларның берсенә әйләнергә тиеш. Хәзер дә, киләчәктә дә республика Хөкүмәте бу эшкә ярдәм кулы сузарга әзер. Бәлкем, теләгәнебезнең барысын да тиз генә тормышка ашырып бетереп тә булмас, шуңа да карамастан, мәдрәсәләрне кайтарып бирүме, нәзарәтләргә башка төрле мөмкинлекләр ачумы – без кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышырбыз.

Шушы уңайдан минем соңгы вакытта туган бер яхшы фикерне яклап чыгасым килә. Сүз Казанда Ислам университеты ачу хакында бара. Әгәр дә без бу эшкә бергәләп тотынсак, ул чагында югары белемле дин әһелләрен дә җитәрлек кадәр үзебездә әзерләргә мөмкинлек туачак. Соңгы елларда күп кенә яшьләр, дин әһелләре чит илләрдә укып кайталар. Исламның төрле агымнары йогынтысына эләгәләр. Мин моны тәнкыйть йөзеннән әйтмим. Динебезне аякка бастыруны нәрсәдән булса да башларга кирәк иде бит. Шул ук вакытта, әгәр дә уйлап карасак, безнең Татарстанда халыкның белем дәрәҗәсе, гомумән алганда, бездәге мөмкинлекләр, башка Ислам илләре белән чагыштырганда, аларныкыннан бер дә ким түгел. Барын да уртага салып сөйләшеп, үзебездә булган көчләрне, кирәк икән, беренче вакытта галимнәрне, белемле кешеләрне башка җирләрдән чакырып, бу мәсьәләләрне матур иттереп юлга салырга кирәк. Минем уйлавымча, республикабызда яхшы дәрәҗәле руханилар әзерли торган университет, мәдрәсәләр корырга көчебез дә, мөмкинлегебез дә бар. Сүз уңаеннан шуны да әйтим: дини белем бирү белән беррәттән, шәкертләргә дөньяви һөнәрләр өйрәтү кирәклеге хакында тәкъдимнәр дә игътибарга лаек. Бу, һичшиксез, руханиларыбызның белем дәрәҗәсен күтәрер, имамнарның көнкүреш проблемаларын хәл итүне җиңеләйтер иде. Университет, кирәкле кадәр мәдрәсәләр булдырып, үз тарихыбызга туры килә торган, үзебезгә хас булган, буыннан-буынга күчеп килә торган юнәлеш тоту дөрес булыр иде. Бу – бик тирән мәсьәлә. Ислам традицияләре Татарстанда, безнең халык арасында гасырлар дәвамында урнашкан. Халкыбызның фикер йөртү, яшәү рәвешен, белем дәрәҗәсен, аның тирәюнендәге арадаш халыкларны, республиканың географик урынын искә алсаң, милли һәм дини традицияләребезне саклау бик мөһим. Шул чакта гына динне халык аңына сеңдерү, аны рухи байлыкка әйләндерү мөмкин булачак. Әгәр дә башка юнәлешкә бассак, без халыкны, дингә ышанучыларны диннән үз кулыбыз белән читләштерүебез мөмкин. Безнең халкыбызның, яшьләребезнең әзерлеге гел икенче. Хәзерге вакытта без барыбыз да бик катлаулы, бик тыгыз мәгълүмат дөньясында яшибез. Халыкның күңеленә барып җитә торган, рухи таләпләренә туры килә торган гамәлләр аша гына без динне аңыбызга, йөрәгебезгә сеңдерә алабыз. Менә ни өчен минем шушы теләгемне, уй-фикерләремне сезгә җиткерәсем килде. Киләчәктә безгә менә шушы берләшү съездыннан соң бу мәсьәләләргә ныклап тотынасы булыр.

Соңгы вакытларда: "Ник Хөкүмәт безнең дин эшләренә катнаша икән?" дигән сүзләрне ишеткәләргә туры килде. Гаепләп әйтүем түгел, мондый эшләр башкарганда ул була торган хәл. Ә шулай да аңлатып китим. Сүз бит катнашу, кемне дә булса ниндидер эшкә мәҗбүр итү, дин әһелләренең эшенә, идарә органнарына комачаулау турында бармый, ә бергәләп халкыбызга хезмәт итү турында бара. Дәүләттән аерылган булса да, дин, дини оешмалар җәмгыятьтән аерылмаган бит. Соңгы вакытларда нәзарәтләр арасында менә шундый ыгы-зыгылар китсә дә, мөселманнар арасында, дингә ышанучылар арасында, халык арасында бүлгәләнү-яргалану юк дип әйтәсем килә. Халык бердәм ул! Мөселманнар – бердәм алар! Соңгы вакытта миңа бик күп хатлар, башка төрле информация килеп ирешә. Четерекле мәсьәлә туганда халык бит гел үзенең Президентына мөрәҗәгать итә. Кайда булса да, кем тарафыннан булса да берәр ялгыш җибәрелсә, эштә кимчелек килеп чыкса, бу барыбер миңа килеп җитә. Бөтен халкыбыз сайлап куйган Президент буларак, мин һич тә моңа битараф кала алмыйм. Шуңа күрә сүз безнең дини эшләргә турыдан-туры катнашу турында бармый, бергәләп, кулга-кул тотышып хезмәт итү турында бара.

Корылтайның төп мәсьәләсе – берләшү, бөтен мөселман нәзарәтенең рәисен билгеләү, идарә органнарын сайлау, дип әйтелде инде. Шуңа күрә без бу эшләрне тормышка ашырганда, инде демократик җәмгыять төзү юлына басканбыз икән, моны онытмыйк, демократик төстә эш итик, демократик юл белән лаеклы кешеләрне сайлап куйыйк.

Идарә итү органнарын демократик ысул белән формалаштыру бик мөһим мәсьәлә дип әйтер идем. Бүгенге көндә бер кеше генә бөтен эшне дә үз өстенә алып, барысы өчен дә җавап бирер диеп карасак, ул дөрес булмас иде. Шуңа күрә идарә органнарын сайлаганда баш мөфтиебез тирәсендә башка демократик органнар да булырга тиеш, дип саныйм мин. Менә әле генә безнең Казыебыз да булырга тиеш дигән фикер яңгырады. Бу бик кирәкле эш, чөнки, минем уйлавымча, безнең барыбызны да бераз тәртипкә китереп тору кирәк: нинди юнәлеш тотабыз, үз-үзебезне ничек тотабыз, тиешле таләпләрне үтибезме-юкмы һәм башкалар. Идарә органнарын шулай төзү бик дөрес булыр иде. Бөтен Татарстан мөфтиенең роленә килсәк, кем генә сайланмасын, ул кеше безнең бүгенге җәмгыять таләпләренә, яңарып килүче Ислам таләпләренә туры килә торган кеше булырга тиеш. Бу хәзер безнең баштан узган әйбер инде, шуңа күрә беләм: альтернатив сайлаулар вакытында сайланырга теләүчеләр күп булса да, урын һәрвакытта да берәү генә бит. Моны онытырга ярамый. Кем генә сайланмасын, сайланмый калганнар саны күбрәк була. Нинди дә булса мәнфәгатьләрең, омтылышларың тормышка ашмаган икән, Аллаһы Тәгалә шулай кушкан икән, дип, үз-үзеңне җиңеп, моны тыныч кына кабул итәргә кирәк. Бөтен кеше дә Президент булып бетә алмаган кебек, мөфти булып та бетә алмый. Бу зур җаваплылык кемнеңдер өстенә төшә икән, ул кеше заман таләпләренә туры килерлек шәхес булырга тиеш. Хәзерге вакытта сүгеп яисә берәр төрле көч кулланып кешеләргә йогынты ясарга тырышу – ул Ислам динен Татарстанда берничә елга артка чигендерү булыр иде. Безгә менә шуннан куркырга кирәк. Дин тотучыларның бар урта буыны, өлкән буыны, яшь буыны бар. Безгә тарих алдында, халкыбыз алдында олы җаваплылыктан чыгып эш итәргә кирәк. Шулай булмаса, безнең киләчәгебез юк. Яшьләр бернинди басымны, үзләренең фикер юнәлешенә, гамәленә туры килми торган ысулны бервакытта да кабул итмәячәкләр. Сез бит күреп торасыз, Президентның да хокукы күп кебек. Ә бу кешедә никадәр түземлелек булырга тиеш. Ул ишетә, күрә белергә, тәрбияли белергә тиеш. Үтемле итеп яхшы сүзен әйтә белергә тиеш. Шулай булмаса, кабатлап әйтәм, без үз кулыбыз белән Ислам динен, аңа ышануны, аны рухи байлык итеп тоюны берничә елга артка алып ташлавыбыз мөмкин. Монда дөрес әйттеләр, бәлкем, кызганычка каршы, дөнья булгач, бүгенге көндә изге кеше юктыр да. Ә шулай да мөфтине сайлаганда аның белемле, кешеләргә яхшы мөнәсәбәтле, тәмле телле, халыкка Аллаһы Тәгалә сүзен, Коръән, Мөхәммәд пәйгамбәр сүзен оста аңлата, җиткерә белүче, алдынгы карашлы, ихтирамлы кеше булырга тиешлеген истә тотарга кирәк. Сезнең бит эчтәлегегез, уй-фикер йөртә белүегез, аңга, күңелгә үтеп керә белү осталыгыгыз – төп коралыгыз. Алда торган мәсьәләләрне хәл иткәндә, сез менә шуны күз алдыннан ычкындырмаска тиешсез. Халкыбыз өчен Ислам дине – гомер-гомергә Аллаһы Тәгаләгә ышану, Аллаһы Тәгаләнең берлеген икърар итү, Мөхәммәд пәйгамбәрнең Аллаһы Тәгаләнең илчесе икәнен тану белән беррәттән, халкыбыз тарихының, яшәү рәвешенең, мәдәниятенең, сәнгатенең нигезе дә булды. Әгәр дә без зирәк акыл белән эш итсәк, ул киләчәктә дә шулай булачак. Моңа минем иманым камил.

Түземлелек белән тыңлавыгыз өчен сезгә бик зур рәхмәт. Берләшү корылтаен матур итеп уздырыйк, корылтай узгач, халкыбыз: менә бит, безнең дин әһелләребез, сайлап җибәргән делегатларыбыз ничек акыллы эш иттеләр, дип әйтерлек булсын. Без, берләшеп, мөселманнар өчен изге символ булган Кол Шәриф мәчетен төзү, Ислам университеты, мәдрәсәләр ачу кебек күркәм эшләребез белән Ислам динен тоткан башка республикаларга, өлкәләргә, халыкларга үрнәк күрсәтик.

Менә бүгенге сүзләрне кайчан да булса искә төшерербез әле: безнең республикабыз, Казаныбыз Русия мөселманнарының кыйбласы булыр! Акыл белән эш итик, уңышлыкларга ирешик! Бик зур рәхмәт!

14 февраль, 1998 ел.

ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

Җидегән 5 6 7 1 2 3 4

Мөнәсәбәт

...Мәңге ачылачак түгел!

Гарәфи ага Хөсәенов, мәрхүм, гомеренең соңгы елларында гел кошлар турында язды. Ник, ни өчен? Табигать баласы булгангамы? Әллә соң аны Сталин лагерьларында булу, гаепсезгә гаепләнүләр сак булырга өйрәткәнме?

Ни өчен нәкъ менә Гарәфи аганы искә төшердем соң әле? Ничектер шулай, кемнеңдер аңа сорау биргәнен хәтерлим: чыпчык-песнекләр турында гына язу туйдырмадымы әле, янәсе. Гарәфи ага ул чакта "Казан утлары"на янә дә кошлар турында яңа язмаларын алып килгән иде. Хәтерлим, теге сорауга ул рәнҗемәде, ә миңа исә ачынып сөйләде:

– Һәр кошның үз җыры, үз тавышы бар аның. Мин бит аларны аерым-аерым тыңларга яратам. Әмма кош тавышы туйдырган чаклар да була. Урманда-бакчада барча кош берьюлы тавыш кубарган вакыт ул. Чыпчыгы да кычкыра, саесканы да кыркылдый. Менә шунда инде колак тона, сандугач тавышына да исең китми башлый...

Бер уйлап баксаң, әйтерсең, бу дөньяда бөтен тормыш шуңа көйләнгән: җырлап-типтереп кенә яшәрлек! Иртәдән кичкә тикле "сайрыйлар", төнлә дә тынып тормыйлар. Әйтерсең, дөньяның бүтән мәшәкатьләре калмаган, әйтерсең, дөньяны танып белүнең хәстәре юк, әйтерсең, кешенең акылы-аңы беткән, хистән исереп кенә яшисе калган!

...Җырлап ачыла күңел.
Җырлап ачылмаган күңел
Мәңге ачылачак түгел!

Хәтта халык сүзләреннән, халык моңыннан адәм көлкесе ясаган җырлар кешенең уен-фикерен сыта, уйлау сәләтен зәгыйфьләндерә түгелме? Үз-үзен расларга, үзенең дөньяда туюн-барлыгын расларга, үсмерлек чорын кичергән яшьләргә "җырлау халәте" килешә кебек әле. Җырласыннар – тамакларыннан яшь өтәч тавышы киткәнче! Ә менә "Җитәкчеләр җырлый" дигән тамашаны ничек аңларга? Нәрсә, коммунизмга "җырлап" кердек, капитализмга да җырлап керәбезме?! Мәҗлесләрдә ул тавышлар шөбрәк яңгырамаганмы?! Сәяси сәхнәләрдә дан алганнар инде чыпчык-песнәк рәвешен дә алдылармыни?!

Җырлап ачыла күңел...

Ләкин... мондый гамьсез халәткә XXI гасырның ишекләре мәңге ачылачак түгел!.. дип әйтеп тә булмый...

Тик әле бу уйларым халыкның килечәгеннән ваз кичү дә булмас. Чын җырлар, җаңга якын җырлар онытылмас... Ачыла икән – аларныкы җырлап ачылсын...

Нияз АКМАЛ.

Әйткән сүз – аткан ук

Константин РАЙКИН, Русиянең халык артисты:

"Миндә татарлык бар, бераз татармын мин. Бу сыйфат мине күп еллар буе тәрбияләгән Тася ападан күчкән. Ул татар иде. Урысча гаҗәеп акцент белән сөйләште. Искиткеч әйбәт, игътибарлы хатын иде, кулыннан бөтен эш тә килә иде. Гаиләдә без аны бик яраттык..."

("ШК", "РТ").

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татарстан Президенты Указы белән Казан шәһәренең 125 нче мәктәп-гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **ХӘМИТОВА Флюсә Кәбир кызы** Татарстан Республикасының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

Бөек җырчыга һәйкәл

Бөтен дөньяга танылган җырчы, безнең атаклы якташыбыз Федор Шаляпинның тууына 125 ел тулу билгеләп үтелгән шушы көннәрдә аңа һәйкәл корыга зур хәзерлек бара. 14 февральдә Бауман урамында күренекле сәхнә остасының булачак һәйкәле урнаштырылачак урынга таш кую булды. Бу тантананы ачып, Казан шәһәре мэры К.Исхаков, атаклы җырчының дан биеклекләренә үз юлын нәкъ менә безнең шәһәрдә башлавы белән казанлылар хаклы горурланалар, дип күрсәтеп узды. Башкалабыз хакиме белдергәнчә, таш куела торган урында тиздән һәйкәл корылыр. Аның авторы – конкурста җиңеп чыккан скульптор В.Винниченко.

Митингта М.Шәймиев кыска нотык белән чыкты, башкалада яшәүчеләрнең республика рухи тормышында тагын бер якты сәхифә шаһитлары булуларын ассызыклап әйтте. Бөек артистның туган көнендә аңа һәйкәл кору башлана. Һәйкәлне төзү факты үзе үк бөтен Русиянең бөек халкына һәм аның Ф.Шаляпин кебек атаклы вәкиленә ихтирам күрсәтүне тыеп килгән акылсыз тоталитар сәяси системаның бетүенә тагын бер дәлил булып тора, дип әйтте Президент. Ә бит аны бөтен дөнья алкышлаган. Ул чагындагы система бу кешенең бөек сәнгатен үзләштерү мөмкинлеге бирмәде. Шунысы сөенечле, соң булса да, без моны эшли алабыз. Мин бер ел-ел ярымнан казанлыларның шушы даһи талант һәйкәлен күреп соклана алырына ышанам, дип белдерде Илбаш.

Моңсарның Мәскәүне алуы

Мәскәүнең "Россия" концерт залында Илһам Шакировның концерты зур уңыш белән үтте. Залда, кем әйтмешли, алма төшәр урын да юк иде. Мәскәүдә яшәүче кан кардәшләр һәм җырчы иҗатына мөкиббән халык ул көнне Илһам аганың бетмәстәкәнмәс талант иясе булуына янә бер кат инанды. Әйе, аны кайда да көтеп алалар, яраталар.

Татарстан Республикасының Русия Федерациясендәге Вәкаләтле вәкиллеге исеменнән җырчыга олуг рәхмәт ирештерелде һәм чәчәк бәйләме тапшырылды. Аның күркәм җырларын милләттәшләр ишетеп сокланысын өчен Мәскәү татарлары җәмгыяте күп көч куйды. "Фатыйха" дип исемләнгән хәйрия фонды, мәсәлән, Русия башкаласындагы бердәнбер татар мәктәбендә белем эстәүче 150 укучы һәм мөгаллимнәргә әлеге концертка бушлай билетлы итте.

Икенче көнне җөмһүриятебезнең Русия Федерациясендәге Вәкаләтле вәкиллегендә Илһам Шакиров һәм аның иҗат төркеме белән очрашу үткәрелде. Вәкиллек җитәкчесе Ф.Мөхәммәтшин, Мәскәүдәге милләттәшләрне Татарстан белән әнә шулай янә якынайтканы өчен, бөек җырчыга рәхмәт әйтте, аңа озын гомер, иҗат уңышлары теләде һәм Вәкаләтле вәкиллек исеменнән кыйммәтле бүләк тапшырды.

Шартнамә хөрмәтенә кабул итү

16 февральдә Президент М.Шәймиев һәм Дәүләт Советы Татарстан белән Русия арасында төзелгән Шартнамәгә кул куюның дүрт еллыгы хөрмәтенә Мәскәүдә кабул итү оештырдылар. Анда Дәүләт Думасы Рәисе урынбасарлары В.Рыжков, А.Шохин, Мәскәү мэры Ю.Лужков, РФнең милләтләр эше һәм федератив мөнәсәбәтләр буенча министры В.Михайлов, БДБ илләре белән хезмәттәшлек буенча министр Л.Адамишин, Башкортстан Президенты М.Рәхимов, РФ Президенты киңәшчесе Э.Паин, РФ Президентының Конституция судындагы тулы вәкаләтле вәкиле С.Шахрай, Татарстанның Мәскәүдәге тулы вәкаләтле вәкиле Ф.Мөхәммәтшин, Дәүләт Думасы депутатлары, аерым илләрнең илчеләре, сәяси һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнашты.

Кабул итүдә котлау сүзе белән М.Шәймиев чыкты, Ю.Лужков, В.Михайлов, М.Рәхимов, М.Гәрәев һ.б. чыгыш ясады.

Бәйрәмгә килгән кунаклар Татарстан рәссамнарының Большая Никитинская урамындагы клубка куелган әсәрләре белән таныштылар.

Мариам белән Таһир

Үткән шимбәдә Татарстанның Зур концерт залында Австрия пианисты Мариам Джива Женье һәм Башкортстан дирижеры Таһир Камалов чыгыш ясады. Индонезиядә туып-үскән, хәзерге вакытта Австриядә яшәүче музыкантның иҗаты белән казанлылар беркадәр таныш инде. Ә менә Таһир Камалов исеме безнең сәнгать сөючеләргә әлегә әлләни билгеле түгел. Ут күршебездән килгән оста – Швейцариядә үткәрелгән халыкара конкурс лауреаты, Башкортстанның халык артисты. Замазында ул Казан Дәүләт консерваториясендә профессор Фуат Мансуров классында укыган. Бүгенге көндә Т.Камалов Башкортстан Дәүләт симфоник оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры. Кичәдә ул Татарстан Дәүләт симфоник оркестрына дирижерлык итте.

Мөгаллимнәр яклауга мохтаҗ

Чаллының 25 ел педагогик стажы булган һәммә хезмәткәре бу ел мәрияснең махсус бүләген алачак. Шәһәр башлыгы Р.Алтынбаев кул куйган карардан күренгәнчә, мөгаллимнәрне социаль яклау максатында мәгариф учреждениеләрендә аларга былел өч хезмәт хакы күләмендә бер тапкыр премия бирү каралган.

Гүзәл туташлар колагына

23 февральдә Татарстанда "Мисс Татарстан-98" дип исемләнгән I республика конкурсы башлана. Ул җөмһүриятебезнең март аенда ачылачак I яшьләр сәнгать фестивале кысаларында үткәрелә.

Әлеге бәйгедә катнашырга нияте булган туташлар өчен хәбәр итәбез: сайлап алу туры 23 февраль көнне Казандагы "Илдан" фирмасының "Лик" мода театрында үткәрелә.

Җомгадан – җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Русия Федерациясенең Дәүләт Думасы Рәисе Г.Селезнев Казанга килеп, Татарстан Президенты М.Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев һәм милли-мәдәни җәмгыятьләр җитәкчеләре, Татарстан халык депутатлары белән очрашты һәм Горбунов исемендәге заводта, Раифа монастырендә, "Майский" совхозында булды.

Президент М.Шәймиев прокуратура, Эчке эшләр министрлыгы, Дәүләт иминлеге комитеты, Юстиция министрлыгы, салым полициясе, таможня идарәсенең берләштерелгән коллегия утырышында үзенең "Ышаныч" телефоны булдырырга нияттотуын әйтте.

Кама Аланында "Экотекс" фирмасы Швеция технологиясе буенча җылылыкны саклый һәм тавышны уздырмый торган обой җитештерә башлады.

Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән Зөя утравында комплексны дәүләт тыюлыгы оештырылды.

Казанда урыс-татар, татар-урыс гимназия, лицей, мәктәп-лицей җитәкчеләре катнашында "Татар телендә укыта торган яңа төр уку йортлары эшчәнлеген оештыруга яңа таләпләр" дигән республика киңәшмәсе үтте.

Республиканың Төзелеш һәм архитектура министрлыгы бинасында Төркиянең "Скайлайн" фирмасы күргәзмәсе ачылды.

"Казан" милли мәдәният үзәгендә халыкны социаль яклауга багышланган җыелыш узды.

Алабуга мәдәни-агарту училищесының бер төркем укытучылары әлегә уку йорты җитәкчесенең "начар" эшләренә карата протест йөзеннән ачлык игълан иттеләр.

Казанда Татарстан мөселманнарының корылтае узды, һәм анда мөфти итеп Госман хәзрәт Исхакый сайланды.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры Кама аръягы районнарында кышкы гастрольләрдә булып кайтты.

Сәхифәдә редакция журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Беренче биттә – **Р.ЯКУПОВ** фотосы.

Хөрмәтле укучылар! Татарстан Элемтә министрлыгы 1 февральдән 31 мартка кадәр 1998 елның икенче ярты еллыгы өчен гамәлдәге бәядә "Мәдәни җомга"га льготалы язылу үткәрә. Димәк, почта бүлекләренә барып, тагын 27 сум акча түләсәгез, гәзитебез сезгә ел ахырына кадәр килеп торачак. Бу хакта туганнарыгызга, күршеләрегезгә, танышларыгызга да әйтсәгез икән.

Татарстан мөселманнарының берләшү корылтае

Үткән атнада Татарстан мөселманнарының корылтае булды. Аны ачканда оештыру комитеты исеменнән Ильяс хәзрәт Җиһаншин корылтайга сайланган 686 делегатның 653е катнашуын хәбәр итте. Габделхак хәзрәт Саматов Коръәннән аять укыганнан соң, корылтайга рәислек итү Балтач районы мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыевка тапшырылды. Ул беренче итеп сүзне Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевкә бирде.

Берләштерү корылтаеның көн тәртибендә каралганча, Татарстанның мөстәкыйль Диния нәзарәте рәисе мөфти Габдулла хәзрәт Галиулла һәм Уфадагы Үзәк диния идарәсенә караган Татарстан Диния нәзарәте мөфтие Фәрит Салман үзләре җитәкләгән нәзарәтләрнең эшчәнлекләре турында мәгълүмат бирделәр. Үзәк Диния нәзарәте рәисе мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин һәм Русия Диния нәзарәтләре шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, Дагыстаннан, Ичкерия республикасыннан, Ригадан килгән кунаклар корылтайда катнашучыларны котладылар.

Балык Бистәсе районының Имәнкискә авылы имам-хатибы Айрат Мөхәммәтҗанов яңа Диния нәзарәтенең низамнамәсе-уставы белән таныштырды. Фикер алышканнан соң, өстәмәләр белән низамнамә кабул ителде. Корылтай делегатлары Диния нәзарәте мөфтие урынына дәгъва итүче алты кандидатның – Камил хәзрәт Бикчәнтәев, Габдулла хәзрәт Галиулла, Мансур хәзрәт Җәләлетдинов, Габделхәмит хәзрәт Зиннәтуллин, Госман хәзрәт Исхакый һәм Фәрит хәзрәт Салман чыгышларын игътибар белән тыңладылар. Яшерен тавыш бирү юлы белән сайлау нәтиҗәсендә күпчелек тавыш белән мөфти итеп Госман Исхакый, аның урынбасары итеп Вәлиулла хәзрәт Ягъкуб, Диния нәзарәте казые итеп Габделхак хәзрәт Саматов сайланды.

Аннары делегатлар яңа Диния нәзарәтенең пленумы һәм ревизия комиссиясе әгъзаларын сайладылар.

Татарстан Диния нәзарәте мөфтие Госман хәзрәт ИСХАКЫЙ

1957 елда Казан шәһәрендә туган. 1964-74 елларда 129 нчы урта мәктәптә укыган. 1975-77 елларда хәрби хезмәттә була. 1978-82 елларда Бохарадагы "Мир Араб" мәдрәсәсендә укый. 1982-84 елларда Уфа Диния нәзарәтендә Тәлгать Таҗетдиннең сәркәтибе. 1984-85 елларда Ливиядәге Триполи шәһәрендәге университетның шәригать факультетында укый. 1985-94 елларда Башкортстанның Октябрьски шәһәрендә имам-хатиб. 1991-94 елларда шушында ук мәдрәсә ректоры. 1990-94 елларда Октябрьски шәһәр Советы депутаты. 1994 елдан Татарстан мөфтие Г.Галиулланың беренче урынбасары. 1998 елның 14 февралендә ул Татарстан мөселманнарының берләштерү корылтаенда Татарстан Диния нәзарәте мөфтие итеп сайланды.

Телевидение һәм радиотапшырулар компаниясендә үзгәреш

Татарстан Президенты М.Шәймиевнең 1998 ел 12 февраль Указы белән Илшат ӘМИНОВ "Татарстан" дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе рәисе итеп билгеләнде.

Илшат Юныс улы Әминов 1963 елның 27 июлендә Казанда туган. Журналист белгечлеге буенча Казан дәүләт университетын тәмамлаган.

Үзенең хезмәт эшчәнлеген университет тәмамлаганнан соң "Татарстан" дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе хәбәрчесе булып башлый. Аннары "Татарстан" дәүләт телерадиокомпаниясенең мәгълүмат программасы мөхәррире, "Социаль проблемалар" редакциясе мөхәррире булып эшли.

1990 елдан 1992 елга хәтле Казан дәүләт университетының журналистика факультетының журналистика теориясе һәм практикасы кафедрасы ассистенты, өлкән укытучысы вазифаларын башкара. 1992 елдан – "Эфир" телекомпаниясенең яңалыклар хезмәте директоры.

Хатыны Ольга – 6 нчы каналның программа директоры, кызы Каринага 12 яшь.

* * *

Хезмәт вәкаләтләрен арттырып җибәрүе сәбәпле, Наил Кадыйр улы Хөснетдинов "Татарстан" дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе рәисе вазифаларыннан азат ителде.

Милли Мәҗлес – Әлмәттә

14 февральдә Әлмәттә Татар халкының Милли Мәҗлесе "Тирә-як мохит һәм шәхес бөтенлеге" дигән темага сессия һәм фәнни-гамәли конференция уткәрде. Аның эшендә Казан, Чаллы, Алабуга, Түбән Кама, Азнакай шәһәрләреннән һәм Татарстанның башка районнарыннан, Башкортстанның төрле төбәкләреннән, Пинҗә, Сарытау, Пермь өлкәләреннән күп кенә делегатлар һәм кунаклар катнашты.

"Татар дөньясын табигый һәм әхлакый тазарту юлында Әлмәт һәм Түбән Кама җәмәгатьчелекләренең уңай тәҗрибәсе" дигән темага Әлмәттән шагыйрь Разим Вәлиуллин, Түбән Кама татар иҗтимагый үзәге җитәкчесе Хәлим Әюпов чыгыш ясады.

Милли Мәҗлес рәисе урынбасары, "Иттифак" фиркасе рәисе, язучы Фәүзия Бәйрәмова "Милләт, дин һәм хакимият" дигән темага доклад белән чыкты.

Милли Мәҗлес рәисе, язучы Айдар Хәлим "Татар халкының дөнья җәмәгатьчелегенә меморандумы"н укыды һәм ул бертавыштан кабул ителде. Милли Мәҗлес сессиясе берничә резолюция дә кабул итте. Алар арасында Гаяз Исхакыйның 120 еллык юбилеена әзерлекнең канәгатьләнерлек булмавын, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачевка ышанычсызлык белдергәне дә бар.

Идеал ИШБҮЛӘКОВ

Өч дистә ел гомере Татарстанның опера сәнгате белән аерылгысыз бәйле булган шәхес – Русиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Идеал Дәүләт улы Ишбүләков вафат булды.

И.Ишбүләков 1926 елның 26 декабрендә Үзбәкстан ССРның Карши шәһәрендә туган. 1953 елда ул Казан консерваториясе студенты була, ә 1956 елдан – Татар опера һәм балет театры солисты. Сәхнәдә беренче адымнарыннан ук Идеал Ишбүләков зур сәләткә ия булуын күрсәтә, театрның төп драматик теноры булып әверелә. Аңа танылу китергән һәм аны билгеле иткән беренче роль – Н.Җиһановның "Җәлил" операсындагы Муса Җәлил роле. Ул аны 1957 елда Мәскәүдәге Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында һәм шушы операның 1959 елда Русиянең Зур театрындагы куелышында башкарды.

Театрда эшләү елларында Идеал Ишбүләков сәхнәдә 40тан артык образ иҗат итте. Алар арасында Радамес һәм Манрико (Вердиның "Аида" һәм "Трубадур"ы), Каварадосси (Пуччининың "Тоска"сы), Канио (Леонковаллоның "Паяцы"сы), Хозе (Бизеның "Кармен"ы) кебек ачык һәм көчле образлар аерылып тора. Идеал Дәүләт улы татар операларындагы Түләк (Н.Җиһановның "Түләк һәм Сусылу"ы), Вәли (Җ.Фәйзинең "Тапшырылмаган хатлар"ы), Гаяз (Р.Гобәйдуллинның "Җиһангир"ы) һ.б. образларны сокландыргыч итеп башкарды.

И.Ишбүләков илнең күп опера сәхнәләрендә чыгыш ясады. Һәр җирдә тамашачы һәм матбугат аның гүзәл тавышына, актерлык сәләтенә, югары вокал осталыгына уңай бәя бирде.

Ул тормыш сөючән шат күңелле кеше иде. Сәхнә белән аерылышу вакыты килеп җиткәч, И.Ишбүләков Казан консерваториясендә укыта башлады, биш ел буена үзенең бай тәҗрибәсен студентларга бирде.

Хөкүмәт аның иҗат эшчәнлеген югары бәяләде. Ул Татарстанның халык, Русиянең атказанган артисты дигән мактаулы исемнәргә лаек булды, Почет Билгесе ордены һәм медальләр белән бүләкләнде.

Артист вафат. Әмма тамашачыларның, шәкертләренең, хезмәттәшләренең, тарафдарлары һәм дусларының күңелендә ул һәрвакыт намуслы һәм сәнгатькә бирелеп хезмәт итү үрнәге булып калыр.

Татарстан Мәдәният министрлыгы,
М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры,
Казан дәүләт консерваториясе,
Татарстан Театр эшлеклеләре берлеге.

Халык артисты кичәсе

***

Венера ШӘРИПОВАга

Назлы җилләр искән иртәләрдә
Тыңладыңмы чишмә агышларын?
Шул чишмәләр җырын хәтерләтеп,
Иркәлидер безне тавышларың.

Отып алдыңмы син бу җиһанның
Йөрәкләргә кучкән сагышларын? –
Шул моңнарың булып әверелгән
Югалтуларың һәм табышларың.

Синең аша күпме җаннар гашыйк –
Җырга гашыйк, моңга, театрга –
Ходай үзе бүләк иткән сине
Күңелләрне безнең юатырга!

Юатырга, уятырга теләп,
Син үзеңне Илгә багышладың. –
Җырга-моңга табынып ялгышмадың,
Гел кояшлы булсын язмышларың!

Нияз АКМАЛ.

(Фоторәсем Әзһәр ХӨСӘЕНОВның шәхси архивыннан алынды).

26 февральдә Актерлар йортында Русиянең һәм Татарстанның халык артисты Венера Шәрипованың тууына 70 ел тулуга багышланган истәлек кичәсе була.

Кичәдә республиканың танылган сәнгать әһелләре, язучылар, композиторлар катнаша.

Керү ирекле.

Тамаша заллары пәрдәсе

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры

20 февраль – "Сөяркә" (Т.Миңнуллин).
21 февраль – Нәҗибә Ихсанининың иҗат кичәсе.
22 февраль (көндез) – "Каениш, көндәш һәм башкалар" (Г.Камал).
22 февраль (кич) – "Җимерелгән бәхет" (А.Островский).
24 февраль – "Әлепле өртисләре" (Аманулла).
25 февраль – "Җанкисәккәем" (Т.Миңнуллин).
26 февраль – "Күрәзәче" (З.Хәким).
27 февраль – "Җүләрләр йорты" (З.Хәким).
28 февраль – Гаяз Исхакыйның тууына 120 ел тулуга багышланган кичә.

Кече зал

20 февраль – "Сагыш" (А.Галин).
21 февраль – "Карак песи" (Ф.Фатыйхов, С.Латыйпов).
22 февраль – "Карак песи" (Ф.Фатыйхов, С.Латыйпов).
24 февраль – "Өрәкләр" (Г.Ибсен).

Зур концерт залы

20 февраль – Татарстанның халык уен кораллары оркестры концерты. Солистлар – Н.Крыгина, Ю.Сидоров. Дирижер – А.Шутиков.

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры

26, 27, 28 февраль – "Кармен-сюита" (Р.Щедрин).

Татар яшьләр театры

20 февраль – "Кадерне белмәүче бурсык" (Н.Новосельская), 86 нчы балалар бакчасы.
20 февраль – "Хуш, Хәйбүш!" ((И.Юзеев), "Чулпан" кинотеатры.
22 февраль – Тамаша-концерт, "Казан" санаторие.
23 февраль – Яшел Үзән шәһәренең 4 нче татар гимназиясендә дискотека.
24 февраль – "Мисс убырлы" (Ф.Галиев), Казандагы 34 нче балалар бакчасы.
24 февраль – "Тозакка төшкән аучы" (Н.Дәүли), 55 нче мәктәп.
26 февраль – "Тозакка төшкән аучы" (Н.Дәүли), 65 нче мәктәп.
26 февраль – "Сандугач килгән безгә" (И.Юзеев), Гайдар исемендәге мәдәният йорты.
27 февраль – "Керпе малае дуслар эзли" (Р.Корбан), Гайдар исемендәге мәдәният йорты.
28 февраль – "Без барабыз, барабыз, барабыз" (Н.Коляда), премьера, "Казан" санаторие.

Цирк

20-28 февраль – Мәскәү циркы йолдызлары тамаша күрсәтә.

Курчак театры

20 февраль – "Барабашка" (Л.Кожевников).
21 февраль – "Машенька и медведь" (Л.Ландау).
22 февраль – "Кот, петух и лиса" (А.Янкелевич).
25 февраль – "Беда от нежного сердца" (В.Соллогуб).
26 февраль – "Ак күлмәктә сары елан" (Р.Корбан).
27 февраль – "Кот в сапогах" (Ш.Перро).
28 февраль – "Кот, петух и лиса" (А.Янкелевич).

Гаяз Исхакыйны без хәзер, бер дә шикләнмичә, бөек фикер иясе дип өйрәнәбез. Әдипнең нинди генә әсәрен алсаң да, анда дөнья тәрәккыятенә бәйле рәвештә үз халкының үсеше һәм язмышы турында уйлану төп юнәлешне тәшкил итә. Бу хакта ул үзенең күпсанлы әдәби әсәрләреннән тыш, фәнни эзләнүгә тиң махсус әсәрләр дә яза. Болардан иң күренеклеләре – "Ике йөз елдан соң инкыйраз" дигән публицистик-фантастик повесте һәм "Идел-Урал" исемле фәнни тикшеренүе. Беренчесе – 1903, икенчесе 1933 елда дөнья күрә.

елда Лондонда урысча басыла. Үзгәртеп корулар башлангач, "Идел-Урал" 1991 елда Казанда урысча, 1992 елда Чаллыда татарча чыгарылды.

Бу әсәрендә дә Г.Исхакый татар халкы тәрәккыятен киң, тулы панорамада күз алдына китерергә тырыша. "Идел-Урал"ның урысча вариантына кереш һәм соңгы сүз язган Рафаэль Хәкимов әдипнең киләчәккә карашларын кыска гына итеп һәм нигездә дөрес яктыртып бирә. Шуның өчен без биредә Г.Исхакыйның бу әсәрдәге этногенетик карашларына гына тукталабыз.

Әдип-галим бу эзләнүләрендә безнең хәзерге халыкны турыдан-туры болгар дип атамый,

Мирфатыйх ЗӘКИЕВ,
академик

Әдипнең этногенетик карашлары

Бу әсәрләрендә Г.Исхакый, һәр фикер иясенә, һәр чын сәясәтчегә хас булган юлдан китеп, үз халкының киләчәген билдыру юлларын, аның этногенезына (килеп чыгышына), тарихына (халык буларак формалашкач үткән юлына), бүгенге вазгыятенә таянып, аларны бер системага салу аркылы билгеләргә омтыла; халыкның этногенезын, тарихын, бүгенгесен һәм киләчәген бер панорама итеп күз алдына китерә, һәм халык тормышының кайсы чоры турында уйланса да, ул аны бары шул яссылыкта гына карый, ягъни бөтенне күз алдында тотмыйча, аерым өлешләр турында фикер йөртми. Г.Исхакыйның бу фәнни алымы безнең күп кенә гуманитарийлар, тарихчылар һәм сәясәтчеләр өчен акыллы үрнәк була ала. Шуңа күрә аны җентекләп өйрәнү аерым әһәмияткә ия.

Г.Исхакыйның этногенетик фикерләренә конкрет тукталганчы, бер этнонимик (халык исеменә бәйле) фактны әйтмичә булмый. Хәзер бездә берничә фән әһеле болгар атамасын татар этнонимына каршы куеп, болгар исеменә арка белән борылуны таләп итә. Бу – тирән ялгышу. Г.Исхакыйда мондый ялгышлык юк. Шуңа күрә әдипнең хәзерге татар атамасы урынына аның бабасы исеме булган болгар этнонимын куллануына аптырамаска кирәк.

"Ике йөз елдан соң инкыйраз" әсәрендә Г.Исхакый XIX йөздә халкыбызның инде терелә баруын күрсәтә дә, бу эштә яңа фикерле җәдитчеләрнең уңай ролен билгели. "Әгәр болгарлар арасында шундый "яңа фикерле" дигән бер сыйныф килеп чыкмаган булса иде, бу вакытка кадәр яткан ягымыз илә ятар идек. Рәхмәт бу кешеләргә! Болгар дигән бер халык бар икәнлеген үзебезгә белгерттеләр... Үз милләтемезне терелтү өчен чаралар эзли башладылар. Үзләрен үзләре фида кылдылар, рәхәтләрен югалттылар. Бөтен милләтемезнең оятсыз кешеләреннән төрле кабахәт сүзләр белән сүгелүне дә күтәрделәр, вә төрле ялган ифтираларга (яла ягуларга – **М.З.**) разый булып, милләт юлында кылган хезмәтләренә рәхмәт, ял сорамыенча, һаман эшләрендә булдылар". Билгеле инде, яңа фикерле кешеләрнең башында Ш.Мәрҗани, К.Насыйри кебек бөек шәхесләребез торганны белеп сөйли автор.

XXI гасыр якынлашу уңае белән, мин Исхакыйның бу әсәреннән тагын бер өзек китерер идем.

"Шулай итеп бу гасыр да үтеп китте. Егерменче гасыр башланды. Бу гасыр безгә ни бирә? Бу гасырда безнең болгарлар нишли... фикерле сыйныфына кергән кешеләр бу гасыр безнең өчен тәрәккый гасыры булса иде, дип дога кылалар иде, һәм дә ... бу гасырның башында ук тәрәккый галәмәтләре күренә башлады", – ди автор һәм аларны санап күрсәтә, бу галәмәтләрнең әле җитәрлек түгеллеген әйтә һәм милләтебезне саклау, үстерүнең күп юлларын билгели. Кыска итеп әйткәндә, бу юл – халкыбызны, аның зыялыларын дөнья мәдәнияте үсеше югарылыгына күтәрү һәм тагын да үстерә бару.

Татар халкының язмышын татар тарихының киң панорамасында дөнья мәдәнияте югарылыгыннан карап өйрәнү һәм аның Идел-Уралдагы киләчәген билгеләү буенча 30 нчы еллар башында Г.Исхакый махсус бер гыйльми эзләнү үткәрә, дигән идек. Ул "Идел-Урал" исеме белән 1933 елда Берлинда – татарча, Парижда – урысча һәм французча, 1934 елда Токиода – японча, 1938 елда Варшавада – полякча, 1988

"болгарларның һәм яу белән килгән төркиләрнең кушылуы нәтиҗәсендә тарих сәхнәсендә Казан татары дигән халык пәйда була", – ди.Танылган этнограф Н.Воробьевтан алып, Г.Исхакый тагын болай дип белдерә: "Татар исемен (урыслар Алтын Урданың барлык халкын рәсми рәвештә шулай атаганнар) Идел-Чулман төбәгендә яшәүче халыкка урыслар, Казан ханлыгы оешканнан соң һәм бу ханлык аларны берничә мәртәбә җиңгәннән соң гына тагалар. Алтын Урдага карата мөнәсәбәт Казан ханлыгына һәм аның халкына күчә".

Шулай итеп иң баштагы этногенетик карашлары буенча болгарчыларга тартымлык күрсәткән Г.Исхакый, безнең күренекле тарихчыларыбызга ияреп, болгар-татарчылар сафына баса. Хәзерге татар халкы җирле болгарлардан һәм кыпчаклардан формалашкан, алар яулап алучылар буларак аз санлы монгол-татарларны да үз эчләрендә бик тиз эреткәннәр, дигән фикер үткәрә. Чыннан да, әгәр Идел-Уралда яулап алучы монгол-татарлар, күпчелекне тәшкил итеп, җирле халыкны ереткән булсалар, халкыбызның антропологик тибы да, теле дә Үзәк Азиядәгечә булыр иде.

Татарның Болгар чорындагы төрки кабиләләрдән генә түгеллеген, **болгар** исеме таралганчы, шунда яшәгән нигездә җирле кабиләләрдән үсеп килүенә басым ясау һәм азатлык хәрәкәтенә башка төркиләрнең дә иярүенең күрсәтү өчен, 1917 елның 22 ноябрендә Уфада үткән милли мәҗлес безнең халыкны **төрки-татар** дип атый. Шуны истә тотып, Г.Исхакый да болгар-татар атамасы урынына күбрәк төрки-татар этнонимын кулланып эш итә, **болгар-татар** мәгънәсен төркитатар семантикасы эчендә күрә.

Татар этносының нигездә җирле кабиләләрдән – төрки-болгарлардан үсеп килүен күрсәтүгә ул чорда Г.Исхакыйның чит илдә эшләве генә мөмкинлек бирә. Әгәр ул СССРда булса, аны болгар-татар юнәлешендәге этногенетик карашны яклаучы башка күренекле татар тарихчылары белән бергә репрессиягә эләктергән булырлар иде. Чөнки татар милләтенең җирле булуын исбатлап, аны милләт буларак яшәргә, үсәргә, үз ватанына хуҗа булырга тиешлеген күрсәтү коммунистларның бер генә милләтне саклау сәясәтенә каршы килә иде.

Менә ни өчен совет чорындагы олы тарихта – урыс һәм Көнбатыш тарихында татарның хәзерге иленә – Идел-Уралга монгол-татар буларак килеп урнашу теориясе, традиция буларак, дәвам иттерелде. Бу традиция XVIII йөздән үк ныгып килә иде. Урыс һәм Көнбатыш тарихчылары, үз халыклары тарихын гына җентекләп өйрәнеп, татар тарихын рәтләп өйрәнмәгән килеш, бары этнонимнан чыгып кына, татарны монгол-татар яуларыннан калган халык, басып алучы халык дип яздылар. Бу юнәлешне мин үз эзләнүләремдә дилетант татарчылар юнәлеше дип атау дөрес булыр дип язып килдем. Чыннан да, болар татар тарихы буенча дилетант иделәр.

Урыс һәм Көнбатыш тарихчылары яза торган олы тарихта татар этногенезын бу **дилетант татарчылар** юнәлешендә яктырту совет чорында бер дә туктамады, аның хәзер дә төзәтелгәне юк.

Ватан сугышыннан соң кайбер автоном республикаларга үз тарихларын бераз борынгылатырга, аларга дәүләт тота алмаслык яшь халык дигән тамгадан котылырга бераз мөмкинлек биреп алдылар. 1946 елда татар тарихы буенча Мәскәүдә дискуссия оештырылды. Алдынгы галимнәребез, "халык дошманы" исеме тагылган һәм репрессияләнгән болгар-татарчыларга ияреп, күп кенә яңа лингвистик антропологик, мифологик фактлар да китереп, болгар-татар теориясен торгызырга азапланып карадылар. Ләкин аларга 1944 елда чыккан мәгълүм партия карары комачаулады. Алтын Урда чорын эндәшмичә сикереп узып, болгар һәм болгарга кадәрге чорларны өйрәнү авырга килә иде, чөнки татар тарихын бербөтен панорама итеп карау таләбе бозылган иде. Дөресен әйтергә кирәк, 1944 елгы бу карар татар тарихын Казан ханлыгының урыс дәүләтенә "кушылуы" чорыннан гына өйрәнүне хуп күреп язылган иде.

Менә шул шартларда татар галимнәренең үз тарихын аз булса да борынгылатырга тырышулары бары татарларның үзләре өчен генә булып калды, аларның эзләнүләре гомум дөнья тарихына үтеп керә алмады, анда дилетант татарчылар юнәлеше һәм миссионерлар карашы хөкем сөрде һәм хәзер дә шул өстенлек ала.

Бары үзгәртеп корулар башлангач кына, ныклы нигезен Шиһабетдин Мәрҗани салган, Һади Атласи, Риза Фәхретдин, Зәки Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Гаяз Исхакый кебек бөекләребез үстергән болгар-татар юнәлеше татар тарихына нигезле генә кертелә башлады. Бу караш кайбер чит ил һәм урыс тарихчыларына да үтеп керде. Әнә, тарихны ясауда үзе катнашып, аны тирәнтен өйрәнгән армия генералы академик Мәхмүт Гәрәев тә болгар-татар юнәлешен яклап, аның дөреслеген антропологик факт белән исбатлап язып чыкты.

Гаяз Исхакый Алтын Урданы болгар-татар дәүләтчелеге системасында карый, аның төзелү, яшәү рәвешен, таркалу сәбәпләрен кыска гына ачыкларга тырыша. Бу факт та Г.Исхакыйның этногенетик карашларын билгеләргә ярдәм итә, аның бу мәсьәләдә Ш.Мәрҗани мәктәбе кешесе булуын күрсәтә.

Билгеле, Гаяз Исхакый төрки-татар этник тамырларының башлангычы турында тикшеренүләр алып бармаган, шул чорда тюркологиядә формалашкан беренче төркиләр Аурупага һунн исеме белән килгән дигән фикер белән чикләнгән. Ул хәзерге татар халкының төп этник тамырларын болгарлар белән бәйләгән монгол-татарларның килеп кушылып, җирле төркиләр арасында эрүен дә ачык күрсәткән.

Гаяз Исхакыйның татар этногенезына карата шундый болгар-татарчылык, хәтта борынгыга тагын да тирәнрәк төшкән төрки-татарчылык карашы шома гына, каршылыксыз гына формалашмаган. Аңа, этноним берлегенә таянып кына, татарны яулап алучы монгол-татарлар белән тиңләүчеләргә каршы көрәшергә туры килгән. Ә монгол-татарчылар үзләре, бигрәк тә Г.Исхакый үлгәч, аның болгар-татар теориясен җимерергә тырышканнар. Шундыйларның берсе – Төркиядә яшәгән Ләбиб Каран.

Ул 1962 елда Истанбулда "Татарларның төп чыгышы" дигән китап бастыра. Анда шул чордагы алдынгы капиталистик илләрдә үсеп киткән милләтчелеккә ияреп, татар халкын, совет коллыгыннан азат итеп, Алтын Урда күләмендә зур татар итеп кире торгызу идеясен алга сөрә. Димәк, патриотик тойгылардан чыгып эш итә. Моның өчен ул татар дигән этнонимның мәгънәсен төрки сүзе мәгънәсендә аңлауны шарт итеп куя. Болгарлар башта ук татарларның бер кабиләсе генә булганнар, ди ул, этнонимны этнос белән бутап, болгар төркитатар кебек этнонимнарга каршы ут ача. Татар исемен кулланып кына Алтын Урданы үзебезнеке итеп торгызып булыр, шул нигездә төркиләрне дә татар исеме белән берләштереп булыр дигән фикер үткәрә Л.Каран.

Татар сүзе белән янәшә киңрәк мәгънәле – төрки-татар (түрк-татар) сүзен, төркиләрнең барысын да җыеп атаганда, түрк атамасын кулланганы өчен, Гаяз Исхакыйга да, Садри Максудига да Л.Караннан бик каты

(Ахыры 8 нче биттә).



Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ

Президент канәгатьсезлек белдерә

Танылган журналист Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ "Мәдәни җомга" гәзитенең парламент хәбәрчесе булып эшли башлады. Бүген ул Татарстан Дәүләт Советының XIY пленар сессиясеннән үзенең беренче язмасын тәкъдим итә.

Дәүләт Советы сессияләрендә, зур җыелышларда Президент М.Шәймиев чыгышларын минем күп тапкырлар тыңлаганым бар. Әмма аның үткән атнада XIY пленар сессиядәге чыгышы башкаларыннан нык аерыла иде. Президент бик кискен тонда чыгыш ясады, күп тармаклы халык хуҗалыгындагы җитди кимчелекләрне каты тәнкыйть итте. Сессиянең барышы радио аша бөтен республикага трансляцияләнүдән файдаланып, ачы булса да, хакыйкатьне бар халыкка җиткерде.

Президентның моңарчы рәсми чыгышларында үз аппаратын тәнкыйтьләвен миңа ишетергә туры килмәгән иде. Бу юлы М.Шәймиев Президент аппараты җитәкчесе Х.Низамовның кадрлар сайлауда, аларны тәрбияләүдә канәгатьләнмәслек эшләвен белдерде. Моңарчы җил-яңгыр тимәгән башка кайбер җитәкчеләрнең дә фамилияләре аталды.

Президент чыгышында Премьер-министр Ф.Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге Министрлар Кабинетының инициативасыз эшләве, кайбер очракларда кушканны көтеп утыруы билгеләп үтелде. Министрлыкларның, Дәүләт комитетларының яңалыкны сиземләү сәләте юк, базар шартларында алар алга карап эш итә белмиләр әле. Мәсәлән, Табигатьне һәм табигый ресурсларны саклау министрлыгының штаты кечкенә түгел. Ул бюджетка халык түләгән салымнардан кергән акчаны шактый күп суыра. Әмма әйләнә-тирә мохитебез елдан-ел начарая бара. Елгаларыбыз корый, чишмәләр пычрана, нык агуланган һаваны сулыйбыз...

Урман хуҗалыгы министрлыгы безгә ата-бабаларыбыздан мирас булып калган урманнарыбызны киләчәк буыннар өчен ни дәрәҗәдә саклый соң? Бу сорауга җавап бирергә тел әйләнми. Шәһәр тирәсендәге урманнардагы тәртипсезлекләрне күреп йөрәк әрни. Юл салсалар да, төрле линияләр үткәрергә кирәк булса да, урман кисәләр. Куйбышев сусаклагычын төзегәндә күпме урманнарыбыз, болыннарыбызның су астында калуы, болай да инде урман мәйданнарының нык кимүе бу тармак өчен җаваплы җитәкчеләрне тетрәндерергә тиеш иде дә бит. Юк шул! Һаман да җавапсызлык чиреннән арына алмыйлар.

Ил белән коммунистлар идарә иткәндә "Барысын да кадрлар хәл итә" дигән гыйбарә еш кулланыла иде. Соңгы вакытта бу сүзләрне нигәдер онытtылар. М.Шәймиев шул ук фикерне башкачарак сүзләр белән кабатлады: "Бүгенге чорда барысын да команда хәл итә". Уйларга сәләтле җитәкчеләр, Президент карашынча, әйбәт команда туплап өлгерделәр, авыр мәсьәләләрне хәл итү юлларын табалар, базар шартларына тизрәк ярашалар, үз предприятиеләренең нәтиҗәле эшләүләренә ирешәләр. Аларның продукция җитештерүгә заказлары да бар, эшчеләргә хезмәт хакы вакытында түләнә, йортлар төзелә, башка социаль мәсьәләләр уңышлырак хәл ителә. Президент А.Павлов (Казан моторлар төзү берләшмәсе), А.Лаврентьев ("Казан вертолет заводы" акционерлык җәмгыяте), В.Кулагин ("Теплоконтроль" берләшмәсе), Р.Каргин ("Хитон" акционерлык җәмгыяте), З.Хабулава ("Заря" кондитер фабрикасы" акционерлык җәмгыяте), Н.Капустин ("Вакуummаш" акционерлык җәмгыяте) кебек җитәкчеләрнең исемнәрен зур хөрмәт белән атады. "Казанькомпрессормаш" (И.Хисамиев), "Радиоприбор" (Р.Аппаков), Горький исемендәге завод (Г.Алексеев), "Сантехприбор" (Ә.Мөхәммәтзакиров), Казан җитен комбинаты (Б.Селеваненко), төгәл машиналар заводы (Н.Гайнетдинов) кебек предприятиеләргә яңа җитәкчеләр килгәч, эш җанлана төшкән.

Шул ук вакытта эшчеләренә хезмәт хакы да түли алмаган җитәкчеләр дә аз түгел әле. Президент промышленность департаменты башлыгы А.Кәримовка андый җитәкчеләргә карата таләпне нык арттырырга кушты. Татарстан хөкүмәте дә дәүләт ярдәмен генә көтеп утыручы җитәкчеләргә карата түземлелек күрсәтә. Акция пакетлары дәүләт милке булып исәпләнгән кайбер предприятиеләргә ярдәм дә итәргә туры киләчәк, билгеле. Әмма предприятиенең тиешенчә анализланган бизнес планы булырга, бухгалтерия, исәп-хисап эшләре халыкара стандартларга җавап бирергә тиеш.

Фәнни-тикшеренү институтларының бүгенге хәле зур борчу тудыра. Республикада алар 70кә якын. Әле кайчан гына дөньякүләм әһәмияткә ия булган фәнни үзәкләр дә таркалып бара. Югары квалификацияле белгечләр кайсы кая китеп бетте. Президент М.Шәймиев фәнни-тикшеренү институтлары белән конкрет шөгыльләнү зарурлыгын белдерде. Мөгаен, аларның кайберләре предприятиеләр белән берләшер, кайберләрен ябарга да туры килер...

Бүгенге көндә җавапсызлык зур афәткә әйләнде дисәк тә, әлләни ялгышмабыз кебек. Сессия ачылган көнне, мәсәлән, иртән хәтта Ирек мәйданы, парламент һәм хөкүмәт урнашкан бинаның әйләнә-тирәсе кардан арчылмаган иде. Шунлыктан Президентның җавапсызлыкка каршы чын мәгънәсендә көрәш ачуын аңларга да, акларга да була. Сессиянең икенче көнге утырышы да дәүләт башлыгының көтелмәгән белдерүе белән башланды. Президент "Татарстан" дәүләт телерадиокомпаниясе рәисе Н. Хәснетдиновны эшеннән алып ыргытачагын, бу уңайдан Указ чыгарачагын белдерде. Телевидениедән Президентның Дәүләт Советына юлламасының тәнкыйть өлешен күрсәтмәгәннәр, кисеп ташлаганнар икән. Бәлки, соңгы вакытта телевидение тапшыруларының түбән сыйфатлы булуы да Президентка йогынты ясагандыр, ә, бәлки, башка башбаштаклык эшләүчеләргә сабак бирергә теләгәндер. Ничек кенә булмасын, Президент сүзендә торды, икенче көнне үк Н.Хәснетдиновны җылы урыныннан кузгатты. Аның урынына "Татарстан" телерадиокомпаниясе рәисе итеп И. Әминов билгеләнде. Илшат – моңарчы дәүләт структураларында чиновник буларак хезмәт итеп бозылмаган иҗат кешесе. Мин аның университетны тәмамлап, Казан телестудиясенә килгән чорын яхшы хәтерлим. И.Әминов тырышлыгы, эчке культуралы булуы белән хезмәттәшләренең ихтирамын тиз казанды. Соңгы елларда "Эфир" каналында эшләгәндә дә үзенең талантын күрсәтә алды. Җаваплы эшендә аңа уңышлар телик.

Президентның журналистларга әйтәсе сүзләре шактый күп җыелган булып чыкты.

– Тәнкыйть адреслы булырга тиеш, – диде Президент. – Транспорт һәм башка кайбер тармаклар начар эшли. Матбугат бүгенге чорда күп нәрсә эшли ала. Кимчелекләрнең сәбәпләрен ачарга кирәк.

Агропромышленность комплексы тотрыклы эшли. Узган ел 1996 ел белән чагыштырганда тулай продукция 9 процентка артыграк җитештерелде. Нәтиҗәләр, беренче карашка, күркәм күренсә дә, тынычланырга һич тә җирлек юк әле. Күрсәткечләр бик чуар. Президент шундый саннар китерде: Азнакай районында айлык уртача хезмәт хакы 763 сум. Нурлат районында да ул шул дәрәҗәдә. Ә менә Әлкидә уртача хезмәт хакы – 282, Балык Бистәсендә 287 сум. Аерма зур. Сәбәбе – берәүләр тирләп-пешеп продукция җитештерүне арттыру өчен тырышса, икенчеләр исә "алма пеш, авызга төш" дигән принцип белән тыныч кына яши бирәләр. Базар шартлары андыйларны кабул итми шул.

М.Шәймиев аерым районнарда терлекчелек продукциясенең үзкыйммәте югары булуын тәнкыйтьләде. Кайбер урыннарда әрәм-шәрәм ителгән, урланган азык-төлекне дә сыер-сарыкларга ашатылды, дип хисап бирәләр.

Республикада җирне сатаргамы, юкмы, дигән бәхәс күптән бара. Ул Татарстанның "Җир кодексы" тикшерелгәндә тагын да көчәя төште. Президент та бу теманы читләтеп үтә алмады, җирне тауарга әйләндерү ягында торуын белдерде.

– Берәү дә җир хуҗасын үзенә бирелгән участогын сатарга мәҗбүр итмәячәк. Тели икән, арендага бирсен яки җирдә үзе эшләсен, продукция җитештерсен, – диде М.Шәймиев.

Күп кенә оешмаларга җитәкчелеккә бизнеста беренче чыныгу алган кешеләр килә. Әмма аларга дистәләрчә бюрократик киртәләрне кичәргә туры килә. Президентның әйтүенә караганда, "Заря" кондитер фабрикасы" акционерлык җәмгыяте генераль директоры З. Хубулавадан уннан артык лицензия таләп иткәннәр. Хәтта үз территориясендәге подстанция электр энергиясеннән файдаланган өчен дә, "Заря" җитештергән конфетларны "Заря" кибетендә сату өчен дә рөхсәт кәгазе – лицензия сораганнар. Ә бер лицензия дә акча түләмичә бирелми... Бәлки Президентның шушы чыгышыннан соң бюрократиягә азмы-күпме чик куелыр. Шуңа өметләник.

* * *

Үткән атна ахырында Татарстан Президенты М.Шәймиев чакыруы буенча Русия Федерациясе Дәүләт Думасы Рәисе Г. Селезнев Казанда булды. Бу аның Дума Рәисе буларак республикабызга беренче тапкыр килүе иде. Мәскәү кунагы визитының төп максаты Татарстан белән федераль мөнәсәбәтләрне көйләү булуын белдерде.

Г.Селезнев Президент М.Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев белән очрашты. Татарстан халык депутатлары, милли-мәдәни җәмгыятьләр вәкилләре, студентлар һәм югары уку йортлары галимнәре белән сөйләште. Горбунов исемендәге авиация берләшмәсендә сентябрьдән бирле хезмәт хакы алмаган эшчеләр Дума Рәисенә кайбер сорауларын бирергә җыенганнар иде. Әмма ул эшчеләр белән сөйләшергә вакыт тапмады, генераль директор белән очрашып, "Майский" совхозына китеп барды.

Г.Селезневның визиты Русия-Татарстан Шартнамәсенә кул куелуга дүрт ел тулган көннәргә туры килде. Бәлки бу очраклы хәл дә түгелдер әле. Ничек кенә булмасын, Г.Селезнев һәр җирдә үзен бик тыныч тотарга тырышты, шактый катлаулы сорауларга да ачыктан-ачык, боргаланмыйча җавап бирде.

Г.Селезневның әйтүенә караганда, Русия Конституциясенә тиздән күп кенә төзәтмәләр кертеләчәк. Чөнки ул төбәкләрнең фикерләрен исәпкә алмыйча, ашык-пошык кына кабул ителгән иде. Яңа паспортларга мөнәсәбәте белән кызыксынгач, Дума Рәисе хөкүмәтнең аларны парламент белән килештермичә әзерләвен әйтте. Аның карашынча, башта Русиянең дәүләт символларын – гербны, флагны һәм гимнны расларга кирәк. Аннары паспорт мәсьәләсенә яңадан әйләнеп кайтырга туры килер.

Г.Селезнев бүгенге Русия хөкүмәтенең бик йомшак булуын белдерде. Министрларның еш алмашынып торуы эшкә тискәре йогынты ясавына басым ясады.

Русия Федерациясе Дәүләт Думасы Рәисе журналистлар өчен матбугат конференциясе үткәрде, радио һәм телевидение буенча "Турыдан-туры элемтә" тапшыруында катнашып, халыкны кызыксындырган сорауларга җавап бирде. Татарстан белән якыннан танышу, бәлки, Мәскәү чиновникларына республикабызга карашларын уңай якка үзгәртергә ярдәм итәр. Г.Селезневның визит йомгакларыннан канәгать булуы моңа ышаныч тудыра.

***

Җиһанда мин
җитмеш ел гомер сөрәм.
Яшьлектәгеләрне төшләремдә күрәм.
Яратканнарыма, җан атканнарыма
кул бирәм.
Егерме биштә дә,
җитмештә дә мин алар белән.
Үз кадеремне белмәсәм дә,
алар кадерен беләм.
Алар хакына тәмугка да керәм.
Газраилне күргәндә дә,
Җан атканымны,
аларны мин өзелеп яратканымны
әйтеп үләм.

***

Сөембикә манарасы –
әллә ул күңел тантанасы,
әллә күңел ярасы –
ничек җавап табасы?
Бар әле сәфәр аласы,
барасы, янасы.
Үзең булып каласы.
Сөембикә манарасы –
милләтнең күңеләнә сеңгән,
догасына кергән,
илаһи бер кыйбласы.

Бел син, татар баласы!..

***

Кайбер симезләр-корләр,
бай тәкәбберләр,
мин-миннәр,
рухи хәерчеләр –
рәхмәт әйтсәң, кабул итмиләр,
сәлам бирсәң, алмыйлар.
Сәбәбе бар:
сәламне дә,
рәхмәтне дә кесәгә салмыйлар.
Алар яшәү халәтен,
сәләтен,
кодрәтен
үзләренчә аңлыйлар.
Андыйлар белеп туалар,
кесәгә акча керсә генә кул уалар.
Мал җыя-җыя,
кул уа-уа,
үлеп куялар.

Үлем түшәгендә
сәлам дә биреп куялар –
тәмугка керәселәрен тоялар.

***

Кая гына барыйм,
кемгә генә ялварыйм,
ничек кенә исән калыйм?
Этләр,
гүргә кертәләр

Кави ЛАТЫЙП

Бер гомер бакчасында әремнәрем, гөлләрем...

***

Минем баш ниләр генә күрмәде:
суга да баттым,
утта да яндым.
Бихисап күз яшем тамды.
Яшим, дип,
бирешмим, дип, артыгын да түләдем.
Әмма үлмәдем,
түзде йөрәгем.
Коткарды кемгәдер кирәгем.

Бер гомер бакчасында
әремнәрем, гөлләрем...

***

Казанда гомерем узды.
Берәүләр аяк чалды,
берәүләр кул сузды.
Кичердем мин төрлесен.
Шигырь иде күңел хисем,
күңел җимешем,
минем эшем.
Чигенергә дә, җиңәргә дә
җитте дәрманым-көчем.
Еласам иртән,
җырладым кичен.

Җиңеп тә, чигенеп тә
үземне мин сынадым.
Пычакта сынмагач,
юк, кочакта сынмамын.

Казаным, киңрәк ач колачыңны!
Ходай биргән
"Казан" дигән бер сүз өчен
бирергә өзер җанымны.

***

Бәхет таш яра,
язган булса.
Тәңре куша.
Күренми үзе генә.
Колакка ишетелә сүзе генә.
Насыйп икән,
язган бәхет кылдан нечкә, кылычтан үткен
сират күперен кичкән
һәм дә кеше күңеленә ирешкән.

***

Уйлап сөйлә,
уйнап сөйләмә.
Сүзләреңне,
серләреңне чәчмә җилләргә.
Үкенерсең.
Гарьлегеңнән,
әрнүеңнән
йә суга сикерерсең,
йә утка керерсең.
Саклан беркатлылыктан,
узган-барганга ачылма.
Ялгыш әйткән бер сүздән
гомер чәчәге сула,
тормыш касәсе агу белән тула.

кансыз бәндәләр.
Үзләрен,
сүзләрен яратмаганым өчен,
үземне сатмаганым өчен.
Вөҗданыма-иманыма
таш атмаганым өчен.
Вөҗдансызлар-имансызлар арасында
урын тапмаганым өчен.
Яшәүдән баш тартмаганым өчен,
агу капмаганым өчен.
Үзем булып атлаганым өчен,

Идел-йортны саклаганым өчен.

***

Яшь бер гүзәл мине сөя,
күкләргә чөя.
Өзелеп ярата,
җан ата.
Үзе белән яшьлеккә алып кайта.

***

Илдар Юзеевка

Син тартмасаң,
мин тартмасам,
тик торыр шигъри арба –
Төртә барда.
Кемдер әйтә: "Шигырь – аргамак".
Бәхәсләшмик.
Фикердәшем,
сердәшем,
шигырьдәшем, –
гел эшлик,
бирешмик!
Шигъри сөенечләрне дә,
шигъри көенечләрне дә,
бүлешик.

Максатларга ирешик.



***

Җәүһәр эзлим,
юк, диңгездән түгел,
үз күңелемнән.
Көн-төн җәфа чигәм,
әмма түзәм.
Табыласын сизәм.
Ләкин кайчан?
Хәзерме?
Соңракмы?
Бәлки, ул сузылыр
гомеремнең соңгы мизгеленә чаклы?
Җәүһәр эзлим,
шигырь-җәүһәр,
шигырь-ядкарь.
Җәүһәр эзлим,
юк, диңгездән түгел,
үз күңелемнән.

Ә ул диңгездән тирән...

***

Яшисе иде икеләнмичә,
теләкләрне чикләмичә.
Ләкин мөмкин түгел.
Шундый минем күңел:
Үз-үземнән шикләнәм.
Тәэсир итә иксез-чиксез Галәм.
Ә мин – бәләкәй бер адәм...

***

Ашкынулы дәрт белән яшим,
эшлим.
Холык-фигылем шундый –
нишлим?
Бутәнчә яши алмыйм,
эшли алмыйм.
"Үзгәр!" дип үземне көчли алмыйм.
Башкача мин була алмыйм,
күңел ташкынын мин буа алмыйм.
Яңадан туа алмыйм.

***

Җиде ятып, җиде уянам,
Җиде ятып, җиде уйланам.
Йә исән калам,
йә мәңгелек йокыга талам.
Көн – тәмам.
Төн – дәвам.
Бәхил бул, гавам!

***

Дөньядан ваз кичәм,
Яшәгез минсез генә.
Йолдыз да бит бер сүнә.
Мин дә сүнәм.
Киек каз юлыдай
сызылып кала шигъри юлым.
Юк, онытмас Күк-Тәңре
шигърият дип,
җанын фида кылган улын.
Күктән җиргә, йолдыздай,
атылырга торган улын...

Шигырь — нечкәлек билгесе белән языла

Рөстәм ФАТЫЙХОВ:

Шекспирга омтылып яшибез

Түбән Кама татар драма театрына моннан ел ярым чамасы элек сәнгать җитәкчесе итеп Рөстәм Фатыйхов билгеләнгән иде. Бүген ул безнең кунагыбыз.

Түбән Кама драма театры – җөмһүриятебездә иң яшь театрларның берсе. Шулай да, аның кечкенә генә булса да, үз тарихы бар инде.

– Театр 1990 елны Түбән Кама "Нефтехим" берләшмәсенең театр студиясе буларак барлыкка килә. Аңа Минзәләдән күчеп килгән Анатолий Богатырев нигез сала. Беренче спектакльләрен Туфан Миңнуллин әсәрләре буенча куялар. 1994 елны ул шәһәр театры булу дәрәҗәсенә ирешә.

– Белүемчә, сез бирегә Минзәлә, Әлмәт театрларында эшләп, бу өлкәдә шактый тәҗрибә туплап килдегез.

– Эшкә тотынганчы ук шәһәр хакимияте белән сөйләшеп куйдым. Бу театр Түбән Кама шәһәренә лаеклы булсын, дидем. Өч ел эчендә республика театрлары дәрәҗәсенә күтәрергә, биш елдан чит илгә алып чыгардай спектакль куярга вәгъдә иттем.

Кыскасы, Париждагы бөтендөнья театр институты тарафыннан дөньядагы иң шәп алты режиссерның берсе итеп танылган Анатолий Васильев төзегән Мәскәү экспериментал ь театры үрнәгендә театр төзүне максат итеп куйдым.

– Димәк, сез ул театр эше белән якыннан таныш инде.

– Әлбәттә. Мин бит 80 нче елларда читтән торып Мәскәүдә, ГИТИСның эксперименталь төркемендә укыдым. Соңга таба җитәкчем Анатолий Васильев булды. Укуымны тәмамлап,Васильев җитәкчелегендәге театр белән контракт төзедем дә, чит илләргә чыгып киттем. Ике ел буе Аурупа һәм Американың 14 илендә булып, итальян драматургы Луиджи Пиранделоның "6 персонажей в поисках автора" исемле әсәре буенча куелган спектакль күрсәтеп йөрдек. Һәр илдә аларның спектакльләрен карадык, фестивальләргә килгән башка ил театрлары белән дә таныштык.

Безнең илдәге театрлар социалистик реализм кысаларында бәргәләнгән чакта, чит илләрдә төрле эслүб-стильләр чәчәк аткан. Ә безгә менә хәзер генә шул баскычларны үтәргә туры килә.

– Сез үрнәк итеп алган Васильев театрының төп асылы нидән гыйбарәт соң?

– Ул Аурупа театрының тышкы формасын урыс театрының тирән кичерешләре белән кушып, синтез тудырды. Актердан сәхнәдә чынчынлап яшәү, хисләр белән януны таләп итә. Уенга да урын калдыра. Бар нәрсә импровизациягә корыла.

Мин дә шундый театр төзү нияте белән эшкә алындым. Аурупаның иң алдынгы аһәңен тормышка ашырасым, татар тамашачысын да элеге халыклар ирешкән сәнгать табышлары белән таныштырасым килә. Әмма җүләрләрчә түгел, татар тамашачысының үзенчәлекләренә таянып. Безнең нигезебездә попса, ягъни популяр, кызыклы, күңелле тамашага тартылу ята. Ул Аурупада да шулай. Анда мюзикл өстенлек итә.

– Сез эшне нидән башладыгыз?

– Репертуардан. Иң әүвәл, Яңа ел әкияте, аннары Хәбир Ибраһимның "Бәхетле килен" исемле сатирик комедиясен куйдым.

Аннары балалар өчен Абдулла Әхмәтнең "Үги кыз"ын сәхнәләштердек. Әкренләп Юныс Сафиуллинның "Йөзек һәм Хәнҗәр"енә килеп җиттек. Аның темасы – бүгенге яра. Әйе, чичән сугышы бетте сыман. Әмма аны онытырга һич тә ярамый. Бөек Ватан сугышы да онытылмый. Җир йөзендә күпме гарипләр, толлар яши. Әфганны сөйлисе дә юк инде.

Сугышны башлавы гына җиңел, ә туктату бик авыр. Сугыш кешеләр язмышы, аларның йөрәкләре аша үтә. Димәк, сугыш туктамый, әле дә дәвам итә.

– Тамашачы премьераны ничек кабул итте?

– Искиткеч җылы кабул иттеләр. Күп рецензияләр чыкты.

– Алга таба нинәр эшләргә уйлыйсыз?

– Театрның киләчәге яшьләр кулында. 15-16 яшьлекләр өчен әсәр эзләдем һәм таптым. Ул – Әнәс Хәсәновның "Әти диясем килә" әсәре. Пьеса башта телесценарий буларак язылган иде. Яңа күзлектән чыгып, өр-яңадан эшләдек.

Әсәрнең төп героинясы – Рәдифә исемле авыл кызы. Ул үзе өчен бик авыр мәсьәләне чишә: яшәү мәгънәсен эзли һәм соңыннан, бәхет акчада түгел, дигән нәтиҗәгә килә. Спектакльдә продиджлар рухында язылган музыка тантана итә. Февраль аенда премьераны тамашачыларга күрсәтергә уйлыйбыз.

Алга таба Гаяз Исхакыйның "Өч хатын белән тормыш", Ризван Хәмиднең "Хан кызы"н кую да күздә тотыла.

– Моның өчен актерлар җитәрлекме соң?

– Актерлар элегә юк. Әмма без үз театрыбызда Казан театр училищесының махсус курсын ачтык. Дөнья театры тәҗрибәсен үземдә күмеп калдырмыйча, аны яшьләр белән уртаклашасым килә. Сәхнәдә эшлиләр дә, өйрәнәләр дә. Сәнгать академиясе белән килешү төзедек. Алар безнең өчен махсус курс җыячаклар. Шулай итеп әкренләп Шекспирга да килеп җитәрбез, дип ышанам.

Әңгәмәне ***Фирдәвес ӘҺЛИЯ*** *үткәрде.*

● Түбән Кама татар драма театры артистлары. Уртада – театрның баш режиссеры Рөстәм Фатыйхов.

(Ахыры. Башы 5 нче биттә).

Әдипнең этногенетик карашлары

әләгә: "30-40 миллионлык татар ыруглары..., милли исемнәрен үзгәртү белән тартышып, талашып, авызларын ачып калдылар. Башларына чүбек тутырган татар олуглары татарларга яңа исем бирү белән шөгыльләнделәр. Халкыбызның исемен татардан төрк-татарга күчерделәр. 1950 елларда шул ук хаин зурларыбыз – садрилар, гаязлар, бу исемне дә яратмыйча, төрк ясап куйдылар", – дип яза ул, бу этнонимнарның семантикалары турында бөтенләй оныта, бәлки сүзнең формасын һәм эчтәлеген аера белмидер.

Гаяз Исхакыйның төрки-татар сүзен куллануы гына түгел, тирән фәлсәфи фикерле әсәрләрен, барлык төркиләргә аңлашырлык итеп, иске төркидә язуы да Л.Каранга аңлашылмый. Бу фактны ул "Ике йөз елдан соң инкыйраз" әсәрен язган әдибебез үз гомере эчендә милләтебезне инкыйразга таба өстери торгач, бу инкыйразны 100 ел эчендә барлыкка чыгарырлык зур хезмәтләр эшләп китте. Ильминскийның рухы бик шат булгандыр, чөнки аңа ярдәм итте ул", – дип үзенчә бик "каты тамгалый", Ильминскийның татар этнонимын куллану мәсьәләсендә Исхакыйга түгел, ә менә нәкъ Л.Каранның үзенә тартымлык күрсәтүен аңламый ул.

Л.Каран, Г.Исхакый һәм С.Максудиларны тарихи наданлыкта гаепләп, Алтын Урданы торгызып, аның эчендә кемнәрне татар исеме белән берләштереп, бер бөек халык итәргә уйлый соң? Аныңча, менә кемнәргә "Алтын Урда татарлары диярге ярый": 1) Казан татарларына, 2) Кырым татарларына, 3) Башкорт татарларына, 4) Буҗак.., 5) Кавказ.., 6) Ногай.., 7) Казакъ.., 8) Каракалпак.., 9) Хива.., 10) Үзбәк татарларына. Шунысы игътибарга лаек, Алтын Урданы бары үзенеке генә итеп өйрәнү, җай туры килсә, үзенеке итеп кенә кире кайтару уе белән янучылар татарларда гына түгел, үзбәкләрдә дә бар (үзбәк үзен Алтын Урдага ныграк бәйләнгән дип уйлый, чөнки аның этнонимы да Үзбәк хан исеменнән), казакъларда да бар.

Укучыга сорау бирәсем килә: югарыда татар дип саналган халыклар арасыннан кайсысы, үз исеменнән ваз кичеп, йә татар, йә үзбәк, йә казакъ исемен алырга риза булыр иде икән! Аллам сакласын, берәр төрле тарихи вәзгыять туып, берәрсе Алтын Урданы андагы барлык халыкларны кушып, татар итеп, кире торгызу эшен башласын, ди. Акылы булган кеше җиңел аңлар, бу эш Л.Каран аңлаганча киң мәгънәдәге татарны гына түгел, хәтта тар мәгънәдәге татарны да юкка чыгаруның башы булыр иде. Аннан соң шуны да онытмаска кирәк: җимерелгән империяне торгызу уе – ул буш хыял. Үзбәктә мондый омтылыш күрсәтүчеләрне ялган патриотлар дип атыйлар. Бездә дә Ләбиб Каранны татарның ялган патриоты дип атап була: болгар-татарчылар, болгарчылар һәм дилетант татарчылар арасында аны, соңгысына каратып, тагын да конкретлаштырып, ялган татарчы дип әйтү дөреслеккә ныграк туры килә.

Хәзерге татарны яулап алучы монгол-татарлардан килгән дип расларга тырышу – ул татарны тарихи ана-йортсыз калдыру икәнен аңламый Л.Каран.

Гаяз Исхакый кебек бөек шәхесләр турында сөйләгәндә Л.Каранның гаҗәеп буталчык карашларын телгә дә алмаска булыр иде. Ләкин безнең көннәрдә дә 2-3 тарихчының, 1-2 әдәбиятчының, татарның барлык күренекле тарихчылары карашларын санга сукмыйча, урыс һәм Көнбатыш тарихчыларының дилетант татарчылыгына, Л.Каранның ялган татарчылыгына ияреп китүе күзәтелде. Шуңа күрә Л.Каранны, кызым сиңа әйтәм, килене син тыңла, мәкаленнән чыгып, принципиаль тәнкыйтьләү актуаль санала. Мин үзебезнең дилетант ялган татарчыларга тарихи чыганаклар белән генә эш итәргә түгел, Ш.Мәрҗани, Риза Фәхретдин, Г.Әхмәров, Й.Акчура, З.Вәлиди, Һ.Атласи, М.Худяков, Г.Гобәйдуллин, Т.Дәүләтшин, Н.Воробьев, С.Максуди, Г.Исхакый кебек элекке тарихчыларыбыз, хәзерге барлык юньле тарихчылар хезмәтләрен укып карарга тәкъдим итәр идем.

Шулай итеп без Гаяз Исхакыйда һәрбер бөек әдипкә хас сыйфатларны таба алабыз, аның тирән фикерле сәясәтче булуын, сәясәтче буларак үз халкы вәзгыятен зур панорамада күреп эш итә торган тарихчы булмыйча кала алмавын зур канәгатьләнү белән икърар итәбез.

Без биредә Гаяз Исхакыйның этногенетик карашларына ачыклык кертергә тырыштык. Бу яктан караганда, ул болгар-татарчы булып кала һәм, сәясәтче буларак, яулап алучы монгол-татарлардан түгел, ә нигездә җирле төркиләрдән (Болгар дәүләте чорында алар болгар этнонимын ала башлаганнар) формалашкан татарның киләчәге булсын өчен көрәшә. Якты киләчәкне булдыру өчен, беренче планга татарларның килмешәк булмавын аңлату, башка халыклар белән, бигрәк тә төркиләр белән дуслыгына, хезмәттәшлегенә таяну зарурлыгын куя.

Гаяз Исхакыйның "Ике йөз елдан соң инкыйраз" әсәрендә "Шулай итеп бу гасыр да үтеп китте. Егерменче гасыр башланды. Бу гасыр безгә ни бирә?" дигән сүзләренә әйләнеп кайтып, әйтергә кирәк: Шулай итеп бу гасыр да үтеп бара. Егерме беренче гасыр җитеп килә. Бу гасыр безгә ни бирер? Гомумән, төркиләрне, төрле татарларны, болгар-татарларны нинди язмыш көтә? Без язмышка ышанып утырырбызмы, әллә безгә барлык юнәлешләр буенча да халкыбызны тергезү, саклау һәм үстерү чараларын эзләргә, табарга, аларны гамәлгә кертә барырга кирәкме? Бу юнәлештә без кулдан килгәнне эшләргә әзерме?

Гаяз Исхакыйның этногенетик карашларын өйрәнү, бу карашларның каршылыклар аша үсеп баруын аңлау да безгә югарыда куелган сорауларга дөрес җавап табарга ярдәм итәр, дип уйлыйм.

Шагыйрь һәм публицист, Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге республика бүләге иясе Шаһинур Әхмәтсафа улы МОСТАФИНга 50 яшь тулды. Бүгенге көндә "Казан утлары" журналында бүлек мөхәррире булып эшләүче тынгысыз каләмдәшебезне, язучы әзтабарны, игелекле дустыбызны түгәрәк юбилее белән ихлас күңелдән котлап, ныклы сәламәтлек, яңа иҗади уңышлар теләп, укучыларыбыз игътибарына аның яңа язмасын тәкъдим итәбез.



Шаһинур ӘХМӘТСАФА

Хәтер мәйданында Ана сыкрый...

...1997 ел безнең өчен икеләтә истәлекле булды. Беренчедән, халык арасында зур абруй казанган, төрле кыйтгаларда-мәмләкәтләрдә яхшы билгеле булган "Казан утлары" журналының 75 еллык бәйрәмен бик матур итеп, 2 Бөтендөнья татар конгрессы ачылган тарихи көннәрдә тантаналы төстә билгеләп үттек. Аллага мең шөкер, тиражыбыз да күзгә күренеп үсә. 1998 елда 14 мең әбүнәчебез бар. Бу, үткән ел белән чагыштырганда, укучыларыбыз 2 мең кешегә артты дигән сүз..

Икенче зур сөенечебез: "Сигез бизәкле Сөлге" дигән документаль бәянемнең төп каһарманы булган Анага – сугышта сигез улын югалткан Фатыйха апа Әхмәдиевага һәм, аның кебек, балаларын яу кырында җуйган аналарга, олы кайгыларын уртаклашып, аларга тирән хөрмәт билгесе итеп, 1997 елның 22 июне иртәсендә Мамадыш шәһәре үзәгендә, ап-ак таштан мәһабәт һәйкәл куелды. Символик һәйкәл!..

Әлеге язмамда шушы вакыйгага киңрәк тукталып үтәсем килә.

Иң элек, бераз чигенеш ясап, һәйкәлне эшләтү тарихы белән таныштырыйк. Безнең Фатыйха апага һәм аның улларына кагылышлы кыйссабыз Мамадыш районы хакимияте башлыгы Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин кулына килеп эләккәч, ул аны эчке бер тетрәнү белән кат-кат укып чыга да, җитди карарга килә: 'Фатыйха түтигә һәйкәлне, һичшиксез, эшләтергә кирәк һәм тиз арада! Шундый олы хезмәтне тиешле югарылыкта башкара алучы яхшы сынчыны да табарга кирәк!.. Район җитәкчесенең үтенечен безгә – Казанда яшәүче мамадышлыларның якташлык җәмгыяте җитәкчеләренә – хаким урынбасары Шамил Нурулла улы Хәсәнов җиткерде. Җәмгыятьнең март аенда булган киңәйтелгән утырышында әлеге мөһим мәсьәлә һәрьяклап җентекләп тикшерелде һәм зур яклау тапты. Скульпторлар арасыннан үзенең күпсанлы монументаль хезмәтләре, иҗади фикерләү осталыгы белән танылган Альфред Хәйрулла улы Әбдрәшитовны сайлап алдык. Заманында ул татарлар арасыннан иң беренче Советлар Союзы Каһарманы Гыйльфан Батыршинга, легендар очучы Мәгүбә Сыртлановага, каһарман шагыйрь Нух Идрисовка, полк улы – Социалистик Хезмәт Каһарманы Камил Шакировка, күренекле язучы Газиз Кашшаф-Үзилегә һ.б. һәйкәлләр койган һәм куйган кеше. Үзе генә түгел, уллары Альберт һәм Гадел белән бергәләп иҗат итә Әлфәрит оста (без аны яратып шулай атап йөртәбез). Хәләл җефете Луиза ханым да – аның иң ышанычлы киңәшчесе, ярдәмчесе. Җыеп кына әйткәндә, агачка, ташка, металлга бөтен гаиләләре белән күмәкләшеп җан өрәләр алар!

Әлфәрит оста эшләгән һәйкәл проекты Мамадышта хуплау тапкач та, җиң сызганып эшкә тотынды әтиле-уллы сынчылар. Аңарчы Мамадышка барып һәйкәл куеласы паркны яхшылап карап кайттылар. Районның талантлы яшь архитекторы Рамил Миннеханов белән бергә, шул парктагы "Хәтер мәйданы"н халык күңелен җәлеп итәрлек өр-яңа төсмерләр-символлар белән баету чараларын күрделәр. Район хакимияте һәр яңа башлангычны күтәреп алып, аларны тормышка ашыру өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырды. Мәйданпаркны үзгәртеп коруда ПМК-88 төзү оешмасы һәм шәһәр коммуналь хуҗалыгы эшчәннәре (җитәкчеләре – Фәргат Гаянов, Салих Сәләховлар) зур тырышлык-фидакарьлек күрсәттеләр. Нәтиҗәдә, шәһәрнең үзәге танымаслык булып үзгәрде, матурайды. Паркны яңа төр агачлар белән баетуда Мамадыш урман хуҗалыгының баш урманчысы Илдус Әхмәтов биредә һәр эшнең барышын даими игътибар үзәгендә тотты, өзеклеккә, сыйфатсызлыкка юл куймады.

Скульпторлар да үз сүзләрендә нык тордылар: 20 июнь көнне Казаннан Ана һәйкәлен Мамадышка алып кайтып, 21ендә аны "Хәтер мәйданы"на бастырып та куйдылар.

22 июнь иртәсендә – Хәтер һәм Матәм көнендә – әлеге һәйкәл янына районның төрле төбәкләреннән йөзләгән-меңләгән кеше җыелды. Алар арасында сугыш утларын кичкән ветераннар да, чал чәчле аналар да, тол хатыннар да бихисап иде.

Иртәнге сәгать 10. Ватанны саклаучыларны искә алу көненә багышланган митинг ачык дип игълан ителә. Хакимият башлыгы Әгъзам Гобәйдуллин, Фатыйха апа Әхмәдиеваның оныгы Мәрзия апа Бикмурзина, сугыш һәм хезмәт ветераннарыннан Любовь Штягина, Дмитрий Манунов белән берлектә, Ана һәйкәлендәге ак җәймәне сак кына җиргә төшерәбез...

● *Фатыйха Әхмәдиева һәйкәле янәшәсендә – оныгы Мәрзия Бикмурзина, Фән Вәлиәхмәтов.*

Менә шушы мизгелдән Фатыйха апа Әхмәдиеваның икенче гомере башланды. Шагыйрь җанлы Әлфәрит оста үзенең уллары белән Ана образын бик яратып иҗат иткән. Сугышта сигез улын югалтса да, горурлыгын һәм сабырлыгын, матурлыгын һәм батырлыгын җуймаган мәгърур Ана безнең каршыда, Хаҗга барырга җыенгандай, ап-ак киемнән басып тора.

Карашы еракка – сигезенче улы, соңгы өмете – Әгъләметдине ятып калган Көнчыгышка төбәлгән аның. Ана инде улының ничек һәлак булуы турында аның җан дусты, полкташы Мәгъсүмҗан Юнысов авызыннан ишеткән. Тугрылык символын чагылдыручы йөзекле сул кулы белән соңгы улының ядрәләр тишкән кызыл йолдызлы пилоткасын (аны яу кырыннан Мәгъсүмҗан солдат алып кайткан була) күкрәгенә-йөрәгенә кысып тора ул. Уң кулында – болыннан яңа өзелгән саф чәчкәләр... (Хыялында гына булса да, улларының сугыш яланнары буйлап сибелгән бинихая кадерле каберләренә туган як гөлләрен куярга теләгән ул!)

Ананың Су-Елга болыны буйлап Урта Кирмәнгә кайтып килеше сурәтләнә һәйкәлдә. Чөеп бәйләгән чигүле ак яулыгын, озын ак күлмәге итәкләрен җилфердәтеп, ак күбәләк кебек оча ул болын түреннән. Киң күңеллелеген, мәрхәмәтлелеген чагылдырып, ике якка урталай аерып тараган ап-ак чәчләре, колакларындагы асыл алкалары, дисбене хәтерләткән муенсасы үзенә бик тә килешеп тора. Әмма Ана инде бу Җиһанны оныткан. Гәрчә, җыйнак гәүдәсе әлегә фани дөньяда булса да, тынгысыз олы җаны инде күптәннән балалары янында – оҗмах түрендә.

Һәйкәл янында ак мәрмәр ташка уеп язылган утлы сүзләр, гайрәтле ялкын телләре кебек, бәгырьләрне көйдерептелеп ала:

Улларым сугыштан кайтмады,
Кайтты тик: "Көт!" – дигән хатлары....
Өзелеп котәм мин һәр таңны -
Улларым әйләнеп кайтканны!!!

Шунда ук яу кырында шәһит киткән сигез улының җавабы да урнаштырылган:

Чыгар Кояш, сибәр нурын -
Бездән сәлам шул булыр!

Могҗиза дисәң, могҗиза: Анага һәйкәл ачкан сәгатьләрдә, моңарчы ике көн буе берөзлексез сибәләп торган яңгыр болытларын таратып күк йөзендә Кояш балкыды һәм Матәм митингы тәгәлләнгәнче халыкны шифалы-җылы нурлары белән коендырып торды...

Митингта бик күп кешеләр чыгыш ясады. Шулар арасында иң тәэсирләндергәне, мөгаен, атаклы җырчы һәм тальянчы Фән Вәлиәхмәтовның "Герман көе"н башкаруы булгандыр. Яу кырына киткән бертуган Фәттаховлар образын гәүдәләндереп, сигез куплетлы итеп җырлады ул әлеге үзәк өзгеч җырны:

Биек икән тавыгыз,
Куе икән талыгыз...
Без китәбез, туганнарым, –
Бәхилләшеп калыгыз...

Юк шул, берсе дә әйләнеп кайта алмый туган нигезгә әлеге каһарманнарның. Бары тик кара мөһерле кайгы кәгазьләре генә кайта бер-бер артлы...

Митинг барышында Фатыйха апа образын Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, табибә Саҗидә Мостафина-Әхмәтгалиева гәүдәләндерде. Аның башкаруындагы "Син кайтмадың" җыры (Сәхаб Урайский шигыре, Мансур Мозаффаров көе) шулай ук беркемне дә битараф калдырмады, күзләрне һәм күңелләрне мөлдерәмә моң белән тутырды.

Гүяки Ана бу җырны үзенең һәр улына атап җырлый иде...

Укучыбыз ялгышмасын: бу көнне митинг Фатыйха апа Әхмәдиева белән аның сигез улына гына багышлап үткәрелмәде. Районнан Бөек Ватан сугышына китеп, яу кырында мәңгелеккә ятып калган солдат-офицерлардан 7 меңгә якын кешене тирән юксыну хисләре белән искә алдылар чыгыш ясаучылар. Алар арасында Татарстанның иң беренче Советлар Союзы Каһарманы Гафият Нигъмәтуллинның кызы Гөлия Мөхәммәтҗанова да бар иде.

– Әтиебез тиздән бирегә, шушы мәйданга, мәһабәт һәйкәл булып кайтып басачак. Бер аңа гына түгел, районыбыздан чыккан тагын өч батырга – Советлар Союзы Каһарманнары Иван Максимовка, Михаил Москвинга, Михаил Просвирнинга да куелачак шундый бюст-һәйкәлләр. Ана һәйкәле янәшәсендә, аның уллары кебек, үзләренең лаеклы урыннарын алачаклар әлеге каһарманнар, – диде ул.

– ... Безнең Фатыйха әби һәйкәле янәшәсендәге ак мәрмәр ташта яу кырында шәһит киткән сигез абыемның да алтын хәрефләр белән язылган исемнәрен күрү мине аеруча тетрәндерде, – диде Мәрзия апа. – Гүяки аларның җаннары бүген, ерак юллар-еллар кичеп, әниләре янына кайтып, мәңге аерылмаслык булып, аңа сарылдылар!

Ул район музеена Фатыйха әбисенең улларына багышлап тукыган сөлгесен бүләк итте.

Сөлге димәктән, шагыйрә Гөлшат Зәйнашева Анага багышлап махсус баллада да иҗат иткән иде (Әхмәт Гадел көе).

Җидегән йолдыз нигә күзләремә
Сигез йолдыз булып күренә?
Йолдыз булып кайткандыр батырлар
Туган якның зәңгәр күгенә!

Якташыбыз, Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев аны башкарганда чал аналарны елатты.

... Борынгы Мамадыш туфрагында, Татарстан тарихында беренче буларак, Анага һәйкәл куелды. Киләчәктә дә Мамадыш җирендә яңадан-яңа һәйкәлләр куелыр! Чөнки район үзәгендә паркның икенче өлешендә әдәбият-сәнгать әһелләре аллеясын булдыру хыялы белән дә яна хәзер мамадышлылар. Анда инде Шәйхи Маннурның Бакый ага Урманче эшләгән һәйкәле балкып тора. Кем белә, бәлкем, тиздән янәшәсендә милләтебез зыялыларыннан Колмөхәммәт, Мәхмүт Бөдәйли, Фәрит Солтанбәков, Заһидулла һәм Фәрит Яруллин кебек олуг якташларыбызның мәрмәрдә, бронзада гәүдәләндерелгән җанлы сыннары да торып басар?

● ***Шаһинур Әхмәтсафа (Мостафин).***

Альберт БИКТИМЕРОВ фотолары.

Бикә РӘХИМОВА

"Коткару килер, көтегез!"

(Хикәя)

Әгәр Нурания Габбасовнадан: "Ничек булды соң ул татар мәктәпләренең ябылу хәлләре?" – дип сорасалар, ул: "Моны бер җепкә тезеп кенә сөйләп тә булмыйдыр инде..." – дияр иде. Әгәр дә тезә башласаң, шул бернәрсәгә – әлеге дә баягы, урысча гына булган югары уку йортларына барып төртеләсең икән. Чөнки, башта шунда укырга кергәндә имтихан бирү өчен җайлы була дип, татар мәктәпләрендә математика, физика, география ише фәннәрне урысча укытуга күчтеләр. Аннары, ничектер үзеннән-үзе килеп чыккандай, татар мәктәбендә бер-бер артлы урысча гына укучы сыйныфлар ачылып, алар ишәя башлады. Ә бер елны исә алар мәктәбендә татарча беренче сыйныфка ундүрт кенә бала җыелган булып чыкты. Нурания Габбасовна "бишләр" белән "алтылар"да ана теле һәм әдәбияты укытучысы Сәрия Зәкиевна янына, сыйныф бүлмәсенә керде, икесендә дә дәрес юк – "тәрәзә" икән.

– Күрдегезме? – диде Нурания Габбасовна Сәрия Зәкиевнага.

– Нәрсәне?

– Татарча беренче сыйныфка ничә бала килгәнен күрмәдегезме?

– Ә-ә... нишлисең инде...

– Соң, хәзер булса да, киләсе ел өчен ата-аналар белән эшли башларга кирәк! Әллә түбән сыйныф укытучылары эшләсен, дип торасызмы?

Нурания Габбасовна, дәрес аңлаткандай, бер баштан икенче башка йөри башлады, бит алмалары янып чыкты, кара күзләреннән чаткылар очты. Сәрия Зәкиевна, бераз эндәшми торганнан соң, болай диде:

– Нурания Габбасовна, мин сезнең янга кермәкче идем әле. Беләсезме, минем сыйныфтагы (ул алтынчы "А"да сыйныф җитәкчесе иде) Бәдриев Наилнең әнисе килде, әйтимме ул нәрсә ди?

– Йә-йә, нәрсә ди инде ул? – Нурания Габбасовна, Габдулла Тукай томлыкларының берсен, укытучы өстәленнән алып, ике куллап чытырдатып тотты, әллә ул хәзер ишетәсе сүзнең авырлыгыннан шагыйрьнең китабына тотынып, котылып калырга тели, әллә китапны ялт итеп ачып, аннан берәр шигырь белән җавап бирергә уйлый? Алай дисәң, андагы шигырьләрне чатнатып яттан белә...

– Бәдриев Наилнең әнисе әйтә... Наилне урысчага күчерергә телим, ди...

– Наилнеме?! Синең алтын баганаңны? Отличникны? – дулкынланудан Сәрия Зәкиевнага "сез"дән "син"гә күчкән Нурания Габбасовна лып итеп урындыкка утырды, егылганчы утырыйм, дигәндер, күрәсең. Шуннан, телсез калгандай, эндәшмәде. Менә кая таба бара икән бит эшләр!.. Ә ул беренче сентябрь җиткәнче мәктәпкә дә бара алмады, еракта, ашказанын дәвалап, су эчеп йөрде. Хәлләрне күреп, белеп торса да, нәрсәгәдер ышанды. Ул да, бәлки, түбән сыйныф укытучыларына ышангандыр? Минем эшем югары сыйныфларны укыту, тиешле кеше кайгырсын, дигәндер? Әллә ата-аналарга ышандымы соң? Әллә соң, хөкүмәткә, коммунистлар партиясенә ышандымы? Әйе-әйе, милли культуралар чәчәк ата, дип ничек кенә сөйләнелмәде дә, ничекләр генә итеп язылмады... Чәчәк аткандырмы, юкмы, ә менә яфраклары гына түгел, тамырларына кадәр корый башлавы хак икән. Йөр менә шифаханәләрдә, үз хасиятеңне хасиятләп. Хәер, берүзе нишли алыр иде, әнә, Сәрия Зәкиевна да сүрелгән, сүнгән кебек күренә.

– Нурания Габбасовна, сезнең дә ударниклар бар бит, ә Гыйльфановның бер генә "дүртле"се, Калганнары – "биш" бугай, әйеме?

– Әйе-әйе... – Нурания Габбасовна авырлык белән генә бастырулы йокыдан айнып килгәндәй җавап бирде, ә эчендә ут кайный.

– Сезнекеләр дә сыйныфны сүтә башласа?..

Тәнәфес булган икән, кабинет ишеге ачылып, ике кыз бала башларын суздылар:

– Исәнмесез... Сәрия Зәкиевна, дәрес буламы?

– Була, була. Нишләп булмасын?!

Укучылар букча-әсбапларын калдырып чыгып киттеләр. Шыпын гына тагын ике кыз керде дә, болары чыгып китмәде, урыннарына утырып, әкрен генә сөйләшә башладылар.

Нурания Габбасовна, ашыгып, үз кабинетына чыкты, бүлмәгә укучылар керде, әмма укытучының уйлары чуалган, дөньяда тотрыклылык беткән иде.

Нурания Габбасовна җитәкләгән сыйныфка бөлане яхшы укучы түгел, ә көчкә-көчкә "өчле"гә тәгәрәп килүче китерде. Бу очракта "сөйрәлеп" дигән сүз кулланылса да, тәгәрәп дип әйтү дөресрәк булыр кебек, чөнки "өчле", "икеле"ләрнең хуҗасы кечкенә генә, түгәрәк кенә, җитез генә, сөйкемле генә Гөлгенә исемле кыз иде. Беркөнне менә шул Гөлгенәнең әтисе белән әнисе килгәннәр.

– Нурания Габбасовна, сезгә киңәшкә килгән идек, – дип башлады сүзен Гөлгенәнең әтисе. Әтисе дә кызы кебек кече күңелле, юма телле иде. Ләкин иренең сүзне озак әвәләп йөртәчәген сизеп, ахрысы, сөйләшүгә хатыны катнашты да, кырт иттереп:

– Гөлгенәне Галина Сергеевна классына күчерәбез, сөйләштек инде, – диде.

Ишетәсең бармы?! Сөйләшүнең мондые да була икән бит әле! Гүяки күчерү урыс сыйныфына күчерү турында бармый, ә Нурания Габбасовна начар укыта да, шунлыктан баласын икенче укытучыга бирә. Бөтен гәүдәсенә, туры кизәнеп, күсәк белән суктылармыни, укытучының нечкә, юка гәүдәсе әллә ничек авырайды, куллары дерелдәде, алдында яткан журнални бер ачты, бер япты, чәчләрен төзәтте, кульъяулыгын алып уч төпләрен сөртте, шуннан соң гына әллә кайдан, ерактан килгән саңгырау тавыш белән:

– Хәл иткәнсез икән инде, мин начар укытам икән бит, – дип, кузгалып, кабинетыннан чыгасы итте.

Тегеләрне чыгарып җибәргәч, янәдән кабинетына керде, әкрен генә озаклап елады, аннары күзләрен йомып уйга чумды. Ләкин шунда бөтен дөнья әйләнә башлады. Шул түгәрәктә бер якынаеп, бер ерагаеп әтисе белән әнисе дә әйләнәләр, гүя кызларына ярдәмгә килмәкчеләр. Тик болай ярамый иде, Нурания Габбасовна тиз генә күзләрен ачты, йә кабинетыңда берүзең егылып ятарсың.

Аяк астына карамаска, як-якка борылмаска тырышып, әкрен генә киенде дә кайту юлына чыкты. Директорга, укыту бүлеге мөдирләренә керергә хәле дә юк, кермәстә. Алар бу хәлне беләләр, билгеле, киңәшләшүне кирәккә санамаганнар...

Бераз вакытлар үткәч, мәктәп директорына тырышып-тырышып гел урысча гына сөйләргә туры килде, акценты барыбер сизелә иде, шул акценттан оялып, тагын да күбрәк бутала иде, ахрысы. Әйе, шундый татар акцентың белән урысчага күчеп баручы мәктәптә директор булып торырсың, кәт, булды ди! Директорны, озак та үтмичә, физкультура укытучысы итеп төшерделәр, ә менә укыту бүлеге мөдирләренең кая китеп югалганнарын да белми калганнар. Бу хәлләр Нурания Габбасовна инсульт белән егылып авырып ятканда булды. Бер ел эшләмәде шул. Ходайның рәхмәте, әкренләп терелде, аякка басты. Начаррак йөри башлаган кулын ышкый-ышкый, уа-уа тәки көйгә китерделәр, яшь тән, сихәте үзендә шул. Иренең кешелеклелеге, аңлый белүе көйгән үләнгә яуган яңгыр ничек булса, шулай ярдәм итте. Авырган чагында укучылары һәр көнне диярлек килеп йөрделәр янына, яңа дирекция дә, бу хәлне күреп, аның хөрмәтле укытучы икәнлеген аңлаган, күрәсең. Ләкин мәктәптә татар сыйныфлары барыбер бетте, Нурания Габбасовнаның соңгы укучылары татар мәктәбен тәмамлады дигән соңгы аттестатны алучы булдылар. Шул ук укучылары, чирләгән чагында янына килгәндә: "Гөлгенәләр өйләрендә урысча сөйләшәләр ич алар", – диләр иде. Алар моның белән әллә укытучыларын юатмакчы булдылар...

Нурания Габбасовна хастаханәдә чирләп ятканда аягы сызлаган бер әрмән хатынын күршесенә салганнар иде. Ул әрмән хатыны каян килеп чыккан диген әле. Аларның ир-атлары ул заманнарда, төркем-төркем булып, халык телендә "шабашниклар" дигән исем алган бригадалар төзеп, сезонлы эш эшләп йөриләр иде. Шулай йөреп, иркенгә киткән көтү сыман, тегеннән-моннан үлән-чәчәк өзгәләп, ягъни әле бер ялгыз хатынга, әле икенче хатынга йортка кергәләп йөрсә дә, әрмән ир-аты үзенең илендә калган гаиләсен акча белән тәэмин итеп, аерылышу турында уена да кертмичә яши бирә, кайвакыт хатыннары, килеп, тикшергәләп тә китәләр икән. Теге аягы сызлаучы хатын да шундыйларның берсе булып чыкты. Үзләрендәге җылы, коры, җәннәт һавасы кебек һавадан аерылып, монда юешкә килеп төшкәч сызлый башлаганмы аягы, кем белә инде анысын. Менә шул хатын белән Нурания Габбасовна һәм, билгеле, тагын да башка сырхаулар яткан палата ишеге беркөнне "тихий час" дигән бервакытта киң итеп ике якка ачылып китте дә, шаулап-гөрләп өч әрмән килеп керде. Үз телләрендә кагалар гына "барабанны", гүяки аларның шулай кычкырып-кычкырып сөйләшүләрен палатадагы авырулар зарыгып көтеп торганнар. Аннан палатадагы бердәнбер өстәлне хатынның караваты башына китереп куйдылар да, җилкәләренә аскан зур кара сумкаларыннан чыгарып, төрле ашамлыклар тезеп салдылар. Шуннан соң башка авыру хатын-кызларны да: "Ай красависа моя, садис угашатся" – дип, – кайсын – торгызып, кайсысына урынына китереп, ипи өстенә итләр, сырлар белән рәттән әллә нинди баллы һәм әле тагын ачы тәмләткечләр кыстырылган бутерброд кебек әйберне кулларына ирексезләп-ирексезләп тоттыра да башладылар. Болар, беренче күргәндә таныш, ә икенче күргәндә дус, дигәнне дә уздырып җибәрделәр, гүяки беренче күргән кешеләре үк җан дуслары, комачау гына итмәсеннәр... Әй, сөйләштеләр рәхәтләнеп, күңелләре булганчы... бик теләгән кешегә шул арада әрмән телен өйрәнеп калырлык булды ул әкәмәт хәл. Әрмәннәр ял сәгате дигән вакытта шар ярып сөйләшеп ашап утырганда палата табибы әкрен генә ишекне ачып карады да, иплән кенә кире япты... Болар палатада шулай шау-шу ясап чыгып киткәч кенә, кайберәүләр канәгатьсезлекләрен белдерделәр: беспорядочность какая!..

Менә, менә нинди холыклар үстәсең икән татар халкына, ә! Әрмәннәр, урыс телен ничек булдыралар, шулай сөйләшәләр, ә шуның өчен оялып торырга, дулкынланырга, борчылырга башларына да килми, уйларына да керми, үз туксаннары туксан.

Рөхсәт ителгән сәгатьләрдә Нурания Габбасовнаның ире Нурислам да хәл белергә дип палатага керә, моның өчен аның аерым рөхсәт кәгазе дә бар. Әмма ул бөтенләй башкача. Әкрен генә, як-ягына карамый гына керер, әкрен генә исәнләшер (барысы белән дә урысча...), аннан, урындык алып, хатыны янына килеп утырыр да, әкрен генә сөйләшеп алырлар, шуннан китергән әйберләрен хатыны тумбочкасы өстенә тезеп куяр да, тагын кайчан киләсен әйтеп, саубуллашып, исәнлек теләп, шулай ук әкрен генә чыгып китәр. Нурания Габбасовна ире киткәннән соң кулларын юып, күчтәнәчләрең чиста кәгазьләргә салып, палатадаш авыруларга таратып чыгар, кемнең дә сөрткәнен көтмичә, исән кулы белән пакь иттереп тумбочкасы өстен дә сөртер, үзенең хәле хәл булганда да тора алмаучыларга булышыр. Терелеп чыктым дигәч тә әле, ул уң ягынарак авышып, сул кулына таяк тоткан кеше сыманрак йөрде, аннан, Ходайга шөкер, бераздан тигез йөреп китте китүен, әмма ул авыру белән шактый матавыкланырга туры килде.

Менә шул көннәрендә ул озын-озак уйларга бирелеп ята иде. Уе мәктәбе тирәсендә бөтерелә, укучылар, алар янында ата-аналар – бөтенесе бергә җыелгандай була. Менә шулар белән бәхәсләр "кора". Нишләп болай килеп чыкты соң әле бу? Туган мәктәбең бетүгә кем гаепле? Басып алучымы, әллә милләтең үземе? Милләтме соң ул безнең халык? Тьфү-тьфү, авызыңнан җил алсын, сандугач кебек сайрап торган теле булган халык ничек милләт булмасын инде?! "Җидегән йолдыз җиде әйләнә җиде төн уртасында..." Шулай матур итеп әйтә белү сирәк бит ул. Тагын, борынгыдан калган туган җире, туган иле бар халкының... Әй-йе. Тукта әле, әйтик, милләт үзенең кимчелекләрен белсә, төзәтеп буладыр ич ул җитешмәгән, китек якларны? Аерым кеше үзенең кимчелегеннән арына ала ич. Нурания Габбасовнаның ире Нурисламның бер танышы бар. Идрис исемле. Шул Идрис беркайчан да авызын зур ачып кычкырып көлми, елмая гына. Шулай бервакыт, сүз иярә сүз чыгып, Нурания Габбасовнага ире бу хәлне аңлатып бирде. Идрис кычкырып көлсә, нишләптер бик ямьсез булып укмашкан урт итләре күренеп, бөтен чибәрлеген юкка чыгара, сызып ташлый икән. Бик озак вакытлар көзге алдында күнегүләр ясарга, һәм үзенә кычкырып көләргә ярамаганлыгын баш чүмеченә ныклап киртләп салып куярга туры килгән аңа. Менә шул ясалма рефлексын табигыйга әйләндергән адәм баласы. Бу бит физик күнегү генә түгел, ә акыл белән үзеңне идарә итү дигән сүз. Тырышсаң, була икән лә.

(Дәвамы бар).

● Әмирхан Еники.
Николай СЕДОВ фотосы.

Бик күптәннән бирле Әмирхан Еники турында язарга хыялланып йөри идем. Тик нәрсәдер тоткарлап торды. Үземнең уемча шулдыр – истәлекләрне, гадәттә, соңлабрак, кайчак артык соңлап язалар. Мин тәвәккәлләдем һәм бу истәлекләрне, очрашуларны язып, бастырып чыгарырга Әмирхан абыйның фатихасын алдым. Әмирхан абыйга риза булганы өчен рәхмәтлемен. Мин аңарга ныклы исәнлек, уңышлы иҗат һәм 100 яшькә җитәрлек гомер телим.
Йөзне узгач, үз хәленнән чыгып, аннан соң тагын ничәмә-ничә еллар яшисен үзе белер дип уйлыйм.
Бу истәлекләрне күңелемдә якты хатирә булып калган очрашуларга багышлыйм. Әмирхан абый – безнең татар халкының зурдан-зур, бәясен биреп бетереп булмый торган милли байлыгы. Сугыш еллары алдыннан, сугыш вакытында исән кала алган. Атаклы морзалар нәселеннән ул.
Таланты искиткеч күпкырлы, бай.
Бу язмаларым белән Әмирхан абыйга булган ихтирамымны белдермәкче идем.
Барып кына чыкса ярар иде...

Әмирхан морза могҗизасы

Дубылтыда очрашу

Мин инде вак-төяк хикәяләр язу белән "агуланган бер бәхетле-бәхетсез бәндәгә" әверелеп, Рига каласында ике төрле иҗат белән сугарылып яшәүче, 50 яшькә җитеп килүче бер татар хәрбие идем. Яңа ракеталар төзү өчен, ракетаның эченә урнаштырыла торган, каты ягулыктан ясалган зарядлар уйлап чыгарып, үземчә туган илем СССРга "иң шәп ракеталар ясаучы" галимнәрнең берсе идем мин ул чакта. Докторлык диссертациясен яклау өчен миңа каршы "Мәскәү тулы" галимнәр белән "фәнни сугыш"та көннәр, айлар, еллар уза. Шул ук вакытта Казан каласында чыга торган сатирик "Чаян" журналында инде минем байтак кына юмористик хикәяләрем басылган. 1981 елның маенда "Казан утлары" журналында "Карбыз сугышы" дигән зур хикәям дә дөнья күрде. Бу хикәяне бастыруда язучы Фаил Шәфигуллинның ярдәме бик нык тиде. Инде ныклап язып китеп, татар язучысы булырга хыялланып, вакыты-вакыты белән "ракета фәне"нә кул селтәп, татар укучылары өчен хикәяләр язып читтә яшәүче бер үҗәт бәндәмен...

1983 елның март урталары. Бер кичне фатирда телефон шалтырый. Алам. Таныш та, таныш та түгел тавыш, татарчалап мине сорый.

– Әйе, тыңлыйм. Зәки Зәйнуллин мин.

Күңел киң. Туган яклардан килгән кешеләрнең барысы өчен дә ишегем ачык булды минем. Чөнки кеше килүе минем өчен һәрвакыт шатлык.

– Танымыйсың, ахрысы? – ди телефон. – Равил мин.

Мин көләм.

– Равилнең кайсысы син? Минем Равил исемле дуслар, танышлар бик күпләр.

– Шаммас мин...

– Ә-ә, шулаймыни...

Башкортстанның танылган шагыйре Равил Шаммас! Мин аның белән Эстәрлебаш урта мәктәбендә 9-10 нчы сыйныфларда бергә укыган идем. Шаммас Эстәрлебаштан дүрт чакрымда урнашкан Уразай исемле мишәр авылыннан. Озын чандыр сор-гәүдә, дулкынланып торган зәңгәр сылт чәч, кып-кызыл бит, ике каткүзләр, озынчарак танау, ике катлы пыяла күзлек. Шаммас мәктәптә берләнбер күзлек кигән кеше иде ул чакта. Унынчыда бер өстәл артында бергә утырабыз: Шаммас, Әнвәр Хәсәнов, мин. Дивар кырында Әнвәр, мин уртада, Шаммас кырыйда. Укуга мин бик маһир. Бигрәк тә математика белән урыс теленнән. Болар – ике мишәр – күчерү исәбе белән мине урталарына утырттылар. Бездән алдагы беренче өстәлдә өч кыз: Рабига Мөхәммәтъярова, Ләлә Бәширова, Халидә Мөсәлимова. Әнвәрнең һәм минем жинел телдән өчесенә дә исем тагылган. Рабига, иң усалы – Ата Ябрәй. Ләлә (староста) – Ана Ябрәй. Халидәсе буйга кечкенә, үзе бик тә юаш – Бала Ябрәй. Халидәне буйга кечкенә дисәм дә, үземнең дә әлләни мактанырлык буй юк анысы. "Ваянный дело" дәресләрендә минем урын Халидә алдыннан гына, иң артта.

Шаммас унынчыда укыганда шигырьләр яза иде инде. Ыштан белән Уразай суында балык тотканы турында. Әнвәр аның шул шигырен тыңлады да, Шаммаска исем дә тагып куйды: ыштансыз Уразай шагыйре! Шул исем белән китте чыгып Равил мәктәпне тәмамлап. Шаммас тальянда да ярыйсы гына сыздыра. Тик укуга йомшак һәм... бик тә юаш иде үзе. Әнвәр белән миннән "күргәннәрен" Шаммас әле дә онытып бетерә алмый.

Бик теңкәсенә тигән чакларда Шаммас безне берәм-берәм тотып алып "акылга утырта". Безнен иң яраткан шөгыль – Шаммасның күзлеген мич башына яшерү иде. Күзлеген яшерсәң, тегенең күрүе чамалы – без аннан соң Равилне төрлечә "этлибез".

Телефоннан шалтыратучы шул Шаммас икән дә, Дубылтыда иҗат йортында икән. Кунакка чакырам моны үзебезгә.

– Юк, әле тиз генә барып булмас, – дип җаваплый бу. – Башкортстаннан без монда икәүбез. "Пионер" журналы редакторы Динис Бүләков та биредә. Иртәгә үзең кил безнең янга...

– Вакыт ягы ничек булыр бит. Эш күп. Иртәгә генә булырмы икән диюем...

– Кил син. Монда Казаннан зур язучыбыз Әмирхан Еники да бар. Синең аны күргәнең бармы?

– Юк.

– Кил, таныштырырмын...

Әмирхан Еники...

Әмирхан хикәяләре белән 10 нчы Мин аның тәмамлап армиягә барып сыйныфны башлаганчы ук мавыккан хезмәт итә хикәяләрне бик тә яраткан һәм ул укучымын. Бик нык ошыйлар иде алар миңа. Ничәмә-ничә еллар буена "Совет әдәбияты" журналын алдырып, шул журнал битләреннән иң беренче иттереп Әмирхан абыйның язганнарын эзләргә өйрәнгән бәндә идем инде.

Икенче көнне өйлә узгач, лекцияләр беткәч, букчага бер коньяк, бер акбаш, кабымлыклар салдым да киттем Дубылтыга.

Барып керсәм, Шаммаслар өйдә юк иде. Бер сәгать чамасы көткәч, Равил белән бергә таза гәүдәле, кара чәчле, зур авызлы бер башкорт кайтып керделәр. Икесе дә кызмачарак. Башкорты Динис Бүләков икән дә, чыгышы белән Агыйдел буеннан, Кинҗә Арсланов авылыннан икән. Күрешеп кул кысышкан уңайга Динис минем баштагы хәрби фуражканы салдырып алып үзенең башына киде дә, тотынды фойеда солдатча "строевой шаг" белән йөрергә. Ике администратор латыш хатыны аңарга күз генә сирпеп алалар да, үз эшләре белән мәшгуль булып, Динискә әһәмият тә итмиләр. Болар, күрәсең, язучыларның төрледән төрлесен күп күреп, аларга гаҗәпләнү планкасын узганнар инде.

Өскә күтәреләбез дә, өстәл хәзерли башлыйбыз. Шешәләрне ачып, ризыкны әзерләп бетергәч, Шаммас Әмирхан абыйны алырга чыгып китте. Озак та үтми, алар икәүләшеп килеп тә керделәр.

Әмирхан абый Еникине мин беренче мәртәбә Латвиядә, Дубылтыда күрдем. Һәм аның белән танышып, белешеп йөрүем өчен Ходайга меңмең рәхмәтлемен.

Шул очрашудан бирле байтак еллар узды. Аллага шөкер, икебез дә исән саубыз, язабыз, татарга хезмәт итәбез. Гәрчә үзе кабаланмыйча, салмак кына иттереп сөйләгән кебек булса да, бик тә үткен телле, җор сүзле, төпле акыллы, кирәк дип таба икән, һәрвакыт үзенекен тыңлаучыга, укучыга җиткерә белә торган, бигрәкләр дә тыныч холыклы (минем үземә үтә дә җитми шундый тыныч холык) кеше ул безнең Әмирхан абыебыз!

Әмирхан абый килеп кергән уңайга ук Динис Бүләков аңарга күрешергә ике кулын сузды да, башкортчалап әйтте:

– Үзебезсә, ысын мөселманса күрешәйик әле, Әмирхан агай!

Әмирхан абый кабаланмый гына аның сузган ике кулын кысты да, җайлап кына әйтмәсенме:

– Чын мөселманча күрешү андый түгел бит, башкачарак.

– Нисек инде башкасарак?! Ошолай инде, ике куллап инде!

– Юк шул! – диде Әмирхан абый. – Ике куллабы, ике куллап ла ул. Тик күрешүе башкачарак шул. Белмисең икән син. Кил якынрак, күрсәтим, кил!

Әмирхан абый Динисне ике куллап җайлап кына кочаклады да, аркасыннан ике кулы белән шапылдатып куйды.

– Менә ничекләр була мөселманча чын күрешү. Мөселманнар бер-берсе белән очрашып күрешкәндә якынлык та күрсәтәләр һәм аркасында яшереп куелган коралы юкмы икән дип тикшерәләр дә. Бер уңайдан Әмирхан абый җайлап кына миңа борылды.

– Шушымыни инде теге сез сөйләгән полковник. Безнең як егете икәне әллә каян күренеп тора шул. Безнең як! Кая, күрешик бу башкортка күрсәткәнчә чын мөселманнарча!

Мин сакланып кына татар халкының атаклы язучысы Әмирхан абый Еникине кочаклыйм. Ул да мине кочаклый. Куллары йомшак һәм җылы. Гәүдәсе түгәрәк, таза, Аллага шөкер!

Минем алда гәүдәсе азрак алгарак табан авышкандай, үткен карашларын калын кашлары астында яшеребрәк тоткан чын татар абзые басып тора. Акылы, иманы, эчке дөньясының матурлыгы һәр сүзеннән, һәр хәрәкәтеннән ташып тора...

Ул көнне байтак утырдык сөйләшеп. Сөйләшкәннәрнең барысы да истә түгел инде хәзер. Иң мөһиме – Әмирхан абый минем нәрсәләр язуым белән кызыксына. Ул "Карбыз сугышы" дигән хикәямне (ул вакытта минем иң зур әсәрем шул иде) укыган булып чыкты. Бәяне дә ярыйсы ук яхшыдан бирде.

Сүз ара сүз чыгып, мин Әмирхан абыйга, аның сораганнарына җавап итеп, үземнең туган авылым Эстәрлебаш турында зур әсәр язарга җыенуымны сөйлим.

– Нәрсәләр язарга уйлыйсың инде син ул әсәреңдә? – дип сорый Әмирхан абый миннән.

– Байлар, ишаннар, сәүдәгәрләр булган Тукаевлар турында. Балта остасы булган бабаем турында, әтием турында...

– Ала-ай! – ди Әмирхан абый суза төшеп һәм кабаланмыйча гына миңа сөйли башлый:

– Тукаевлар бит алар иң башта мәгърифәтчеләр, гыйлем ияләре, белем бирүчеләр булганнар. Аннан соң гына сәүдәгәрләр, байлар, кибетчеләр булганнар. Безнең башкорт, казакъ якларына белем бирүче затлар булганнар алар. Эстәрлебашта би-ик зур мәдрәсә тотканнар. Бабалары Тукайдан ук алып. Син шуларны беләсеңдер бит?

– Беләм. Әмене берсе – Гапкадыйр Тукаев дигәннәре бик тә комсыз һәм...

Әмирхан абый кулын аз гына күтәргәндәй иттереп мине туктата:

– Мин үз фикеремне әйтеп бетерим әле. Үзең белерсең шуннан соң нәрсә язарга икәнен. Комсыз кешеләр алар байлар арасында да була, ярлылар арасында да була. Тукаевлар бер генә нәсел кешеләре дә эшли алмаганны башкарганнар. Эстәрлебашта би-ик зур мәдрәсә тотканнар. Казакъ, кыргыз халкы укырга Бохара, Сәмәркандка бармаган, ә Эстәрлебашка килгән. Чөнки аларны үзбәк өнәп бетермәгән һәм, табигый, алар да үзбәкне өнәп җиткермәгән. Безнең татарның ифрат та зур дәрәҗәсе бар казакъ белән кыргызны укытуда. Мин менә гомерем буена бер хыял белән яшим. Мөхәммәт Шакир Тукаев язган "Эстәрлебаш тарихы" дигән китап барын ишетеп беләм мин. Казанның үзендәме, Петербургтамы чыккан. Анысын белеп бетермим. Чөнки күргәнем юк ул китапны. Мәгәр 1897 елда чыкканын беләм. Шул китапны бик тә укыйсым килә. Синең ишеткәнең бармы шул китап хакында?

– Бар. Исеме аның "Тарих Эстәрлебаш" дип атала.

– Ала-ай! – дип суза Әмирхан абый. Үзе сынаган кебегрәк итеп миңа карап ала.

– Исемен төгәл белгәч, бәлки, китапның үзен дә күргәнең бардыр?

Мин Әмирхан абыйны куандырып яңалык әйтәм:

– Ул китап миндә бар. Үземнеке.

Әдипнең йөзе алсулана, куллары хәрәкәткә килә.

– Ул китапны миңа, шушында алып киләм димәкчесеңме?

Мин дә куанып елмаям. Чөнки Әмирхан абыйның шатлыгы йөзенә чыккан.

– Әйе!..

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН.

(Дәвамы бар).

Тау мәгәнә

Алдымда 25 ел элек артист Нәҗибә Ихсанова иҗатына багышлап язылган "Сәхнә шатлыклары" исемле бер мәкаләм ята. Аңа ул вакытта бары 35 кенә яшь булган. Нәҗибә театр дигән тылсымлы дөньяның ишеген киң ачып кергән гади генә бер артист әле. Әмма ул үз темасын табып өлгергән, үз моңын тамашачыга ирештерергә омтылучы, үз күңел ачышлары белән канатланган Нәҗибә Ихсанова инде. Ул чакта ук аның сәхнәдә бөтен йөрәген биреп, онытылып уйнавын, нинди генә рольне башкарырга туры килмәсен, аны бераз күпертеп, купайтып бирүе турында әйткәнмен, ләкин һәр хиснең реаль җирлеге бар, дип тә искәрткәнмен. Хәзер карыйм да, бер генә дә ялгышмаганмын, икән, дип сөенәм. Чирек гасыр эчендә ул сәхнәдә гәүдәләндергән образларга күз йөртеп чыгу белән да, аларның "кем"леген аңлыйсың, күңелең белән кабул итәсең. Нәҗибәгә сәнгаткяр буларак җир кешеләре аеруча якын, шунлыктан алар гаять тормышчан, безгә бик тә таныш һәм кадерле. Монда инде Чехов әсәрләренә хас икенче, өченче планнар турында уйлау юк. Алар, билгеле ки, бар. Тик актриса алар белән артык мавыкмый, ачык, җете төсләр белән эш итә. Бу Нәҗибәнең табигатеннән дә киләдер. Аңа "сәхнә арты уеннары" бөтенләй хас түгел. Ул кылана белми, кәефе китсә, эченә бикләнә, шатлыгы да шунда ук йөзенә чыга. Сәхнәдә дә шулай. Кешенең асылы, үзенә генә хас чалымнары, зәвыгы һәр уйналган рольдә чагылмыйча калмый. Нәҗибә ачык карашлы, якты күңелле актриса, шуңа тамашачы аны үз итә, ярата, хөрмәтли. Ләкин "сәхнә" дигән нәрсә Нәҗибәгә алай да ансат бирелмәде. Аның каршылыгын җиңү – Нәҗибәнең үҗәтлеге, тырышлыгы, хезмәт сөючәнлеге, тынгысызлыгы, матур итеп үртәлә белүе, сәхнәне бар нәрсәдән өстен куюы нәтиҗәсе. Аның уенына халыкчанлык, образлылык хас, дибез. Халыкчан артист дибез икән, бу бик зур сүз. Һәр артистка карата да андый мәртәбәле сүз әйтелми. Ә менә Н.Ихсановага бу сүз килешеп, ябышып тора. Менә шул сыйфат аны татар сәхнәсенең өлкән буын артистлары традициясе белән тоташтыра да инде. Бүген без аны театрыбыз йолдызлары Г.Болгарская, Н.Арапова, М.Сульва, Г.Камская, Ф.Камалова, Г.Камалова, А.Хәйруллина, В.Минкиналар исемнәре белән бер рәткә куеп, уенын алар уены белән тиңлибез икән, бу – актрисаның иң зур казанышы булып тора. Бу сүз Нәҗибәгә бары тик сатирик яисә милли рухтагы рольләрне еш уйнаганы өчен генә түгел, ә бәлки, ул тудырган образларның тулы канлы, анык фикерле булулары өчен әйтелә. Аның һәр образы асылташтай балкый, спектакльнең бер бизәгенә әверелә. Образлылык дигән сыйфат икеләнүгә урын калдырмый – һәрнәрсә ачык әйтелә һәм бер ноктага туплана. Әйтә торган сүзен артист һәрвакыт әйтеп бетерә.

Нәҗибәнең иҗаты халык авыз иҗатына бик якын. Авыл кызы, Азнакай якларында Яңа Ташлыяр авылында туып, дөньяга аваз салган бу табигать баласы, җир кешеләренең гадилегенә, зирәклегенә, аларның күңел сафлыгына, самимилегенә, риясызлыгына, уңган-булганлыгына, тормыш күзенә туры карый алу көченә, кичереш-тойгыларында йолдызларга кадәр күтәрелә алуларына сокланып, аларның якты образларын сәхнәдә гәүдәләндерә. Шагыйрь Хәсән Туфан әйткәндәй, бу кешеләрнең "хисләре шулкадәр киеренке: кагылсаң, арфа күк, чыңгылдар шикелле". Нәҗибәнең күңел хисләре ташкынга тиң, шунлыктан аның драма әсәрләрендәге героинялары хисләр ялкынында гөрләп яналар сыман. Менә аның 1961 елда театрга эшкә кайткач иҗат иткән иң тәүге роле – А.Гыйләҗевнең "Көзге ачы җилләр"ендәге Гөндәлиф образы.

Яшь кызның йөрәген беренче мәхәббәт хисе биләп ала. Аның башы әйләнеп кенә калмаган, ул сукырларча хисләр иркенә бирелгән. Гади авыл кызының йөрәгендә Шекспирча хисләр өермәсе давыл куптаруын яшь артист ялкынлы һәм үтемле итеп тамашачы күңеленә сеңдерә. Шуннан соң берсеннән-берсе кызыклы рольләр тезелеп китә: "Тормыш җыры"нда – Фатыйма (Фатыйма Ильскаядан соң уйнап кара әле!), "Чаткылар"да – Маһисәрвәр, "Американ"да – Мәйсәрә, "Зәңгәр шәл"дә – Заһирә, "Фигароның өйләнүе"ндә – Розина, "Назлы кияү"дә – Нәгыймә, "Кан кардәшләр"дә – Сәрдия, "Чикләвек төше"ндә – Рокыя, "Авылдашлар, акча кирәк!"тә – Мария, "Акчарлаклар"да – Газизә һ. б. Соңгы өчесе актриса иҗатында аерым бер урын алып тора. Алар Нәҗибәнең күңел түрендәге "яшерен серен" халыкка чишеп җибәрделәр сыман, хатын-кызның асылы, аның язмышы сайлаган ярының сикәлтәле язмышыннан аерылгысыз икәнен расладылар. Ш.Камалның "Акчарлаклар" повесте буенча куелган спектакльдә Нәҗибә борынгы халык җырларындагы Гөлҗамал, Зөлхиҗҗә, Мәдинәкәй, Сәлимәкәйләрне хәтерләткән, моңсу гүзәллеге белән үзенә җәлеп итә торган Газизә образын тудырды. Бу спектакль өчен махсус язылган "Акчарлаклар" көе белән дә ул тамашачы күңеленә кереп калды. Очар коштай талпынып уйнаган Нәҗибә татар классик әсәрләренең эчке моңын тоя, аның күңел сизгерлеге героиняларның күңел тибрәнүләре белән тәңгәл килә. Мин моны Нәҗибәнең җырга һәвәслеге белән генә түгел, ә, бәлки, милли моңнарны йөрәге аша үткәрә алу сәләте белән дә бәйлим.

Икенче образга – Г.Ахуновның "Чикләвек төше"ндәге Рокыяга килгәндә дә Нәҗибә үзе булып калды. Ул героинясының тормыш пәрдәсен күтәреп карый да, үз башыннан кичкәннәрне тамашачыга сөйли сыман. Көр һәм җитү тормышлы татар гаиләсендә үскән иркә һәм үзсүзле бу кыз баштарак тормышны беркатлырак кабул итә, ә инде үз язмышын "сантый Халик" белән бәйләгәч, бу "бистә кызы"ның күп нәрсәгә күзе ачыла, иренең изгелегенә төшенгәч, аның язмышын үз язмышы итеп кабул кыла, һәм артист моны ышандырырлык итеп тасвирлый ала. Нәҗибә үзе бу роль турында: "Әсәрне укып чыккач та, мин аны бик ошаттым, Рокыя миңа шулкадәр якын, үз булып китте. Театр әлеге әсәрне куярга булып, бу роль миңа бирелгәч, бик шатландым, әмма, дөресен әйтим, шулай тиеш дип кабул иттем. Чөнки мин моңа бөтен күңелем, барлыгым белән әзер идем. Мин әйтергә теләгән фикерләрне туплаган, барлык хыялларымны үз эченә алган сыман тоелды ул миңа. Әйе, синең җаныңны ачып бирердәй мондый рольләр тормышыңда аерым урын били, әлбәттә", - дигән иде.

Нәҗибә бөтен барлыгы белән җир кешесе, дидек. Нинди генә роль уйнаса да, ул үзеннән, туган туфрагыннан, нигезеннән һәм халкыннан ерак китә алмый. Аның тамырлары милли җирлеккә шул кадәр нык береккән, җәелгән ки, ул аңардан көч-куәт ала, шаулап аткан чәчәге дә, элберәп пешкән җимеше дә шул җирнең бизәгенә әверелә. Тамырлары бик тирәнгә киткән, аларны йолкып алу һич тә мөмкин түгел. Нәҗибә исемле бу чәчәкне мин тау битендә үскән тау мәгенә – эдельвейска тиңләр идем. Аның да җете кызыл киң таҗ яфракчыклары күзнең явын алырдай булып әллә кайдан күренеп балкып торалар. Тамырлары җир асты суларын, шифалы матдәләрен тирәннән суыралар һәм җирне бизәп, кояш нурларында янып торалар. Нәҗибәнең сәхнәдә тудырган иң шигъри образлары да шундыйлар. Шушы җәһәттән тагы ике образга тукталмый мөмкин түгел. Сүз Р.Батулланың "Кичер мине, әнкәй!"дәге Миңзифа һәм Т.Миңнуллинның "Әниләр һәм бәбиләр"дәге Гөлфинә турында бара. Икесе дә иң кадерле кешеләребез – Әниләргә мәдхия җырлый. Аларның һәр икесе үзенә бер төрле. Берсе салмак, кырыс күз карашы белән өтеп ала, беркайчан да ачылып китмәс, тәмле телле булмас. Әмма аның күңеле бик сизгер һәм нечкә. Юкса, "башын җуйган" сеңлесенең улын тәрбияләп үстерә, аны кеше итә алыр иде микән? Бик кешелекле кеше ул Миңзифа. Менә ул – чын татар хатыны! Гөлфинә үзгә, әмма ул да үзебезнеке. Күп балалы ана булса да, бала холыклы, уңган-булган, тәвәккәл, тиз кабынучан һәм тиз кайтып төшүчән,кулыннан килсә, бөтен кешеләргә дә ярдәм итәргә әзер торучы хатын. Ул кызлардай җитез, чая, самими, кигән күлмәгеннән дә ана сөте исе бөркеп тора. Ул хастаханә бүлмәсенә үз нигезенең хуш исен алып килгәндәй тоела. "Әниләр һәм бәбиләр"не Нәҗибәнең ире – Туфан Миңнуллин язган. Миңа калса, Гөлфинә образы Нәҗибәгә атап, аңа багышлап язылгандыр кебек. Туфанның пьесалары театр сәхнәсендә күп куелды. Аларның күбесендә (кечкенә генә рольдә булса да), Нәҗибә катнашмый калмады, тик менә Гөлфинә берсүзсез аңа атап язылган булырга тиеш – ул аның бөтен кешелек асылына ике тамчы судай тәңгәл килә. Һәр хатын-кыз Ана булырга тели. Гөлфинә палатадагы хатын-кызлар арасында иң бае, иң бәхетлесе. Нәҗибә үзенең Гөлфинә ролен башкарганда шушы бөек хисне – Ана булу теләген шигъри югарылыкта ачып бирә алды. Бу рольне мин башка артист уйнавында күз алдыма да китерә алмыйм. Ул аныкы, бары тик аныкы гына! Нәҗибәдәге яшәү дәрте, дөньяны иңләү, колачлау теләге аның үзенә дә, сәхнәдә ул тудырган образларга да хас.

Ни хикмәттер, Нәҗибәне тамашачылар күбрәк характерлы актриса итеп таныйлар һәм алар хаклы да. Ул, чыннан да, тонык төсләрне яратмый. Нәҗибә сәхнәдә тискәрерәк, каршылыклырак холыклы хатын-кызларны киң колач белән уйнарга омтыла. Менә аның тәүге рольләреннән берсе – Җ.Җаббарлының "Айдын" әсәрендәге Бөекханым образы. Нәҗибә, әйтерсең лә, бу образны сурәтләү өчен бары тик өч – кызыл, сары һәм кара төсне сайлый. Зиннәт һәм байлыкка чумган бу хатын үз көчен яхшы тоя, ирен горур, тәкәббер сөю белән ярата һәм шул ук вакытта иренең хыянәтен гаять авыр кичерә. Менә шушы өч хиснең бер-берсенә үрелеп баруында бу образның бөтен каршылыгы ачыла. Актриса ярсып көлә, ярсып елый, ярсып көтә, ярсып нәфрәтләнә. Тагы бер образны искә төшерик: ул И.Йомаголның "Нәркәс" әсәре буенча куелган спектакльдәге Зөмрәт карчык. Бу очракта актриса романтик киңлеккә омтыла. Аның тышкы кыяфәте шактый ямьсез, хәтта куркыныч. Менә актриса, мөнәҗәт әйткәндәй, мәкам белән сүзен сөйли. Моңлы һәм аһәңле аның бу зарлы җыры. Бу көйдә туган илгә, туган далага, якын кешегә карата булган сагыш ярылып ята. Шушы хис аша кешенең рухи көченә, какшамас кодрәтенә дан-шөһрәт җырлана. Менә тагын бер "характерлы" роль – ул "Әлдермештән Әлмәндәр"дәге Өммия образы. Гомер буена кайнатасы белән яшәгән, ялгыш кына да сүз кайтармаган, гел аның көенә торган. Хәзер кайнатасы үлем белән очрашкач, Өммия күңелендә аңа карата гаҗәпсенү катыш соклану хисе уяна. Ул аңа ачуланса да, кеше юкта гына, тәртип өчен генә мыгырдана. "Үләм!" дигән аһ орулары мәзәк булып халык теленә кереп, хәзер инде спектакльдән, артисттан аерым рәвештә яши башлады.

Инде "Гөргөри кияүләре"ндәге Әүдәкине искә алыйк: бу карчыкка йөз дә ничә яшь бит, аяклары йөрми, ә йөрәге исә картаймый, яна. Бу керәшен карчыгының утырган җирдән биеп, "ут уйнатуы" халыкның җорлыгы, үлмәс акылы, яшәү дәрте булып кабул ителә. "Йөрәк маем"дагы мишәр карчыгы Асимәнең өч оныгына "көтүче" булып йөрүе шулай ук мәзәк булып күренә. Ул шулкадәр оныклары мәнфәгате белән яши ки, кирәк икән, алар белән бергә бии, хәтта цирк артисты кебек шпагат та ясый.

Нәҗибә ачык күңелле хатын. Ул – хис кешесе. Канатлары булса, күкнең җиденче катына да менәргә әзер. Сәхнәдә ничек ихлас уйнаса, тормышта да шулай яши. Аны җәмәгать эшләрендә күзәткәнем булды. Ул халык театрлары смотрында жюри әгъзасы иде. Шул хәтле яратып эшләде ул бу эшне, шуннан ямь, тәм тапты. Телевидение яки радио тапшыруларында катнашу да аның өчен сәхнәгә чыгу белән бер. Җаваплылык хисе – чиксез, чамасыз. Мин аларны Туфан белән икесен бик күп юбилей кичәләрендә очратам. Шуны әйтә алам, алар анда рухи азык эзләп киләләр һәм табалар да. Менә бер генә мисал:татарның беренче мәшһүр композиторы Солтан Габәшинең 100 еллыгына багышланган кичә. Декабрь аеның салкын киче. Килгән кешеләр арасында Туфан белән Нәҗибә дә бар. Аларның килүләре безгә – бу кичәне оештыручыларга зур терәк булды. Шушы кичә тәэсирендә Нәҗибә "Татарстан хәбәрләре" гәзите битләрендә, үзенең уйхисләре белән уртаклашып, мәкалә дә язып чыкты. Кеше кушуы буенча түгел, үзе теләп. Менә бит ул нинди киң күңелле. Мең рәхмәт аңа!

Әйе, Нәҗибә сәхнәдә дә, тормышта да янып, яшьнәп яши. Менә шуңа халык аны ярата, үз итә. Менә шушы яклары белән ул, халык артисты, данлыклы татар сәхнәсендә озак еллар буе фидакарьләрчә хезмәт итә, өлкән буын сәхнә осталары салган якты юлны намус белән дәвам иттерә.

Дания ГЫЙМРАНОВА,
театр белгече.

Батулла баганасы

Алкышлар һәм балкышлар

1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы булып уза. Бу сәнгать бәйрәмендә Бари Рәхмәт тә катнаша. Сәхнәдә шигырь укып, ул зур уңыш казана. Ләкин сәхнәдән чыгуга ук аның хәле начарая, ул шундук җан бирә. Халык аны һаман алкышлый, яңадан сәхнәгә чакыра, сәхнәдә исә ыгы-зыгы, каушау, буталыш башлана. Арттагы язучылар нишләргә белми. Сибгат Хәким халык алдына чыгып:

– Иптәшләр, сез яраткан мәшһүр шагыйрь Бари Рәхмәт әле яңа гына вафат булды! – ди.

Халык тагын да ныграк итеп, гөрләтеп кул чаба, шагыйрьне һаман сәхнәгә чакыра икән.

– Иптәшләр! – ди Сибгат Хәким, – Бари Рәхмәт сәхнәгә чыга алмый, ул әле генә үлде.

Тамашачы нишләргә белми, аның саен катырак кул чаба башлый. Сибгат ага сәхнәдән чыгып китә.

Шаяруның чиге бармы?

Бер мәҗлестә Гали Хуҗи, шәраб күтәреп, тантаналы рәвештә болай ди:

– Әйдәгез әле, Кол Галидән алып Хуҗи Галигә, Мөхәммәдъярдан алып Нәҗип Мадъярга кадәр килгән әдәбиятыбыз хөрмәтенә күтәрик бокалларны!

– Саграк кылан, Гали, – ди Сибгат Хәким. – Шаяруның да бер чиге була.

Бөек мактау

Балалар әдәбияты секциясе Мостафа Ногманның иҗатын тикшереп, аны Язучылар берлегенә әгъзалыкка тәкъдим итәргә тиеш иде. Госман Бакир, Газиз Иделле һәм башкалар Мостафа Ногманны бик нык мактадылар: имеш, ул өлгергән шагыйрь икән; аның җырлары һәм "Кокушкино таңнары" олы бәя алды. Барысы да сөйләп бетергәч, рәис Сибгат Хәкимгә сүз бирде. Бөтен җыелыш тынып-сагаеп калды. Мостафа Ногман бигрәк тә каушаган, бичара кыяфәттә иде. Хәзер Сибгат ни әйтсә, шул гамәлдә булачак. Сибгат Хәким озак кына дәшми утырды. Яңагына таянган, ике бармагын чигәсенә куйган; ул әкрен генә түшәмдәге акшар тапларын тәфсилләп тикшерде, соңра бармагы белән диван култыксасындагы күзгә күренмәс тузан бөртекләрен капшап карады да, сүз әйтергә сулыш алды:

– Менә... урысларда... союзда... мең ярым язучы бар... аның... без белгәне егермеләп булыр... урысларның союзында... башка халыкларның союзында да, әйтик, язмаган язучыларны да союзга алалар... бу яза бит әле... алыйк!

Көлсәң – көл, көлмәсәң – ела!

Елга белән комган

(Мәсәл)

Тау буеннан боргаланып елга ага,
Ничә гасыр, ничә мең ел инде аңа.
Яры өстендә аунап ята тишек комган –
Кемдер аны, кирәкмәгәч, монда куйган.
Эшсез ятып арыгач комган телгә килде,
Һәм елгага, борынын сузып, сорау бирде:
– Күпме суың бушка ага ярың буйлап,
Кешеләргә ни файдаң бар? Кара уйлап.
Борыным аша акты һәркөн синең суың,
Яше-карты юды миннән битен-кулын.
Мин, ичмаса, муллага да иттем хезмәт,
Шуңа күрә миңа хәзер нинди хөрмәт?!
Шул чагында бака тотып йөргән бала
Бу комганны яр өстеннән табып ала.
Кызык өчен бала аны аска атты...
Тишек комган тиз вакытта суга батты.
Бу мәсәлнең мәгънәсе сезгә ачык:
Хезмәт итә һәммә нәрсә, хәтта кашык.
Комган сыман көлке хәлгә калмас өчен
Иң әүвәл син сынап кара елга көчен.

Рифкат СӘЛИМОВ.
Бөгелмә шәһәре.

Сала саен мең дә бер мәзәк

"Мәдәни җомга" гәзитен беренче саныннан башлап алдырам һәм бик яратып укып барам. Ул безгә, татар теле һәм әдәбияты укытучыларына, бигрәк тә якын, кадерле. Менә, гәзитнең "Сала саен мең дә бер мәзәк" рубрикасы өчен берничә мәзәк җибәрәм.

Нәзһәт ЗИМАСОВ.
Казан шәһәре.

Үзенчә аңлаган

Иртә белән Сәми каты махмырдан нишләргә белми: арлы-бирле йөри дә йөри, ни ашый, ни эчә алмый.

Хатыны, ачуланып:

– Әзрәк эчәргә кирәк! – дигән.

Сәми:

– Менә-менә, мин дә шулай уйлыйм: эчәргә кирәк әзрәк, салып бир тизрәк! – дигән, шатланып.

Йөзгә тулу

Акылга җиңелрәк Сәмине авылда 99лы дип йөртәләр иде. Бервакыт, кибет алдында, тәмәке тартып утыручылар янынан узып барганда, Сәми җирдә бер тиен акча табып алган. Шуны күреп:

– Менә хәзер инде йөзгә тулдың! – дип, Сәмидән тагын бер көлгәннәр.

Аякка кирәк

Сугыштан соңгы елларда авыл кибетләрендә иң кирәкле тауарларны май, йомырка, сөт, ит кебек азык-төлеккә алмаштырып саталар иде. Беркөнне кибеттә күкәй тапшыручыларга галош саталар икән, шунда Әпсәләм абзый килеп кергән һәм нәрсә сатулары белән кызыксынган. Аңа:

– Әпсәләм абзый, галош саталар күкәйгә, – дигәннәр.

– Миңа аякка кирәк иде, – дип, Әпсәләм абзый кибеттән чыгып киткән.

Сагыну хатлары

Гыйльми фронтка киткәч, авылда калган хатыны сагынып хатлар язып тора. Бер хатында:

"Одеял ябынасыңмы,
юрган ябынасыңмы?
Одеял-юрган ябынганда
мине сагынасыңмы?" –

дип, җыр да өстәп куйган.

Гыйльми дә җавапсыз калмаган:

"Одеял да юк монда,
юрганы да юк монда;
Яңгыр кебек пуля ява,
синең кайгы юк монда", –

дип язып җибәргән.

Лаеш шулпасының шулпасы

Акча мәсьәләсе – җитди мәсьәлә. Борынгы ханнар да үз акчаларын суккан. Ул акчаларны археологлар әле дә булса эзләп таба, казып ала. Абзар артында тирес түккәндә мин бик "борынгы" бер акча таптым. Анда Концерн "Татплодоовощпром", АООТ "Нармонка", Лаишевский район, дип язылган. Редакциягә калдырам, югалткан кеше килеп алсын!

И.ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Раил СӘЛАХ

Үрнәк тормышта яшәүче ир белән хатынның ызгышуы

Ир:
Нигә мине игәүлисең,
Тоз саласың каныма,
Тырмага килгән мәчедәй,
Ыргыласың яныма?
Һаман мине алкаш дисең,
Эчкәнем дә юк күптән.
Ачуымнан эчәр идем,
Аракы төшсә күктән.
Сезгә, җаныем, ирек куйсаң,
Авызны да ябарсыз.
Әле амбар йозагының
Күгәргәнен тагарсыз.

Хатын:
Төкерегеңне йотасың
Шешәсен күргәндә дә.
Эчүеңне ташламассың,
Пажалуй, үлгәндә дә.
Әле айныганың да юк,
Эчкән юк, дисең күптән.
Күрмәгәнеңне күрсәтер,
Горбачев төшсә күктән.
Һаман шулай салып йөрсәң,
Түзә алмам озакка.
Авызыңны бикләп куям
Амбарский йозакка.
Син телисең, эшләмичә,
Лишь бы эчеп ятарга.
Синең ише дармоедны
Судсыз кирәк атарга!

Пар(О!)доя

Аш пешерү

Йөрәгемә шырпы сыза,
Җанымда су кайната.
Каннарыма таш тоз сала
Әйләнеп кайта-кайта.

Ренат ХАРИС.

Йөрәгемә шырпы сызды
Һәм утларын үйнатты.
Бер чиләк суын салды да
Шулпа итеп кайнатты.
Үпкәләрем бик тиз пеште,
Төннәремнән чыкты пар.
"Нишлисез сез, поварлар?! – дим,
Пешә бөер-бавырлар!.."
Колаклардан төтен чыкты,
Куырылды чәчләрем.
Үзе китте кибетләргә...
Берүзем, дим, нишләрмен?!
Бер-ике сәгать йөргәндер,
Кайтып керде соңыннан:
– Тозсыз шулпа – шулпамыни,
Гафу ит, ди, онтылган!
Кашык алып тозын салды,
Макароннарын тапты.
Мин сүз әйтә алмый калдым,
Кунак дәшәргә чапты...

Касыйм ТӘХАУ

Гыйбрәтле гыйбарәләр

Башың эшләмәсә, телең акыллы сүз әйтмәс.

•

Туганнарны сайламыйлар.

•

Елгага таш ыргытып, суы артмас.

•

Йөрәк – алама киңәшче.

•

Яшьлектә дөнья матур, дөнья киң,
Картлыкта ул авыш әйгә тиң.

•

Булдыксыз тормышны гаепләр,
Булдыклы тормышын ипләр.

•

Беренче мәхәббәт – гомерлек сагыш.

•

Гомер алтын күрмәгән,
Ярлы булып үлмәгән.

•

Шапшак килен пычрак белән дуслашыр.

•

Яктылык якынлашкан саен күләгәләр кими барыр.

•

Кешене кимсеткәнгә дан ябышмас.

Игелек эшлә, игелек күр

Илбарис НАДИРОВ, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе

Бер вакыфның бәрәкәтле

"Вакыф" (кайбер очракта "Вәкыф") сүзе телебезгә берничә ел әүвәл генә кире кайтты кебек. Аның 70 елдан артык кулланылмый торуына төп сәбәпне бу сүзнең мәгънәсеннән эзләргә кирәктер. Чөнки "вакыф" шәригать белән бәйле төшенчә дип саналган, гадәттә, әлеге сүз мәдрәсә, мәчет тоту һәм ярлыларга ярдәм итү өчен аерым байлар тарафыннан бүләк рәвешендә бирелә торган акчага яисә малга карата әйтелгән.

Мәгълүм инкыйлаптан соң байлар да, ярлылар да, мәчет-мәдрәсәләр дә юкка чыкты. Шул сәбәпле, "вакыф" та искергән сүзләр рәтенә кереп, онытылу дәрәҗәсенә җитте. Инде, шөкер, тормыштагы яңарышлар дулкынына ияреп бу сүз кабат ишетелә башлады. Шуның бер дәлиле – Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфы. Истанбул шәһәрендә моннан өч ел әүвәл корылган әлеге вакыф һәм аның эшчәнлеге турында татар дөньясы күпмедер хәбәрдар булса да, бу хәбәрдарлыкка тулылык, бөтенлек җитми шикелле. Әлеге мәкалә шуны истә тотып язылды.

Сүзне Әхмәтвәли Мәңгәрдән башлыйк. Гаҗәп сәләтле шәхес булган ул. Заманында Садри Максуди аны юкка гына "сәүдә даһие" дип атамаган. 1914-1939 елларда Монголиядә, Кытайда, соңыннан вафатына кадәр (1978) Төркиядә яшәгәндә аны яхшы белүче аркадашлары һәм якыннарының Ә.Мәңгәр турында гаять җылы хатирәләре бар. Ә.Мәңгәрнең кызы Сафия ханым Имренең әтисе турындагы тәфсилле истәлекләре исә аерым китап рәвешендә башта төрекчә (1993), ә бер елдан соң татарча басылып чыкты. Соңыннан бу истәлекләр һәммәсе бергә узган ел Казанда Әхмәтвәли Мәңгәр. "Хатирәләр" дигән җыентыкта дөнья күрде. Шул ук китапта Ә.Мәңгәрнең үз хатирәләре һәм XX гасыр башы татар тарихы белән бәйле мәкаләләре дә урнашкан. Ул китапта Әхмәтвәли Мәңгәр сәүдә-кәсәбә дөньясында танылган эшмәкәр буларак та, озын гомере буе татар халкының тарихы, мәдәнияте белән кызыксынып яшәгән һәм Төркиядә татар рухлы журналлар, китаплар бастыруга, төрле җәмгыятьләр эшчәнлеген юлга салуга мул гына матди ярдәм күрсәтүче милләтпәрвәр шәхес, меценат буларак та сурәтләнә. Аның турында Төркиядә дәүләт эшлеклесе, дипломат, галимә булып танылган Адилә Айдә (Садри Максуди кызы) тарафыннан язылган хатирәдә шундый юллар бар: "... Бераздан Мәңгәр сүзен үзенә күчерде, инде картаеп китүен, сиксәнгә җитүен, үлемгә әзерләнә башларга кирәген искә төшерде. Шуннан соң җыйган малының бер өлешен Казан төркиләренә мәдәни ярдәм күрсәтү өчен бүлеп куйганлыгын әйтте... Аңлавымча, ул бер вакыф кормакчы иде... Иншалла, мәрхүмнең бу изге теләге тормышка ашар дип уйлыйм" (Ә.Мәңгәр. "Хатирәләр". 86 б.). Дөрестән дә, Ә.Мәңгәрнең бу мөкатдәс хыялын күпмедер еллар узгач, кызы Сафия Имре тормышка ашырды. 1995 ел башында ул әтисе исемендәге мәдәни-хәйрия вакыфы оештырды.

Сафия ханым Имре – филология фәннәре кандидаты, алты телдә иркен сөйләшә белә, гомере буена Төркиядә әтисе җитәкчелек иткән "Мерседес-Бенц" фирмасында эшли, аның якын киңәшчесе һәм ярдәмчесе була. Соңгы елларда Сафия ханым вакыф президенты буларак үзенең бар вакытын, егәрен хәйрия эшләренә багышлый. Анкарада яшәүче милләттәшебез, күренекле тюрколог, профессор, вакыфның идарә советы әгъзасы Әхмәт Тимер белән фикер алышканнан соң, алар вакыфка фәнни киңәшчеләр сыйфатында Казаннан өч галимне – тел белеме буенча академик Мирфатыйх Зәкиевне, тарих фәннәре буенча академик Миркасыйм Госмановны һәм фольклор буенча мине сайлап алалар.

Соңгы өч ел эчендә вакыф ниләр эшләде соң?

Вакыф уставында язылганча, аның иҗтимагый-хәйрия эшчәнлеге нигезен төрле илләргә сибелгән төрки халыклар белән Төркия дәүләте арасында рухи-мәдәни күпер хезмәтен үтәү максаты тәшкил итә. Бу максатка ирешү өчен вакыф төрки халыклар тарихына, мәдәниятенә һәм теленә хас булган уртаклыкларны үстерүнегытуны, фәнни китаплар алмашуны, уртак латин алфавитына күчүне күз алдында тота. Шуны истә тотып Сафия Имре төрки халыклар иҗатыннан "Берлектән куәт туар" дигән мәкальне вакыфның асыл мәсләгенә туры килә дип саный (бу мәкаль вакыфның гамәли эш кәгазьләре башына язылып та куелган).

Әхмәтвәли Мәңгәр хәләл җефете Гайшә ханым белән. Истанбул, 1971 ел.

Вакыф үзенең эшчәнлеген төүге чиратта Татарстан илендә яшәүче татарлар белән элемтәләр урнаштырудан башлап җибәрде. Болай эшләү табигый дә, чөнки ул Әхмәтвәли Мәңгәр хыялына тәңгәл килә. Мәңгәр гомере буе үзенә газиз булган татар халкын, татар дөньясын сагынып, җирсеп яшәгән, Татарстанны үзенең тарихи Ватаны дип санаган. Аның ерак бабалары гомер иткән Мәңгәр авылы (сүз хәзерге Әтнә районына кергән Олы Мәңгәр авылы турында бара) исемен 1939 елда үзенә икенче фамилия итеп алуы да юкка гына түгел.

Искә алган "Хатирәләр" мәҗмугасында Ә.Мәңгәрнең китапка гашыйк һәм китап җыярга яратучы искиткеч һәвәскәр зат булуын аны белгән кешеләр сокланып хәтергә алалар. Аның китапханәсендә меңләгән китап туплана. Соңыннан ул аларны Анкарадагы Төрек Мәдәниятен өйрәнү институтына бүләк итә. Сафия ханым иң әүвәл шул китапларның татар, төрек һәм башка төрки халыклар тарихына, филологиясенә караган өлешеннән Казанда булмаган үрнәкләрен җибәрүне күз уңында тота. Без – киңәшчеләр бай библиографик исемлек нигезендә шул эшне башкаруга, озак та үтми сайланган 122 китапның калын тышлыкта, сыйфатлы кәгазьдә басылган икешәр данәдәге ксерокопияләре Казанга килә башлады. Нинди китаплар турында сүз бара соң?

Аларның төп авторлары – заманында Русиядәге милли-рухи кысанлыкка, кырыслыкка түзә алмыйча Төркиягә китәргә мәҗбүр булган татар галимнәре һәм язучылары. Арада Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Йосыф Акчура кебек бөек затлар, Рәшит Рәхмәти, Зәки Вәлиди, Абдулла Баттал, Әкъдәс Курат, Хәмит Кошай, Сәгадәт Чагатай, Абдулкадыйр Инан, Әхмәт Тимер, Надир Дәүләт кебек атаклы тюркологлар бар. Бу исемлеккә Ләбиб Каран, Али Акыш, Тәмурбәк Дәүләтшин, Сания Гыйффәт кебек мәгълүм шәхесләрне дә өстәргә кирәк. Телгә алган авторларның Казанга килгән китаплары нигездә төрек телендә булып, Г.Исхакый, Л.Каран, С.Гыйффәт әсәрләре генә татар телендә. Китаплар арасында 1913-1936 елларда нимес телендә басылган һәм 8 томнан торган "Ислам энциклопедиясе" һәм 5 томнан торучы "Шәрекъ ислам классиклары. Милләтләр вә хөкемдарлар тарихы" (төрек телендә) барлыгын да әйтеп китик. Килгән китапларның бер данәсе Татарстан Милли китапханәсенә, икенчесе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты китапханәсенә тапшырылды. Аларны укучылар саны көннән-көн ишәя бара.

Узган ел җәй башында Сафия Имре үзенең ире Иззәт Имре һәм Мәхмүт Әлүкәй (вакыфның вице-президенты) белән Казанга килгәч, вакыф җибәргән китапларны тәкъдир итү кичәсе булды. Аны Татарстан Милли китапханәсе оештырган иде. Кичәдә катнашкан гыйлем ияләре бүләк ителгән китапларга югары бәя биреп, аларның татар һәм төрки халыклар тарихын, мәдәниятен өйрәнүдә, Төркияне тану-белүдә гаять кыйммәтле чыганаклар булуын билгеләп үттеләр. Шулай итеп, Ә.Мәңгәр вакыфы халкыбызның төрле якларга сибелгән кадерле китаби мирасыннан аерым үрнәкләрне төп Ватанына – Татарстанга, Казанга кайтаруга ирешә. Олы рәхмәткә лаек игелекле бер эш бу.

Вакыфның Казанда башкарган икенче эше – латин хәрефләрендә китаплар чыгару булды. Бу эшнең үзенә күрә "көн кадагына сугучы" бер вакыйга булуын искә төшерик. Чөнки нәкъ менә соңгы өч-дүрт елда татар илендә латинга күчү мәсьәләсе көн тәртибенә басты. "Күчәбезме, юкмы?" дигән сорауга җавап эзләп кайнар бәхәсләр кабынды. Мин үзем Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми киңәшмәсендә кабул ителгән латин проектын яклаучылар ягында. Бу вариант академик М.Зәкиев аңлатмалары белән "Ватаным Татарстан" гәзитендә узган ел 28 мартта басылып чыккан иде. Ул үткәнгә – яңалифкә кайтуны күз алдында тотып түгел, киләчәкне уйлап төзелгән алфавит. Әгәр без үзебезне төрки халыклар гаиләсенең тулы хокуклы бер әгъзасы дип саныйбыз икән, безгә язмабызда төрлелек, аерымлык эзләү юлыннан түгел, ә уртаклык, бердәмлек эзләү юлыннан атлау тиеш икәнлеген истән чыгармаска кирәктер.

Ә.Мәңгәр вакыфы сайлап алган һәм 1997 ел башында Казанда бер-бер артлы дөнья күргән өч китап халыкара латинда басылдылар. Алар өчесе дә соңгы ун ел дәвамында Казанда кириллица белән басылган китаплар: Риза Фәхретдиннең "Болгар вә Казан төрекләре", Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф"ы, халкыбызның мәшһүр дастаны "Идегәй". Бу китапларның титул битендә бирелгән кыскача аңлатмага күз салыйк. Анда шундый юллар да бар: "Китапның бу басмасы 1992 елда Төркия мәмләкәтенең Анталия шәһәрендә халыкара тюркологлар конференциясендә кабул ителгән уртак латин әлифбасында бастырылды. Болай эшләү бер яктан чит илләрдәге милләттәшләребез дә иркен укый алуга хезмәт итсә, икенче тарафтан Татарстан һәм Русиядәге татарларны да уртак латин әлифбасы белән якыннан таныштыруга ярдәм итәчәк". Бу максат дөрес куелган булып чыкты. Сафия ханым Имре хәбәр итүенчә, ерак чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез искә алган китапларны чын күңелдән хуплап, куанып кабул иткәннәр. Үткән ел җәен Казанда уздырылган II Бөтендөнья татар конгрессына килгән чит ил кунаклары өчен дә бу китаплар кадерле бүләк булды. "Казан утлары" журналы шушы китаплардан күчереп латин әлифбасында язуга бәйле үрнәкләр бирде. Кыскасы, Ә.Мәңгәр вакыфының бу гамәле дә халык күңеленә хуш килде, чөнки латин бик күпләр хыялында йөргән һәм туган телебез аһәңенә ятышлы бердәнбер алфавит бит.

Вакыфның китаплар белән бәйле башка эшләрен дә искә төшерик. XX гасыр башында төрки халыклар өчен чыгарылган "Тәрҗеман" гәзитенең мөхәррире һәм җәмәгать эшлеклесе буларак киң танылган Исмәгыйль бәй Гаспралының тууына 1996 елда 145 ел тулды. Шул уңайдан вакыф аның тормыш юлы турында профессор Надир Дәүләтнең төрек телендә Анкарада (1988) чыккан монографиясен Казанда кабат бастыруны кирәк тапты. Яңа басмага Н.Дәүләт татар телендә яңа кереш мәкалә язды, китап ахырында күренекле татар журналисты Фатих Кәриминең 1914 елда "Вакыт" гәзитендә И.Гаспралы вафатыннан соң басылган кайгынамә язмасы бирелде. Ниһаять, И.Гаспралы турындагы төүге басмада булмаган гаилә фоторәсемнәре (алар сигез) яңа басмага күркәмлек өстәде.

Халкыбызның милли азатлыгы өчен көрәшчеләрдән берсе, Төркия тарихында могтәбәр урын тотучы күренекле галим, дипломат, җәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчура (1876-1935) турында профессор Әхмәт Тимер язган монографияне дә вакыф кабат бастырды. Ул китап моннан ун ел элек Төркиядә чыккан. Яңа басмасы да Анкарада дөнья күреп (1997) Казанга җибәрелде. Сафия ханым Имре төрек телендә басылган әлеге монографияләрне соңгы елларда Казанда һәм Татарстан шәһәрләрендә ачылган төрек-татар лицейлары һәм гимназияләренә бушлай таратырга тәкъдим итте. Алда саналган латин имлясындагы китапларның да бер өлеше Казан һәм Татарстан китапханәләренә, мәктәпләренә бүләк ителүен әйтү кирәктер.

Әхмәтвәли Мәңгәр вакыфы чыгарган тагын ике китапны телгә алу зарур. Аларның берсе – олуг галимебез, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани әсәре "Мөстәфадел-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар". Мәгълүм ки, мәшһүр тарихчының бу әсәре ике томнан торып, беренчесе 1897 елда, икенчесе 1900 елда Казанда нәшер ителәләр. Шуннан соң алар тулы хәлендә беркайчан да кабат басылмыйлар. Шуны истә тотып, Сафия Имре һәм Әхмәт Тимер бу ике китапны факсимиле (фотокүчермә) рәвешендә чыгару дөрес булыр дигән фикергә киләләр һәм бөек шәхеснең тууына 180 ел тулу уңаеннан ул китаплар бер-бер артлы Анкарада дөнья күрә. Аларны бастыру мәшәкатьләрен Анкарадагы Төрек мәдәниятен өйрәнү институты үз өстенә ала, Мәңгәр вакыфы исә матди ягын кайгырта. Әсәрнең 1 нче томына профессор Әхмәт Тимер бәй эчтәлекле кереш мәкалә язган. Төрек телендәге бу мәкаләне татар телендә дә бастыру мәслихәт булыр иде. Анда Мәрҗани һәм ул яшәгән чор турында безнең тарихи әдәбият өчен яңача яңгыраган хәбәрләр дә бар. Мәрҗани китапларының бер

өлешен вакыф Казанга җибәрде. Без аны фәнни китапханәләргә, Мәрҗани исемендәге гимназиягә, аның туган авылындагы музейга, Казандагы туганнарына һәм Мәрҗани иҗаты белән шөгыльләнүче галимнәргә тараттык.

Татарстан белән Төркия арасында соңгы елларда урнашкан тотрыклы икътисади-мәдәни мөнәсәбәтләр көн үзәгенә төрек һәм татар телләрен өйрәнү ихтыяҗын да куйды. Шуны истә тотып, Әхмәтвәли Мөңгәр вакыфы нәшрият эшчәнлегендәге игътибарын ике зур сүзлек чыгаруга юнәлтте. Аларның берсе – "Татарча-төрекчә сүзлек", икенчесе – "Төрекчә-татарча сүзлек". Беренче сүзлек узган ел Мәскәүдә "Инсан" нәшриятында дөнья күрде, икенчесе быел басылачак. Аларны тел галиме, профессор Фоат Ганиев җитәкчелегендәге авторлар әзерләде. "Татарча-төрекчә сүзлек"тә 22 меңгә якын сүзнең төрекчәгә тәрҗемәсе бирелгән. Белгечләр тарафыннан уңай бәя алган ул сүзлек татар-төрек лицейларына, китапханәләргә таратылды, кибетләрдә сатуга чыгарылды һәм тел өйрәнүчеләр өчен файдалы бер кулланмага әйләнде. "Төрекчә-татарча сүзлек"нең дә шундый күркәм һәм сыйфатлы булып чыгуын көтәргә кала.

хәрәкәте

Вакыф президенты буларак, Сафия Имренең аерата игелекле һәм затлы бер гамәле – ул әдәбиятыбыз классигы Гаяз Исхакыйның архивын һәм кайбер шәхси әйберләрен кадерле Ватанына – Татарстан җиренә, Казанга кайтаруы булды. Сүз атаклы әдипнең тулы архивы турында түгел, шул архивның бер өлеше турында бара, чөнки архивның төп өлеше әле Истанбулда, башка кулларда, киләчәктә анысы да Татарстан иленә кайтыр дип өметләник.

Казанга китерелгән бу архивны узган ел башында Сафия Имре үз кулы белән Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевкә тапшырды. Истәлекле очрашуда танылган галимнәр һәм язучылар да бар иде. Президентыбыз татар халкының иҗтимагый-мәдәни тарихында Гаяз Исхакый биләгән олы урынга югары бәя биреп, аның шәхси архивын Ватанга кайтаруда куйган изге хезмәте өчен Ә.Мөңгәр вакыфына, Сафия ханым Имрегә һәм архивны вакыфка биргән Сөембикә ханым Шәриповага (Гаяз Исхакыйның бертуган сеңлесе Гайнемәрзия кызы, варис хуҗасы) зур рәхмәт белдерде.

Хәзерге вакытта Гаяз Исхакыйның бу архивы Татарстан Милли архивында саклана. Андагы кульязмалар, документлар исемлеген Сафия ханым миңа Истанбулда 1996 елның мартында ук биргән иде. Ул исемлектә 89 документ саналган. Алар арасында Г.Исхакыйның күпсанлы хатлары, аңа килгән хатлар, көндәлек дәфтәреннән өзекләр, бөйсез Идел-Урал мөселманнарының милли-мәдәни мөхтәриятен коруга караган язмалар, Берлинда чыккан "Милли юл" журналының аерым саннары, "Җан Баевич" комедиясе буенча язылган либретто, "Олуг Мөхәммәт" пьесасы, Йосыф Акчура, Галимҗан Баруди хакындагы мәкаләләрнең кульязмалары, Ерак Шәрекътәге (Кытай, Япония, Корея) татарлар арасында утызынчы елларда алып барган сәяси-мәдәни эшчәнлеге турындагы документлар, Г.Исхакыйның 50 яшьлегенә караган материаллар һ.б. бар. Г.Исхакый иҗатын өйрәнүче галимнәр һәм архив белгечләре ул документларга якын арада әтрафлы тасвирлама ясап, аларның фәнни кыйммәтенә бәя бирерләр дип ышанасы килә. Бу өлкәдә тәүге адым ясалды инде. "Гасырлар авазы" журналының әле яңа гына чыккан санында (1997, № 3-4) бу архивтан ике документ басылды һәм документлар исемлегенең урыс теленә тәрҗемәсе бирелде.

Гаяз Исхакый архивыннан тыш, Сафия Имре Татарстан Милли архивына XX гасыр башында татарларның һәм башка мөселман халыкларының милли азатлык хәрәкәтенә, 1906-1914 елларда үткәрелгән Мөселман конгрессларына, Исмәгыйль Гаспралы һәм аның кызы Шәфика Гаспралыларның сәяси-мәдәни эшчәнлекләре белән бәйле кырыкка якын кыйммәтле документлар тапшыруын да рәхмәт хисе белән искә алу зарур. Ә.Мөңгәр вакыфы шулай ук Татарстан Милли китапханәсенә дә XX гасыр башында Идел, Урал, Кырым татарларының иҗтимагый вә мәдәни тормышына караган аерым сирәк китаплар һәм кульязмалар бүләк итте.

Мөңгәр вакыфының хәйрия эшчәнлеге озак елларга исәпләнсә дә, һәр елның үз планы бар. Быел вакыф Анкарада төрек телендә ике китап чыгаруны ниятли. Аларның берсе Казан галиме, тарих фәннәре кандидаты Рафаэль Мөхәммәтдиновның "Төркичелекнең барлыкка килүе һәм үсеше" дигән монографиясе. Урыс телендә Казанда басылган (1996) бу китабын автор төрекчәгә үзе тәрҗемә итте. Анда соңгы йөз елдан артык дәвердә төрки халыкларда төркичелек идеологиясенең барлыкка килүе һәм ничек акрынлап таралуы тикшерелә. Быел чыгачак икенче китап Кырымтатар галиме Нәҗип Хәблиметуглының "Шәфика Гаспралы биографиясе" дигән хезмәте булачак.

• Сафия һәм Иззәт Имре, уңда – вакыфның вице президенты Мәхмүт Әлүкәй. Казан, 1997 ел.

Татарлар илендә төрле вакыфлар башкарган игелекле эшләр тарихы турында киләчәктә махсус китап язылыр әле дигән өмет бар. Шул китап битләрендә Төркиядә оештырылган Әхмәтвәли Мөңгәр вакыфы, аның президенты Сафия ханым Имренең татар халкы өчен, төрки халыклар өчен кылган күркәм вә шәфәгатьле эшләре хакында да рәхмәтле сүзләр үзенә лаек урын алмый калмас.

Ул бит безнең Дәү әни!

Быелның гыйнварында Әминә БИКЧӘНТӘЕВАның тууына 85 ел тулды. Шагыйрәнең сабыйларга атап, үтә дә бер җылылык белән язылган шигырьләре, хикәяләре ничәмә-ничә татар балаларына юлдаш булды, аларга дөньяны танып-белергә ярдәм итте. Инде үзләре өлкәннәр рәтендә саналучы язучылар балачакларыннан Әминә Бикчәнтәеваның тылсымлы шигырьләрен, Абдулла Алишның әкиятләрен, Мирсәй Әмирнең хикәяләрен укып үстеләр, дисәм дә ялгышмам.

Әминә Бикчәнтәева Казанның Бишбалта бистәсендә эшче гаиләсендә туа. Казан педагогия институтын тәмамлый. Аннары Актаныш, Буа мәктәпләрендә, Яшел Үзән каласында укытучы булып эшли. Гомеренең калган язларын туган Казан каласында каршылый.

Булачак шагыйрә Бишбалта мәктәбендә укыганда ук шигырьләр, хикәяләр яза башлый. Аның бәхетенә, мәктәптә әдәбият дәресләрен шагыйрь Хәсән Туфан алып бара. Хискә бай, киләчәккә тыелгысыз омтылыш белән яшәүче кыз баланың иҗатка булган сәләтенә шагыйрь игътибар итми калмагандыр. Мәктәптә әдәбият түгәрәкләренә йөрү, концертларда шигырьләр уку, стена газетләре чыгару – болар барысы да булачак шагыйрәнең язмышын билгеләүдә этәргеч булгандыр. Әминә апа укытучысы Хәсән ага Туфанны һәрчак зур ихтирам белән телгә ала һәм шагыйрә булып җитешүендә үзен аңа бурычлы саный иде.

Әминә Бикчәнтәева Ватан сугышы алдыннан "Яшь ленинчы" газетендә әдәби хезмәткәр булып эшли.

Әле дә хәтеремдә: сугышка хәтле безнең йортка "Яшь ленинчы" газете һәм "Пионер каләме" журналы килә иде. Бу газет белән журнал безне, яңа гына хәреф танырга өйрәнгән авыл балаларын, нинди генә хыял дулкыннарында тибрәтмиләр дә, кайларда гына йөртмиләр иде! Шуңа иманыбыз камил: безнең киләчәгебез якты булыр. Чөнки дөньяда безнең илдән дә матур, иркле ил юк, әлегә туйганчы ашамасак та, бездән рәхәт яшәүче халык юк, булмаган һәм булуы да мөмкин түгел! Без мөкиббән китеп укыган "Яшь ленинчы" белән "Пионер каләме" шул хакта сөйли. Без аларга укытучыларыбызга ышанган кебек ышанабыз. И сабыйлар һәм сабый хәленә төшерелеп җүләрсетелгән әти-әниләр!

Ул чакта әле авылларга радио да кермәгән, телевизор дигән нәрсә әкиятләрдә генә сөйләнә. Авыл балаларын тышкы дөнья белән бәйләп торган бердәнбер мәгълүмат чыганаклары – яраткан газет-журналыбыз. Ә аларда Әминә апаның бер укуда хәтердә кала торган шигырьләре, Абдулла Алишның тылсымлы әкиятләре, Мирсәй Әмирнең укып туймаслык хикәя-повестьлары. Газет тә, журнал да – төссез, рәсемсез, начар гына кәгазьдә басыла. Әмма анысы безне кызыксындырмый (чөнки яхшысын күргәнебез юк). Иң кадерлесе – анда басылган шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр! Аларны укыганда бездән дә бәхетле кеше булдымы икән?! Ул чакларда безгә дәреслекләрдән гайре укыр өчен китаплар юк иде шул. Бәлки шуңадыр да Әминә Бикчәнтәеваның 1939 елны басылып чыккан "Бүләк" дигән китабы безнең өчен чын-чынлап зур бүләк булды.

Әминә апа Бикчәнтәева – гомере буе балалар әдәбиятына тугрылыклы булып калган язучы. Аның сабыйларга һәм яшүсмерләргә атап язылган егермеләп китабы дөнья күрде. Шагыйрәнең "Шинель", "Бакча гөлләре", "Дачада", "Күңелле сөйләшү", "Дәү әнием", "Яз бүләкләре" дигән шигырь җыентыклары, "Мин аңлыйм сине", "Минем танышларым", "Ана йөрәге" һәм башка хикәя, повестьлары балалар өчен тансык бүләк булды. Бүген татар балалар әдәбияты тарихын бу китаплардан башка күз алдына да китерергә мөмкин түгел.

Әминә Бикчәнтәева балалар психологиясен тирәнтен белә. Аның шигырьләреннән һәрчак яктылык, самимилек бөркелә. Алар бер укуда ук күңелдә калалар. Аның шигырьләре эчке музыкага бай, рифмалары төгәл. Шагыйрәнең кыска гына шигырь юлларыннан да нәни кеше үзенә кирәкле мәгълүматны ала, аның дөньяга күзе ачыла. Әйтик, "Көнбагышлар" шигырендә мондый юллар бар:

Сары эшләпә кигәннәр,
Җем-җем итә күзләре,
Гел кояшка караганга,
Кояш төсле йөзләре.

Гап-гади, ап-ачык, сабый сокланмаслык түгел..

Әминә Бикчәнтәеваның повестьлары үсмер балаларга юлланган. "Ана йөрәге", "Мин аңлыйм сине" повестьлары яшүсмерләр тормышына багышланган. Боларда автор балалар тәрбиясе мәсьәләләрен үзәккә куя. Кызыклы язмышлар үрнәгендә кеше шәхесе формалашуда хезмәтнең һәм әйләнә-тирәнең йогынтысы турында тәфсилләп сөйли.

Шагыйрәнең иҗатына анализ ясау тәнкыйтьчеләр эше. Мине баш иярга мәҗбүр иткәне шагыйрәнең шәхесе...

Октябрь инкыйлабы булганда Әминә апага нибары 4 кенә яшь тула. Аның бөтен гомере совет илендә булган вакыйгалар шаукымына үрелеп бара. Совет мәктәбендә укый, шунда дөньяга карашы формалаша. Әмма гомере буе редакцияләрдә, китап нәшриятында, радиокомитетта эшләсә дә, ул партиягә кермәде. Ул гади эшче гаиләсендә тәрбияләнгән, эчкерсез, гаҗәеп тыйнак, сабыр һәм киң күңелле иде. Күңеле тулы сагыш йөрткән бу илаһи затның сабырлыгына кайчакларда хәйран каласың.

Тормыш шагыйрә өчен тоташ сынау булды. Яраткан кешесенең хыянәтенә бәйле рәвештә җилкәсенә төшкән авыр йөкне ул ялгыз күтәрде. Бер ялгызы ике бала тәрбияләп үстерде, карт әнисен карады. Әмма беркайчан да зарланмады. Көне-төне җигелеп эшләде. Шигырьләр, хикәяләр, повестьлар язды. Ләкин "кара сакалы" үзеннән калмады. Чөнки катлы-катлы буйсынудагы колония булган автономияле республика шартларында иҗат кешесенә хезмәт хакын тиенләп кенә түлиләр иде. Язган китапларның әҗерен әйткән дә юк. (Һәр әдәби китаптан алынган керемнең бары биш проценты гына язучыга тигәнен без хәзер генә беләбез). Юкса, дөньяга чыккан егермеләп китап өчен тиешлесен алган тәкъдирдә дә Әминә апа затлы ташпулатларда яшәргә тиеш кеше иде. Ә ул гомере буе балконлы фатир турында хыялланды. Соңгы яшәү урыны Ленин районында, ике бүлмәле кысан "хрущевка" иде. Шагыйрәнең үзенә язу өстәле куярлык урын да юк. Ул гомере буе михнәтле тормышта яшәп дөнья куйды.

Шагыйрә Әминә Бикчәнтәева яхшы күңелле, чын иҗат кешесе иде. Ул татар балалар әдәбияты тарихында онытылмас эз калдырды. Ул, чыннан да, балачакның Дәү әнисе кебек...

Роза ХАФИЗОВА,
Татарстанның һәм Русиянең атказанган мәдәният хезмәткәре.

Иҗатта сыналган ДУСЛЫК

Казандагы Г.Тукай музеенда рәссам Эрот Зариповның күренекле шагыйрь Равил Фәйзуллин иҗатына, аның туганнарына, якташларына багышланган күргәзмәсе эшли. Аны ачу тантанасыннан Татарстан радиосы журналисты Нәсим Акмал магнитофон тасмасына язып алган репортажны тәкъдим итәбез.

Г.Тукай музее директоры, язучы Фәрит ЯХИН:

– Безнең әдәбият музее тарихында мондый очрашулар бик сирәк була. Шушы кадәр зыялыларыбызның җыелуы һәм әлеге вакыйга барыбызны да сөендерә. Шуңа беренче чиратта бу тантананың хуҗалары булган Эрот Зариповка һәм Равил Фәйзуллинга рәхмәт әйтер идем. Бүген безнең арада булган һәммә кешенең әйтер сүзе бардыр, дип беләм. Сүз Татарстан Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе Абрек Абзгильдинга бирелә.

Абрек АБЗГИЛЬДИН:

– Шагыйрь юлы – авыр юл. Рәссам юлы аннан да авыррактыр. Шагыйрьләрне кеше белә, ярата, китапларын укый. Рәссамнарның эшен, статистика буенча, халыкның бер-ике проценты гына карый. Безне пропагандалау да юк, китаплар да аз басыла. Ә менә Равилне барлык рәссамнар да белә. Атказанган рәссамыбыз Эрот та билгеле кеше, әлбәттә. Равилне кем генә ясап карамады: Бакый Урманчедан башлап Рәшит Имашка кадәр. Аннан соң Әнвәр Сәйфетдинов, Әхсән Фәсхетдинов... Йөзенә, талантына караганда, Равилне ясавы бик авыр. Менә шуны тоемлап, шагыйрьгә гашыйк булып, Эрот үз ысулын, үз күремен безгә ачып сала. Сәнгатькә гашыйк Эрот Зарипов күргәзмәсе бүген матурлык булып кына каралмый. Нәкъ менә философ буларак, ул шагыйрьнең нәсел-нәсәбен, Балык Бистәсенең иң матур егетләрен күрсәтә алган. Ул үзе бер йөрмәк энциклопедиясе, йөрмәк музеймы?! Рәссамнарның теләге: бу күргәзмә монда гына калмасын, Балык Бистәсендә дә күрсәтелсен иде.

Равилгә без барыбыз да гашыйк. Мөхәррир буларак та, ул безгә зур ярдәм итә, пропагандалый. "Казан утлары" журналының һәр санында диярлек рәсемнәребез чыгып тора.

Татарстан мәгълүмат һәм матбугат министры Ислам ӘХМӘТҖАНОВ:

– Һәм Равил Фәйзуллинның, һәм Эрот Зариповның сәнгатьтә, әдәбиятта үз кыйбласы, үз җыры, үз укучылары, үз тамашачылары бар. Һәм без бүген олы вакыйганың шаһитләре: шагыйрь белән рәссамның бер-берсен тулыландырып иҗат иткән күргәзмәсен карыйбыз. Аларның икесенә дә уңышлар, җан тынычлыгы телик.

Лилия ИМАЕВА:

– Менә без – тарихи йортта, бөек Тукаебыз исемен йөрткән, аның хатирәсен халыкка җиткерә торган музейда иҗади дуслыкның шаһитләре. Бу очрашу да, мөгаен, тарихка кереп калыр. Чөнки талантлы татар егетләренең бәйрәме бүген. Аларның иҗат юллары озын булсын һәм халкыбызны да менә шушылай шатландырып торсын.

Татарстанның халык язучысы Гариф АХУНОВ:

– Равил турында озаклап сөйләп тормыйм, чөнки мин аны 20 яшендә Әлмәткә язучылар җитәкчесе итеп илтеп куйдым. Бусы – бер. Аннан соң РСФСР Язучылар берлегендә берденбер комсомол шагыйрь иде ул. Равилнең Җәлил исемендәге бүләк иясе булуы да, аннан соң Тукай бүләген алуы да бик табигый. Ә Эротның бу эше, Лилия ханым Имаева матур итеп әйткәнчә, аның XXI гасырда яшәүче кешеләргә бүләге. Аларда тарихка мөнәсәбәт чагыла: менә нинди затлы кешеләр, менә нинди рәссамнар, менә нинди шагыйрьләр яшәгән икән, дип караячаклар. Равил үзенең туганнарын ясаткан, аннан килеп Балык Бистәсенә бик зур ихтирам күрсәткән. Үзенең портреты да бик көчле, һәм өстәвенә китапларын да куйган.

Балык Бистәсе районы хакимияте башлыгы Хатип ГАЗИЗОВ:

– Шушы гомер яшәп, үземнең рәссам ясаган сурәтемне беренче мәртәбә күрәм. Менә Фәтхерахман Әхмәдиев. Горурланырлык шәхесебез. Ул – минем укытучым: көйгә, җырларга өйрәтте. Кемнең генә рәсемен карасаң да – барысы да Балык Бистәлеләр. Равил абый, Эрот абый, ихлас күңелдән сезгә бик зур рәхмәт: Балык Бистәсен шушылай итеп күтәргән өчен, алар турында рәсемнәр белән аңлаткан өчен. Безнең бистәбездә мәгънәле, тирән хисле, эшчән халык яши. Тупланып, берләшеп районга килегез, танышыгыз, карагыз, күрегез, языгыз, рәсемнәрен ясап чыгыгыз безнең халыкның. Сезгә кулыбыздан килгән бөтен мөмкинлекләрне тудырырбыз.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат МӨХӘММӘДИЕВ:

– Без бу музейда даими кунакка әверелдек. Менә өченче тапкыр безне Эрот Зарипов кунакка чакыра. Беренче күргәзмә – Илдар Юзеев, икенчесе Шәүкәт Галиев иҗатына багышланган иде. Бусы – шулай ук зур каләм остасының иҗатына, тормыш юлына, якташларына багышланган. Бер уйласаң, без милли күтәрелеш чорында яшибез. Шул ук вакытта милләтебезне саклау өчен гомер булмаганча авыр чор кичерәбез. Һәм менә шушы юллар белән, бөтен мөмкинлекләрне файдаланып, поэзияне, әдәбиятны, туган телебезне пропагандалап барсак та, әле безгә бик таманга килә. Милләтебезнең тамыры булган поэзия, әдәбият пропагандага бик тә мохтаҗ. Равил Фәйзуллинның иҗатын олылаган, хөрмәт иткән рәссамның максаты – шагыйрьнең тамырлары булган туган як һәм шул төбәктә туып-үскән кешеләр һәм андагы талант ияләрен күрсәтү. Хатип Фатыйхович шаярып сөйләсә дә, чынлап та, бу як артык кадер күреп, артык макталып бозылган төбәк түгел. Хәтта 21 нче елгы ачлык заманында да иң күп халык үлгән төбәкләрнең берсе Балык Бистәсе булган. Бу як гомергә Рыбная Слобода булып яшәде. Без менә аның Балык Бистәсенә әверелгән бер чорын күрәбез. Татар халкының җанын берләштереп торган бер төбәккә әверелүенә менә шушы егетләр: Равил Фәйзуллин, Хатип Газизов, Эрот Зарипов кебек каһарман егетләрнең эше сәбәпче дип саныйм. Бу күргәзмә, әлбәттә, халкыбызның сәнгате, әдәбияты тарихында күренекле бер вакыйга.

Татарстан китап нәшрияты директоры Харис ӘШРӘФҖАНОВ:

– Без заманында Равил белән ярыша-ярыша шигырь яза башлаган идек. Мин моны үземне пропагандалау өчен әйтмим. Сәвит мәктәбе кемнәрне генә чыгармаган: эттән ала да туа, кола да туа, дип әйтәм. Менә хәзер мин – әдәбиятның хезмәтчесе, алар – безнең хуҗалар шикелле. Чыгыш ясаучылар шагыйрьнең әти-әнисенең рәсемнәре турында матур итеп әйттеләр. Фотодан гына торган экспонатлар булса, болай сокланып карамаслар иде. Ә фотога охшатып ясалган рәсемнәрне бик мактыйлар. Мин Равилнең әти-әнисен беләрәк әйтәм: рәсемнәр чынлап та, бик әйбәт чыккан. Аннан соң рәссам ике хакимият башлыгын ясаган. Һәр ике район сәнгать кешеләренә бай. Балык Бистәсе турында Хатип Фатыйхович әйтте инде. Биредә безнең Вахитов районы (төп шушы районда эшлибез ич инде) хакимият башлыгын да күрәбез. Димәк, рәссам бер яклы гына эшләмәгән. Аннан соң китаплар турында әйтелде. Алар, чынлап та, мактауга лаек. Күбесе – безнеке. Без шуның белән горурланабыз. Эрот кемгә ышыкланырга, кем белән дус булырга икәнен белгән. Әдәбиятыбызны пропагандалауга тагын да зур өлеш кертүегезне телим.

Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты рәисе Индус ТАҺИРОВ:

– Бервакыт Балык Бистәсеннән чыккан Равил Шәрәфи сәхнәдән үзенең ягы турында, балыксыз Балык Бистәсе, дип әйткән иде. Ә бүген Марсель Галиев килеп, карап чыкты да, кара, безнең милләт эшли икән бит, ди, бай икән, ди. Димәк, "балык" бар инде. Район башлыгы Хатип туган күрсәтте, чыннан да, Балык Бистәсе төрле нәрсәгә бай икән. Һәм аның иң зур байлыгы – шундый затлы кешеләрне тудыра һәм үстерә белүдә. Ике кеше – Равил белән Эрот кечкенә генә бер бүлмәгә сыйдырып, шушы байлыкны күрсәтә алганнар.

Татарстанның атказанган артисты Гөлзадә:

– Бу – милләтебез өчен чын мәгънәсендә бәйрәм, зур шатлык. Бу башлангыч дәвамлы булсын иде. Халыктан кайвакыт Равил Фәйзуллин әле исәнмени, дигән сүзләрне дә ишетергә туры килә. Чөнки без туганда да Равил Фәйзуллин бар иде, без аның шигырьләрен тыңлап үстек, әле дә Равил Фәйзуллин исән һәм ул һаман да яшь, һаман да шулай яза, шуңа күрә халык аны үзенеке дип кабул итте. Һәм инде бүген аның халык үзенеке дип кабул иткән "Аккошлар" дигән җырын сезнең белән бергә, бер тавыштан башкарасым килә.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН:

– Монда минем турыда бик зур сүзләр сөйләнде. Дөресен генә әйткәндә, минем бәйрәмнән бигрәк, Эрот бәйрәме. Рәссам бәйрәме бу. Бу очракта мин материал булдыручы, сәбәпче булып кына басып торам. Эрот әйтә, пыяла кирәк булыр инде, ди. Мин әйтәм, ярар, пыяла табарбыз. Рам кирәк, ди. Табарбыз, дим. Карточкалар, фоторәсемнәр, ди. Мин шуңа күрә аның тәэминатчысы, булышчысы гына булып йөрдем. Бу күргәзмәдә җитмештән артык экспонат бар. Аларда ниндидер бер мәгънә ята. Һәммәсендә дә. Эротның өстән кушмыйча, бернинди юбилей уңае белән түгел, бер нәрсә вәгъдә итмәгән килеш, бер тиенсез дип әйтим инде, шушы эшкә алынып, һәм берничә ай эчендә эшләп чыгуына таң калдым. Безнең халыкның талантлары бик күп. Әгәр дә үзләренең талантларын шушылай эшләп күрсәтсәләр, минемчә, безнең милләтнең язмышы һәм күркәмрәк, һәм эшенең нәтиҗәсе күбрәк булыр иде. Бүген, һичшиксез, минем өчен бик истәлекле көн. Бу залга татар халкының иң зыялы кешеләренең каймагы җыелган. Без Яңа ел бәйрәмнәрендә чыршы куярга яратабыз. Шуның тирәсендә бәйрәм була. Көннәр үтә, аннан соң ул чыршыны чыгарып аталар. Ул юл кырыйларында инде кирәксез нәрсә булып ята. Сәнгатьтә – ул китапмы, ул картинамы – бүген макталган, балкып торган әйберләр иртәгә кирәксез булмасын, халыкка хезмәт итсен иде.

Язманы гәзит өчен **Шәех ЗӘБИРОВ** әзерләде.

● ***"Шагыйрь Равил Фәйзуллин". Э.Зарипов эше.***

● ***Күргәзмәне ачу тантанасында (уңнан сулга – рәссам Э.Зарипов, шагыйрь Р.Фәйзуллин, академик И.Таһиров, шагыйрь Ә.Рәшит, язучылар Р.Мөхәммәдиев һәм Ф.Яхин).***

М.ШАКИРҖАНОВ фотолары.

Бәҗай бәлеш ашамый

Яшәгән, ди, ике баҗай. Берсе бик тә үткер, шаян, икенчесе йомыкыйрак та, оялчанрак та икән боларның. Беренче баҗай җае чыккан саен икенчесен котыртырга, аннан көләргә маһир, имеш. Кәҗә хайван түгел, баҗа туган түгел, дисәләр дә, баҗаларның очрашмый-аралашмый яшәр чамасы юк: ни дисәң дә, хатыннары бертуган бит.

Менә шул. Мәҗлесләрдә утырганда елгыр баҗай ялт итеп кенә юашының авызын томалый да куя: "Кыстамагыз, минем баҗай бәлеш яратмай, баҗай бәлеш ашамай", – ди. Ә тегесенең кире кагарга кыюлыгы җитми. Аның каравы, беренче баҗайга күбрәк тия.

Бу мәзәкне сөйләвемнең сәбәбе ни, дисезме? Сәбәбе – Татарстан радиосыннан яңгыраган "Сезнең китап киштәгезгә" дигән тапшырудагы бер әңгәмә (7 февраль, 1998 ел). Язучы Фәнзаман Баттал оештырган бу әңгәмәдә Татарстан китап нәшрияты директоры могтәбәр Харис әфәнде Әшрәфҗанов:

– Шигырь китапларын кечкенә тираж белән чыгарабыз. Чөнки шигырьне халык укымый, – диде. (Соңрак нәни генә төзәтмә керттекертүен: Гамил Афзалны яисә Харрас Әюпне укырга мөмкиннәр).

Кем белә, бәлки, сатира остасы Фәнзаман Баттал, тирән яшерелгән эчке мәгънә белән, радио тыңлаучыларга нәшрият директорын шушы рәвешчә күрсәтергә уйлагандыр. Һәрхәлдә, бу очракта үземнең нинди халәт кичергәнемне бер сүз белән әйтеп аңлата алмыйм. Әле утка, әле суга төшкәндәй булдым. Шигырь бәйрәмнәрендә мәйданга сыймаган халык күз алдыма килде. Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмнең бер сулыш белән суырып алгандай кабул ителгән иҗат кичәсе исемә төште. Роберт Әхмәтҗан, Харрас Әюп кичәләрендә утыру түгел, басып торыр урын булмаганын уйладым. "Йөрәктән чыккан сүзем, һичшиксез, йөрәккә барып җитәр", – дигәндәй, халык алдына янып, дулкынланып чыгып баскан мәрхүм Рәшит абый Әхмәтҗан, нечкә хисле Әхмәт абый Рәшит, шашкын табигатьле Лена апа Шагыйрьҗан, тыйнак елмаюлы Шәүкәт абый Галиев, "Шигърият – әдәбиятның әнкәсе" дип инанган Рәдиф абый Гаташ... һәм аларның һәр сүзен йотлыгып тыңлаган тамашачы (димәк, укучы) күз алдымнан бер-бер артлы тезелеп үтте. Тагын бер вакыйга – Милли китапханәнең "Иң күп укыла торган китап" конкурсында шагыйрә Рифә Рахманның "Шук алма, моңсу алма" дигән китабы икенче дәрәҗә диплом алган иде.

Ә без: "Баҗай бәлеш ашамый", – дибез! Бала чагымнан истә калган: үзара гап-гади сүзләр сөйләшкән чагында да, үз әбием булсынмы, күрше-күләнме, әле Габдулла Тукайның, әле Сәгыйт Рәмиевнең шигъри тезмәләрен оста гына үрә дә җибәрә иде сүзгә. Мәсәлән, "И надан, тугъ яңадан мәгърифәтле анадан...", – ди. (Хәер, боларның авторларын мин үсә-үсә генә белдем). Халык шигырь яратмаганга күрә ул "Кыйссаи Йосыф"лар, "Сак-Сок бәет"ләре һәм башка тарихи дастаннар халык телендә гасырлардан гасырларга юлга-юл, сүзгә-сүз күчеп барганмыни?

Мин бүгенге көндә дә әдәбият дөньясыннан шактый ерак торган гапгади механизаторлар, инженерлар арасыннан көндәлек матбугат сәхифәләреннән иң элек шигырь эзләп укый торган бик күп кешеләрне беләм. Әле генә "Ватаным Татарстан" гәзитендә шагыйрь Кави Латыйпның редакциягә килгән шигырьләр турындагы язмасы басылып чыкты (6 февраль, 1998 ел, "Шагыйрь булып туалар"). Редакциягә шигырьләр ява. Ә шигырь укымаган кеше шигырь язамыни ул?! "Ничек кенә булмасын, шигъриятне бетереп тә, үтереп тә булмый, ул – мәңгелек жанр. Шул сәбәпле, рухи дога рәвешендә сиксән-туксанйөз яшьтәгеләр дә шигырь язалардыр да инде. Кыскасы, шигърият яшәтә дә, яшәртә дә", – ди Кави ага.

Дөрес анысы, акча юк, дигән ачы хакыйкать тә бар бу дөньяда. Менә анысына каршы бөтен дәлилләр дә көчсез инде. Әнә, бер җитәкчебез: "Хастаханәләрдә авыруларга дарулар җитми, акча юк, ә сез китап турында сөйлисез", – дип "оялта". Ул да хаклы инде. Гөнаһ шомлыгына күрә, бездәй мәхлукларның Ходай биргән кыска гына гомерендә дә китап та укыйсы, язасы да килә шул. Тик шунысы кызганыч, кешеләрне рухи ярлылыкка илтү максатларында акчасы да табыла. (Порно һәм эротик кассеталар, китаплар... Юк-бар тауарга реклама... Бу очракта, безнең китап нәшриятын күздә тотуым түгел). Әдәбиятны, аның да әнкәсе саналган шигъриятне яратучыларны күбрәк тәрбияли алсак (яратканнарыннан да ваз кичү ягын каермасак), дөньябыз да күпкә матуррак булмас идеме икән?!

Тукайда менә мондый шигъри юллар да бар:

Сиңа, дустым, сүзем шулдыр:
татарга сатма матбугат,
Тырактир ач татарга, –
сат та тор һәртөрле мәшрубат.
("Бер гәзитә идарәсе хәленнән").

Бәлки, чыннан да, шул юлга борылыргадыр? Укымаган, надан татарга китап укытырга, "яратмаган" шигырьләрен көчләп тагарга маташканчы, "тырактир" ачу хәерлерәктер?

Сер итеп кенә әйткәндә, минем үземнең дә моннан биш еллар элек планга кергән шигырь китабым нәшриятта ята. Шигъриятькә мөнәсәбәткә караганда, мин бу сүзләрне әйтсәм дә-әйтмәсәм дә, аның инде дөнья күрүе икеле. Акча түләп чыгарырлык байлыгым да юк. Ярар, хәерле булсын.

Гаҗәпләнеп тә куясың: кайчандыр үзе дә шигырь "кыштырдаткан" (үз сүзләре) кеше буларак, хөрмәтле директорыбыз бәгырьләрдән өзелеп төшкән шигъри сүзнең бәһасен ничек инде аңлап җиткермәсен?! Һәрхәлдә, мин аның әлеге чыгышын шулайрак кабул иттем.

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА.

ЙОЛДЫЗНАМӘ
(23 февраль - 1 март)

КУЧКАР (21.03-20.04). Сез гаҗәп уңышлы атнада яшисез. Эшегездә, гаиләгездә иминлек, бәхет кичерәсез. Ялгызакларга мәхәббәт елмая һәм дустанә мөнәсәбәтләр урнаша. 24е көнне рухи ихтыяҗыгызны канәгатьләндерү белән шөгыльләнегез, изге эшләр башкарыгыз. Илаһи серле көчләр сезнең карамакта, җан таләбенә игътибар итегез. 28е көнне мөһим мәсьәләләр хәл итүгә алынмагыз.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04-21.05). 25, 27се көнне сезне сәфәр көтә. Ул эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруны күздә тота. 26сы көнне финанс мәсьәләләрен хәл иткәндә сакчыллык күрсәтегез, рәсми кәгазьләргә имза салырга ашыкмагыз, үзегезгә зыян китерүегез бар. 23е көнне күптән хыялда йөрткән, планлаштырып куйган зур, әһәмияткә ия эшләргә керешегез, уңарсыз, гомумән, февральнең соңгы атнасы тормышның күп өлкәсендә сезгә шәфкатьле, уңыш юллый.

ИГЕЗӘКЛӘР (22.05-21.06). Бу атна сездән зур сабырлык таләп итә. Язмыш борылышлары шактый гына күңелсез вакыйгалар, бәхәсле мәсьәләләр китереп куя. Эштә дә, гаиләгездә дә, хәтта шәһәр транспортында да үзегезне кулда тотыгыз, кирәкмәгән сүздән читләшегез, өлкәннәр сүзенә каршы килмәгез, җитәкчегез сүзен тыңлагыз. Җитәкче Игезәкләр дә үзләренең начар кәефен коллективка "аудармый" гына үткәреп җибәрсен иде бу атнасын.

КЫСЛА (22.06-22.07). Бу атна сезнең өчен дә сынаулар куя. 25е көнне сәфәргә чыгарсыз һәм бераз тынычлану алырсыз. 26, 27се көнне гадәти эшләр белән мавыгыгыз, җан тынычлыгы китерә торган шөгыль табыгыз. Сәламәтлек турында кайгырту да таләп ителә, бәхетсезлектән сакланыгыз. Ызгыш-талашлардан сакланыгыз, юкка нерв бозмагыз, якты, матур көн туасын уйлагыз.

АРЫСЛАН (23.07-23.08). Атна башы, хәер, ул якшәмбегә кадәр, сездән тупланганлык, оешканлык һәм игътибарлылык таләп итә. Хезмәттәшлек урнаштырып, аның беренче нәтиҗәләрен татысагыз да, бәхәсле минутлар шактый күзәтелә. 28е көнне акчагыз белән сак булыгыз, гомумән, матди байлык мәсьәләсендә уяулык күрсәтегез.

КЫЗ (24.08-23.09). 23, 25, 26, 27, 1е сезнең өчен бик уңышлы көннәр. Бу атнада зур рухи канәгатьләнү кичерерсез, чөнки сез илаһи көчләр карамагында. Гаиләгездә бәхет, тулы аңлашучанлык, эшегездә тагын да үсеш юлында. Сәфәр чыгарсыз, юлыгыз уңар, ниятегез тормышка ашар. Ләкин 28е көнне аеруча җаваплы эшләргә алынмагыз.

ҮЛЧӘҮ (24.09-23.10). Атна сезнең сәламәтлекне сынаудан башлый. Юлдагы, транспорттагы, эштәге бәхетсезлекләрдән сакланудан тыш та, сезгә сәламәтлегегезне даими кайгыртып тору кирәк. 25, 26, 28е сезнең өчен эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыру һәм шуның сөенечле нәтиҗәләрен барлау көннәре. Көтелмәгән, әмма шатлыклы вакыйгалар шаһите булуыгыз да бик мөмкин.

ЧАЯН (24.10-22.11). 25, 27, 28, 1е сезнең өчен уңайлы көннәр.Әмма атнаның беренче көне акчагызга сакчыл караш күрсәтүне таләп итә. 24е көнне вактөяк эшләр башкарыгыз, мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә алынмагыз. Бу атна сездән ихтыяр көчен туплап эш итүне, башкаларга игътибар күрсәтүне сорый.

УКЧЫ (23.11-21.12). Юлга чыгарсыз, аннан яңа тәэсирләр алырсыз. Әмма кайбер кешеләрнең икейөзле мөнәсәбәтен күреп, өметсезлек кичерерсез. Шулай да атна сезгә зур уңышлар, мул акча, табыш, эшегездә дәрәҗәле үсеш юллый. 28е көнне җан таләбен канәгатьләндерегез, рухи байлык арттыру өстендә эшләгез. Илаһи көчләр сезгә шәфкать кыла.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12-20.01). Сез эзләнү өстендә, эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруда, юлда, кешеләр арасында. Тирә-юньдәге байтак нәрсә сезне борчый, тетрәндерә, рухи туплануны таләп итә. Эзләнүләр сезне кызыклы очрашуларга, аралашуларга китерә.

СУКОЯР (21.01-19.02). 24, 25, 27, 28, 1е сезнең өчен аеруча уңышлы көннәр. Тәвәккәлләп зур эшләргә алыныгыз, җаваплы кешеләр белән дустанә, эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырыгыз. Ләкин кирәк-кирәкмәскә бәхәсле мәсьәләләргә катнашмагыз, үзегезне тыеп, кулда тотыгыз. Атна сезгә бик күп сөенечле мизгелләр юллый. Сез илаһи серле көчләр карамагында. Изгелек кылырга онытмагыз.

БАЛЫК (20.02-20.03). Атнаның беренче көнендә үк сезгә мул табыш керә. Әмма аның бик тиз юкка чыгу ихтималы да бар. 26сы көнне акчагызга игътибарлы булыгыз. 25е көнне иң зур телэгегез тормышка ашар, дәрәҗәле үсеш кичерерсез, үзегезне бәхетле хис итәрсез. Февральнең соңгы көне шактый гына күңелсез вакыйгалар белән дә сынап карамакчы. Нишләмәк кирәк, кояшлы көн артыннан төн булган кебек, тормыш сөенеч вә көенечтән тора инде ул.

Үз-үзеңне ничек тотарга?

Алма агачыннан ерак төшми

Халыкның гасырлардан килгән тәҗрибәсеннән чыккан әйтем бу. Әйе, күпчелек очракта бала ата-анасына охшап үсә. Балада ата-анасының аңа мөгамәләсе һәм аларның бала алдында үз-үзләрен ничек тотулары чагыла. Балалар ата-ананың яратуына, иркәләвенә мохтаҗ. Моны тоймаганда алар боек, йомыкый, еш кына ачулы булып үсәләр.

Баланы яшь җиләк-җимеш үсентесе итеп күзалларга кирәк. Гадәттә аның тирәсендә бик тиз чүп үләннәре үсеп чыга да, туфрактан яшь үсентегә дигән матдәләрне суырып бетерә, кыса, каплап, аңа кояш нурларын төшерми. Тәҗрибәле бакчачы чүп үләннәрен вакытында йолкып ташламаса, әлеге үсенте ябыга, чирли, ахыр чиктә бөтенләй корый. Баланың мондый хәлдә калуына юл куярга ярамый.

Үсемлекләрдән аермалы буларак, балага үсү өчен уңай шартлар тудыру гына җитенкерәми. Ул ата-ананың ничек сөйләшүен дә, үзара әрләшүләрен дә, башкаларга булган мөнәсәбәтләрен дә бик тиз үзенә сеңдереп бара, үзләштерә. Ата-ана үрнәге бала тормышында хәлиткеч роль уйный.

Беренче чиратта ата-ана өстәл янында үз-үзен тотышы белән үрнәк күрсәтә. Баланы кечкенәдән өстәл янында үзен ничек тотарга, ашаганда приборларны ничек кулланырга өйрәтергә бурычлы. Кунаклар булганда баланы өстәл янына утырту кирәк түгел. Ул кунакларга булган игътибардан көнләшә, үзенә игътибарны җәлеп итү өчен көйсезләнүчән була.

Үсмер чор – бала өчен дә, ата-ана өчен дә иң катлаулы, авыр чор. Еш кына алар арасында бер-беренә ышанмаучылык, аңлашылмаучылык туа. Ата-ана интим мәсьәләләр буенча сөйләшмәскә тырыша, нәтиҗәдә, үсмер үзендә туган сорауларга җавапны бөтенләй башка кешеләрдән, бозык бәндәләрдән алуы ихтимал.

Менә шулардан чыгып, ата-аналарга унике кагыйдәне истә тоту мөһим:

1. Үзегез дә кайчандыр бала булгансыз бит, шуны искә төшерегез.

2. Балаларыгыз – кешеләр алар, тәрбиянең төрле системасын сынап карау өчен кирәкле тренажерлар түгел – шуны онытмагыз.

3. Балагызны хөрмәт итсәгез, ул да сезне гомере буена хөрмәт итәр.

4. Ярату һәм кырыслык үзара үрелеп барырга тиеш.

5. Һәрнәрсәнең чамасы була.

6. Балаңны нинди итеп үстерергә теләсәң, үзең дә шулай яшә.

7. Балаңны туктаусыз үгет-нәсихәтләрең белән туйдырма.

8. Өлкәннәр утырган өстәл янында баланың утыруы кирәк түгел.

9. Балаларыгызны бер-берсенә ярдәм итәргә өйрәтегез.

10. Үз балагыз белән ачыктан-ачык сөйләшергә өйрәнегез.

11. Балагызга ышаныч белдерегез.

12. (Әбиләргә). Әни белән бала арасына кермәгез, акыллы булыгыз.

Балаларыбыз тәрбиясез булып үсмәсен өчен үзебез тәрбиялелек үрнәге күрсәтик.

("Как вести себя в любой компании").

Нури КАМАЛ

ЧИТЛӘШҮ

Булган хәл

Суд бара.Көтмәгәндә килгән көз ямь-яшел яфраклар өстенә уч-уча сары сипкәндәй, яшь хатынның коңгырт чәчләренә чал яткан. Читтән карап торучыга бу чибәр ханым алдындагы елтыр өстәл көзгесеннән үз сылулыгына үзе сокланып утырадыр кебек тоелыр иде.

Менә хәзер казый торып басар да, тагын элекке карарын укыр: "Суд, барысы да үзара ризалык белән булган, көчләү юк, дигән карарга килде. Гаепләнүче, яше җитмәгән үсмер кыз белән җенси мөнәсәбәткә керүе өчен, ирегеннән шартлы рәвештә мәхрүм ителә".

Зал кинәттән тынып калды. Карар укылдымы, юкмы. Таңгөл инде берсен дә ишетми иде. Чөнки ул мәхкәмәдә бүгенге эш кенә карала дип саный алмый. Явызлыкны яшереп калуның ни икәнен Таңгөл үз гомерендә нык аңлады. Явызлыкны яшерсәң, ул тагын да зурая, кешеләрне газаплый, җаннарны кыя, дөньяга сыймаслык булып кабара.

Таңгөл, үзенең кайдалыгын да онытып, урыныннан сикереп торды.

– Юк! Юк! Юк!

Мәхкәмә залы гөжләргә тотынды.

Бары казый гына баягы тынычлыгын һич җуймагандай: "Тынлык! Суд киңәшмәгә китә!" – дип белдерде.

Таңгөлнең бу кыланышын иң аңламаган кеше аның ире Госман иде: аның сабыр Таңгөленә ни булды соң?

Хатынын нидер борчыганын Госман күптән сизә иде. Тик ул аннан сорарга курка. Алла сакласын, сорар да, үзен курыткан җавапны ишетер. Әгәр аңа Таңгөле: "Мин сине ярат-мыйм", – дисә...

Юк-юк, Госман Таңгөленнән башка җирдә дә, күктә дә, оҗмахның үзендә дә яшәргә риза булмас иде. Госман шушы мәхәббәт хакына гына яши. Артык сораулар белән бимазаларга да курка ул аны.

Шулай уйлый-уйлый еллар үтте. Менә инде Таңгөленә охшаган бердәнберләре Чынгөл дә буй җиткерде. Әнисе белән алар ике сердәш кыз кебек. Бер гөлдән ике гүзәл гөл, дип сөенә иде Госман. Әмма дә ләкин Таңгөленең күзләрендәге авыр моң аны һәрчак сагайтты. Ә инде хатынының төннәрендә яшеренеп елауларын ул берничек тә аңлый алмады. Чөнки Таңгөл аның мәхәббәтенә олы мәхәббәт белән җавап бирә, ул гына да түгел, үзен бик тә югары бәяли. Таңгөлдән дә тугры, аннан да ихлас хатын бардыр дип башына да китерә алмады ул. Дөрес, һәркемнең күңелендә була торган кайбер томанлы уйлар Госманда да булды. Тик аларның ачыкланып бетмәвендә ул фәкать үзен генә гаепле саный. Ә кайбер сәер уйларына ышанасы да килми. Таңгөле аныкы гына, һәм бу башка төрле була да алмый.

Госманның уй тасмасына басып, утырыш залына торна сыман нечкә торыклы сәркәтиб кыз килеп керде. Аның артыннан башкалар да күренде. Утырыш дәвам итте.

Госман урыныннан купмады. Гомумән, ул бу залда утырмас та иде. Инде булганы булган дип, фаҗигане үзара сөйләшеп йомшартырга тырышып карар иде. Һәм кызының хурлыгын бөтен дөньяга чыгарып сипмәс иде ул. Ир булган ир Чынгөлен аңлар иде әле. Чибәр кыз бит ул. Гүзәллеге бу гаебен йомшартыр иде, бәлки, дип уйлый һәм, Таңгөленең инде дүртенче тапкыр хөкемгә мөрәҗәгать итеп, шул бәла бүкәнен төрмәгә утыртырга тырышуын, тырышу гына түгел, шуңа бар җанын бирүен аңлый алмый ул. Дүрт елга ирегеннән шартлыча мәхрүм ителү дә җәза бит инде. Менә инде елдан артык шушы юлда йөри-йөри, ул үз-үзен аңламас хәлгә килеп җиткән иде. Аңа хәзер бу вакыйгаларны иксез-чиксез киң яланнарга җәелеп утырган Чаллы шәһәре генә түгел, Казаннан Мәскәүгәчә юлдагы барлык кешеләр беләдер сыман тоела башлады. Аның уенда, миен көйдереп, гел бер сүз яңгырап торды: оят! оят! оят!

Менә шуннан качарга омтылу аның башын яка астына ук тыгып бетерә язды бугай.

Таңгөл дә юкка гына болай сыгылмыйдыр бит инде. Әйе, фаҗига зур. Тик хатынының халәте бу фаҗигадан йөз, мең тапкыр аянычрак тоела аңа.

– Суд килә! – Залга яңадан казый, адвокатлар, утырышчылар керә.

– Бар нәрсәләрне эзлекле рәвештә янә күзәтеп чыгарга булдык, – ди казый.

– Чынгөл Галиева, барысын да рәттән, җентекләп сөйлә, берни төшереп калдырмыйча...

– Сөйләдем ич инде, – ди кыз.

Аның газап тулы күзләре, нәкъ әнисенеке шикелле, бер ноктага төбәлә.Башы иелә. Күзләрендә яшь бөртекләре ялтырый. Госман, кайгысын үзенә тартып алырдай булып, кызына карап тора.

Аннан соң ул теләр-теләмәс дәвам итә:

– Авылга кунакка кайткан идем. Рәфис белән дуслаштык. Ул миңа, яратам, диде.

– Ә син яраттыңмы аны? – Казыйның сүзләре катгый, дәшми яки ялган җавап белән калдыра торган түгел.

– Әйе, мин дә, – дип өстәде Чынгөл, елап җибәрүдән чак тыелып. – Су буена төштек. Анда таллык. Шунда йөрдек.

Кочаклаштык. Үбештек. Аннан соң ул мине таллыктагы үлән өстенә өйдәде. Аның курткасын җәеп утырдык.

– Сәгать ничә иде?

Казыйның бу соравы Госманның җанын пычак белән уеп төшергәндәй булды.

– Сәгать? Сәгать төнге өч иде...

Госманның башында уйлар өермәсе бөтерелә. Тукта әле, теге бәла баганасын яклап утырган адвокат Сафа Сабирович дигәннәре бу сорауны әллә ничә тапкыр бирде бит инде. Өстәвенә, әле тәнәфестә сөйләшкәндә: "Агай, кызлы кеше кызын тыйсын, егетләрне тыймасын", – дип тә ычкындырып куйган иде. Юкса бит, үзенең дә 16 яшьлек кызы бар, Татарстан гүзәле, "Мисс Сөембикә" бәйгесенең иң зур бүләген алган, диделәр. Ә минем кызым – Чынгөлем нишләде? Үзен гаепләүне башына да китерә алмаган Госман кинәт куркак куян хәленә килде, гаепле ләбаса ул! Кызын, Чынгөлен кызларча саклыкка өйрәтмәгән.

Госман иреннәрен дерелдәтеп сөйләп торган кызына күтәрелеп карады. Шушындый көндә дә калын итеп буялган күз кабаклары, тушь буяу салудан авырайган озын керфекләре, кыпкызыл озын тырнаклары, нәзек бармаклары беренче мәртәбә аңа ямьсез, хәтта җирәнгеч булып күренделәр.

Госман күз карашын хатынына текәде.

Ул аны танымады. "Монда тагын да нидер бар, миннән барысын да яшергәннәр. Әле дә әйтмиләр," – дигән уй миен көйдереп үтте. Әле генә җанын бирердәй булып торган ике гүзәл зат аңа чит-ят иде инде.

Чынгөл һаман сөйли. Ни сөйли бит әле! Төнге сәгать өчтә. Чит авылда. Әзмәвердәй егет белән япа-ялгызы... Шуннан соң Госманның колагына ирешкән сүзләр тагын да ямьсез, җирәнгеч булып тоелды.

– Ул мине үләнгә егып салды, авызымны иреннәре белән томалады да ... Иртән мин джинсы чалбарымны юып элдем. Апа шуннан сизде. Чөнки мин аны алдагы көнне генә юган идем.

Казый тагы сораулар яудырды.

– Рәфис көчләде, дип ник кайткач та әйтмәдең?

– Курыктым...

Казый Таңгөлгә борылды:

– Ә сезгә кайчан әйтте?

Таңгөл тагы урыныннан сикереп торды. Аның тавышы өзелеп китте. Һәм ул, чак-чак сулыш алып, өзек-өзек дәвам итте.

– Әйтте. Көчләнгән. Төрмә аңа. Утыртмыйча туктасым юк! Гаражны да, өйне дә сатам... Җинаятькә җәза бирелергә тиеш. Миңа дөньяда башка берни дә кирәкми. Ул аның җанына гомере буе утлы күмер булып кереп урнашачак бит. Ни өчен ул кемнеңдер җинаяте өчен гомер буе минем кебек газапланырга тиеш!?

Таңгөл өстәлгә авып төште.

Бер мәлгә югалып калган казый: "Тынычланыгыз! Болай дәвам итеп булмый!" – диде.

Йөзеннән мәңге бер уй-хис укып булмас адвокатның күзләрендә беренче тапкыр уйчан чалымнар күренде. Ул, җитез хәрәкәтләр белән, графиннан стаканга су коеп, хатын алдына куйды. Һәм, җавап бирмәсәң дә була дигән кыяфәт белән: "Таңгөл ханым, сезнең белән дә шуңа охшаш хәл булган идемени?" – дип сорады.

Әйе, адвокат Таңгөл ханым белән ни булганын күптән белә. Тик бу мәхкәмә башланыр алдыннан якты дөнья белән хушлашкан әнисенең йөрәгендә гомере буе йөрткән серен адвокатка ачып калдыргандыр, дип берсе дә башына китерә алмый иде. Сафаның гадәте: хатын-кыз мәсьәләсе килеп тудымы, иң элек ул аның әнисен, әбисен, ата-бабасын күреп сөйләшергә тырыша.Бу юлы да шулай булды. Күңеле сизенгәндәй, машинасын Кукмара якларыннан Чаллыга, аннан авылга кадәр куса куды – әмма үлем түшәгендәге әбине күреп сөйләште һәм сәер вакыйганың серенә төшенде.

Сафага Сәрвәр әби чынлап та газаптан, бу очракта, авыр серне яшереп яшәтү газабыннан үлеп барадыр төсле тоелды.

Залда газаплы үксү һаман яңгырап тора.Госманнын күз карашы хатынына төбәлгән. Тузгыган чәчләр. Елаудан шешенгән күзләр. Таңгөл бу юлы убырлы карчыкны хәтерләтте.

– Әйе, – диде ул, – мин еламыйм инде. Әмма минем кияүгә чыкканда әниемнәрдә яшереп калдырган кызым җанымда гомерем буе үксеп илерде.

Залда үлем тынлыгы урнашты. Адвокат Сафа ул кызны да күрде. Әби аңа кызның кайдалыгын да әйтте. Ул олы җанлы әбигә рәхмәтләр укый һәм каршысында үз сеңлесен яклап утырган адвокат кызның күзләренә күтәрелеп карарга да курка иде.

Юк, Сафа адвокат Айгөлдән курыкмый, ул акыллы, ипле, олы кара күзле, моңсу карашлы Айгөлне күптән белә, тик ул әбигә биргән антын бозудан курка.

– ...Мине дә яратам, – диделәр.

Залда Айгөл тавышы яңгырап киткәндәй булды. Сафа Таңгөлгә таба борылды. Әйе, Айгөл түгел, әнисе Таңгөл сөйли икән.

– Мине дә яратам, – диделәр. Мине дә. Ул...– Таңгөл гаепләнүче Рәфискә төртеп күрсәтте, – ул шушы оятсызның әтисе!!! – Таңгөл тагы, сүзен әйтә алмыйча, илереп кычкырды:

– Атасы – мине, улы – кызымны...

Үз гомерендә беренче тапкыр горурлыгы баш күтәргән ирнең, һушын югалтып, почмактагы көнәфигә авып төшкәнен беркем дә күрмәде бугай.

Мәхкәмә кичектерелде. Залдан чыгып барышлый, ишек төбендә басып калган ап-ак чәчле, бөкшәйгән карты яныннан Таңгөл дә, Чынгөл дә игътибарсыз гына узып киттеләр һәм, бина каршында калган машиналары янына чыгып, Госманны көтә башладылар.

Госман ишек төбендәге көнәфидә утыра да утыра. Менә диварга беркетелгән көзгегә күзе төште. Аннан аңа ап-ак чәчле бер карт карап тора иде.

Таңгөл белән Чынгөл, Госманның чыгуын көтеп, карашларын ишеккә текәгәннәр. Кинәт әллә каян гына чыккан көчле җил аларның күлмәк итәкләрен күтәреп башларына кадәр каплады.

Чәбәләнә-чәбәләнә итәкләрен чак җыеп өлгергән бу икенең алдындагы зәңгәр машина өстенә шартлап каен ботагы сынып төште.

– Кая булды инде теге бозау, – дип үртәлгәнен Таңгөл үзе дә сизми калды, ахры. Аннан, кызының янында торганлыгын исенә төшергәндәй:

– Бар, алып чык әтиеңне, теленә бетеп торадыр, берәрсе белән, – дип Чынгөлгә эндәште.

Чынгөл исе дә китмәгән кыяфәт белән: "Бар, кирәксә үзең кереп ал!" – диде. Машина өстеннән алып ташлыйм дип, кулына алган каен ботагын тоткан Таңгөл катты да калды. Гүя ул токлы чыбыкка килеп тотынган. Күз алдында, уйнап киткәндәй, очкыннар сибелде. Шунда Таңгөл канлы тырнакларын аның йөзенә батырырга чамалап үзенә таба очып килүче каракошны шәйләп алды.

Бу – һушын югалтып авып баручы әнисен тотып калырга укталган Чынгөл куллары иде.

"Мәдәни җомга" гәзитен алдырам һәм яратып укыйм, шуңа күрә сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым.

Без ирем белән бер ел да сигез ай яшәдек. Ирем 1995 елның ноябрь аенда чыгып киткәч, кире әйләнеп кайтмады. Милиция эзләсә дә, таба алмый әле.

Без – кызым һәм иремнең әнисе белән бергә яшәдек. Иремнең туганнары (абыйсы, апасы), ул өйдә пропискада тормасалар да, яшәргә ирек бирмәделәр. Без кызым белән чыгып китәргә мәҗбүр булдык. 1997 елның декабрь аенда иремнең әнисе үлде. Без әле һаман да шул йортта пропискада торабыз.

Ул йортта безнең өлешебез бармы?

3 яшьлек кызыма пособие тиешлеме һәм моның өчен нинди документлар кирәк?

Алдан рәхмәт әйтеп, Максутова.
Минзәлә.

Бу хатка җавап бирүне үтенеп, без Татарстан журналистларының хокукларын яклау комитеты рәисе, юрист Назыйм Сафинга мөрәҗәгать иттек. Түбәндә аның җавабын урнаштырабыз.

Хатыгызда юридик киңәш бирер өчен кайбер мәгълүматлар җитеп бетми. Сезнең нинди йортта яшәвегез билгеле түгел. Әгәр Минзәлә шәһәренең дәүләт йортында яшәгән булсагыз, сез ул фатирга кире әйләнеп кайтып яши аласыз. Ирегезнең анасы үлгәннән соң, пропискада бары сез генә (балагыз белән, әлбәттә) калгансыз бит инде. Шулай булгач, сезгә беркем дә комачаулый алмый. Әгәр дә бу фатирның дәүләтнеке булуына карамастан, сезгә анда керергә ирегезнең туганнары каршылык күрсәтә икән, аларны судка бирә аласыз.

Ирегезнең югалуы мәсьәләсенә килгәндә, сез аның билгесез югалуын тануны сорап, судка мөрәҗәгать итә аласыз. Моның өчен эчке эшләр органнарыннан ирегезне эзләүнең нәтиҗәсе турында белешмә алырга кирәк. Суд карары чыкканнан соң, сез балагызга пенсия юллый аласыз.

Әгәр дә инде сез шәхси йортта яки хосусыйлаштырылмаган фатирда яшәгән булсагыз, мәсьәлә бераз катлаулана төшә. Әмма сезгә барыбер, ирегезнең югалуын тануны сорап, судка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Аннан соң гына йортны (фатирны) мирас итеп алу мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Бу очракта ирегезнең бертуган апалары-сеңелләре, агалары-энеләре әниләренең өлешен мирас буларак таләп итәргә хокуклы. Гади генә итеп әйткәндә, йортның (фатирның) һәм башка милекнең өчтән бер өлеше ирегезнең әнисенә тиеш дип карарга була. Менә шушы өлешне бүлешә алалар да инде. Әмма бу очракта әбинең мирасында сезнең балагызның да (әбинең бертуган оныгы булса гына) өлеше бар.

Мәсьәләнең тагын бер четерекле ягы бар. Сез фатир белән озак вакытлар файдалана алмагансыз. Билгеле, фатир өчен түләми дә йөргәнсездер. Шул сәбәпле, сез моны үз гаебегез белән түгел, ә ирегезнең туганнары каршылыгы нәтиҗәсендә булганлыгын шаһитләр белән дәлилләргә тиешсез.

Сәйдәшевләр шәҗәрәсе

Мине сөекле композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең фамилиясе кызыксындыра. Мин озак еллар Татарстанда яшәдем, күп кенә районнарда булганым бар, ләкин Сәйдәшев фамилияле кешеләрне очратмадым. Соңгы елларда Пермь өлкәсендә яшим. Бу якларның Барда районында Тау дигән бер авыл бар. Шунда яшәүчеләрнең яртысы диярлек Сәйдәшев фамилиясен йөртә. Мине шушы фамилиянең биредә ничек килеп чыгуы кызыксындыра. Шуңа бәйле рәвештә сезгә мөрәҗәгать итәсем килә: Салих Сәйдәшевнең, этисенең, бабаларының кайда туып-үскәннәрен, исемнәрен беләсем килә. "Мәдәни җомга" аша мине кызыксындырган сорауларга җавап бирә алмассызмы?

Рәйсә ИЖГУЗИНА.
Пермь өлкәсе,
Барда авылы.

Әлеге хатка җавап итеп без "Салих Сайдашев. Детство и юность композитора" дигән китаптан өзек тәкъдим итәбез. Бу китапның авторы – Дилбәр Саинова-Әхмәрова.

С.Сәйдәшев 1900 елның 3 декабрендә Казанда, хәзерге Нариман урамының 101 нче йортында туган. Ул этисе Бикчәнтәй улы Җамалетдин Сәйдәшев үлгәннән соң дөньяга килә. Сәйдәшевләрнең ишле шәҗәрәсе крәстиән катлавына барып тоташа. Салих Сәйдәшевнең бабасы Бикчәнтәй хәзерге Биектау районының Өбрә авылында хәлле крәстиәннәрдән исәпләнгән. Аның, заман үлчәвеннән чыгып караганда, хуҗалыгы төзек була. Сәйдәшевнең туганнан-туган сеңелесе Сәгадәт Идрисованың сүзләре буенча бабасының тарантаслы аты, сыеры, зур гына умарталыгы һәм ул елларда крәстиәннең тормыш дәрәҗәсен билгеләүче башка күп әйберләре булган.

Бикчәнтәйнең дүрт улы була. Бикмөхәммәт, Мөхәммәди, Җамалетдин һәм Сабирҗан. Авылда хуҗалыкта этисе белән өлкән улы Бикмөхәммәт кенә кала. Бабай калган улларын шәһәргә җибәрә. Бу, С.Сәйдәшевнең туганнарының әйтүенә караганда, элек-электән Өбрә авылында имана җирләре зур булмаганлыктан шулай эшләнә. Салих Сәйдәшевнең бабасы, алдан күрә торган хуҗа булгандыр һәм андый җирләрдә зур хуҗалык булдыру мөмкин түгеллеген аңлагандыр.

Авылдан беренче булып Бикчәнтәй бабайның улы Мөхәммәди китә һәм бер байга өйрәнчек булып керә. Эше бик тиз алга китә һәм тиздән этисе ярдәме белән үз эшен ачып җибәрә, бик иртә үлә. Аның мирасын ул вакытта әле балигъ булып өлгермәгән улы һәм уртак эшне алып баруны үз кулына алган абыйсы Сабирҗан бүлешәләр. Соңрак алар икесе дә ул вакыттагы җәмгыяти баскычта бай булып исәпләнәләр.

Аннары шәһәргә булачак композитор Салих Сәйдәшевнең этисе Җамалетдин күчеп килә. Ул шулай ук аяк киемнәре (итек, кәвеш) тегү артелендә ялланып эшли башлый, соңрак сәүдә эшен башлап җибәрә. Бик яшьли бер бай кызына өйләнә. Әмма тормышлары ни сәбәпледер барып чыкмый һәм алар аерылышалар. Бу никахтан туган бердәнбер бала – Галимҗан әнисе гаиләсендә үсә. Ул бик иртә шәраб белән дуслаша. Күрәсең, тынычсыз холыклы булгандыр, берничә тапкыр өйләнә. Әмма бу никахларның берсеннән дә балалар булмый. Галимҗан 1931 елда Казанда үлә.

Җамалетдин икенче тапкыр Дары бистәсендә яшәүче Миңнебай кызы Мәхүбҗамалга өйләнә. Миңнебай үзе Битаман авылыннан (Биектау районы) була, шуннан солдатка алына. Патша армиясендә 20 ел хезмәт итеп туган ягына әйләнеп кайта. Әмма патша күрсәтмәсе буенча аңа туган авылында яшәргә рөхсәт итмиләр, ә дары заводы төзелешенә китәргә әйтәләр. Күчеп килүчеләр, делянкалар алгач, урман кисеп, йортлар салалар. Шулай итеп Казанның борынгы бистәләренең берсе – Дары бистәсе барлыкка килә. Миңнебай яшь кызга өйләнә. Ул дүрт бала (шул исәптән композиторның әнисе Мәхүбҗамалны да) таба һәм бик яшьли үлеп китә.

Композиторның әнисе Мәхүбҗамал, аның туганнарының, белешләренең сөйләвенә караганда, бик мәрхәмәтле, йомшак холыклы, ягымлы, матур була.

Җамалетдин аның белән озак яшәгән, күрәсең, тормышы бәхетле булгандыр. Әмма Җамалетдин салкын тиеп авырып китә һәм 10 нчы улы Салих туарга берничә атна калгач үлә. Бу балаларның күбесе яшьли гүр иясе була, Әминә һәм Салих кына исән калалар.

Барда районындагы Сәйдәшевләргә килгәндә исә аларның, китапның авторы Дилбәр ханым Саинова-Әхмәрованың әйтүенә караганда, композиторның нәселе белән бәйләнеше булу ихтималы юк.

"Шәһри Чаллы" – Чистайда

Кыйммәтчелек заманы, дип тормыйбыз – концертларга бик теләп йөрибез. Менә күптән түгел Чаллы шәһәреннән "Шәһри Чаллы" исемле иҗат төркеме Чистаебызга килде. Алар белән тәүге очрашуыбыз бик күңелле узды.

Азнакай районының Камышлы Күл авылыннан чыгып, "Татар җыры – 93", "Дуслык җыры – 94" (Нефтекама), "Чаллы былбылы", "Урал моңы" (Уфа) җыр бәйгеләрендә лауреат булган җырчы Равил Галиев чыгышын чистайлылар да кайнар алкышларга күмде.

Икенче җырчы, Резидә Шәрәфиева – җөмһүриятебезнең яшь эстрада йолдызы, тамашачыга шактый таныш, аның һәр чыгышы кечкенә генә спектакль кук.

Җырчыларга музыкант Фәнис Шакиров ярдәм итте, баянда, синтезаторда менә дигән итеп уйнады. Фәнис үзе көйләр дә яза икән. Рахмай Хисмәтуллин шигыренә язылган җырны Резидә һәм Равил башкаруында бик яратып тыңладык.

Нәфис сүз остасы Илдус Ризван исә шушы төркемне үзе оештырган һәм иң әүвәл аны Чистайга алып килгән. Ә бу юкка түгел, чөнки Илдус безнең якташ. Ул Татар Ялтанында үскән егет.

Гомумән, концерт бик уңышлы үтте. Һәр чыгыш кайнар алкышларга күмелде.

Саимә ГАТИНА.
Чистай шәһәре.

"Бизәкләр"нең бизәге

Яңа ел шау-шуы тынарга да өлгермәде, Кылачы авылы клубында янә ыгы-зыгы. Авыл үзешчәннәре "Авылым бизәкләре" дип исемләнгән тамаша күрсәтергә әзерләнәләр: сәхнә түрендә милли киемнәр кигән кызлар бию кабатлыйлар, бер егет баянга кушылып җыр суза, бер төркем яшьләр скетчның декорациясе турында киңәшәләр...

Ә шушыларның барысына да уртак киңәшче – авылның мәдәният учагын һәрчак сүндерми тергезеп торучы Илсөя Мөхәммәтвәлиева. Илсөя дистә елдан артык шушы эштә. Урта мәктәпне тәмамлагач эшли башлаган иде. Алабуга мәдәният училищесын да тәмамлады.

Илсөя гаиләсендә дә күпләргә үрнәк. Күптән түгел Ире Илфат белән бергәләп яңа йорт салып чыктылар. Өч малай үстерәләр. Игезәк уллары Илфар белән Илназ киләсе елда мәктәпкә баралар.

Илсөя апа мәктәп укучылары белән дә элемтәне югалтмый, яшьләр белән аралаша, уртак тел табып аларны суытмый. Менә монда инде аның кеше белән аралаша, уртак тел таба белү осталыгы да күренә.

Соңрак алар, югары классларда укыганда да, эшли башлагач та үзешчән сәнгать буенча төрле конкурсларда катнашып, призлы урыннар да яулыйлар. Илсөя апа баянда бик матур уйный, ул – нәфис сүз остасы да. "Авылым бизәкләре" дип аталган концертта Илсөя апа авылдашларына яңа ягы белән ачылды: үзе шигырь язган, үзе үк аны көйгә дә салган һәм үзе үк башкарып та күрсәтте. "Перспективасыз" тамгасы белән күп кенә авыллар юкка чыккан чорда Кылачы авылының сакланып калуында, бүгенге көндә үсеш чоры кичерүендә шушындый фидакарь затларның өлеше зур, әлбәттә.

Данис ХӘМИДУЛЛИН.
Арча районы,
Урта Аты авылы.

"Мин кирәкле кеше"

Әзәл абый Яһудин концертлар куеп авылларда бик еш йөри иде. Безнең күрше авылларны йөреп чыккач, бер көнне Шәмәрдән эшчеләр бистәсендәге Тимер юлчылар клубында чыгыш ясады. Бу 1950 ел башларында булгандыр. Мин мәктәптә укый идем әле. Безнең билет алырга акча юк. Шуңа күрә клубка кача-поса кердек тә утырырга буш урын булмагач, сәхнә алдына идәнгә сузылып яттык.

Әзәл абый гармунда шулкадәр сыздырып уйнады ки, без аны шаккатып, авыз ачып тыңладык. Бу – чын гармунчының уйнавын беренче ишетүебез иде. Үзе уйный, үзе такмаклар әйтә. Мондый шаяртуы истә калган: "Минем фамилиям – Яһудин. Урысча – Ягодин була. Тагын татарчага тәрҗемә итсәң, "мин кирәкле кеше" булып чыгам. Аның шулай сүз уйнатуларын кешеләр яратып тыңладылар, көлештеләр һәм озаклап кул чаптылар. ул үзенең кечкенә буе турында да нәрсәдер әйткән иде, анысы хәтердә калмаган.

Әзәл абыйның тагын берничә концертында булу бәхетенә ирештем. 1972 елның декабрендә язучыларның Г.Тукай клубында аның юбилей кичәсе уздырылды. Ул анда М.Җәлилнең "Хат ташучы", С.Хәкимнең "Кырыгынчы бүлмә" поэмаларын, С.Кудаш, Ә.Ерикәй, Ә.Исхак, Р.Фәйзуллин, М.Хөсәен, Ш.Галиев шигырьләрен, мәсәлләр, халык мәзәкләрен укыды. Кайбер шигырьләрне һәм җырларны үзе гармунда уйнап башкарды.

Әйе, татар эстрадасын үстерүгә биниһая өлеш керткән артист иде ул Әзәл Яһудин.

Бер нәрсә үкенечле калды – олы яшьтә һәм күп хезмәт күрсәткән булуына карамастан, ул безнең арабыздан Татарстанның халык артисты була алмыйча китеп барды. Ә андыйлар бездә байтак әле. Бу данлы исемне Флера Сөләйманова, Галия Гафиятуллина, Җәвәһирә Сәләхова, Фәгыйлә Тимерова, Сөләйман Йосыпов кебек гомерләрен сәнгатькә багышлаган артистларга күптән бирергә вакыт.

Ренат ГАЛӘВИН.
Казан.

Дини саташу фаҗигасе

Кайчакта җан тетрәткеч фаҗигаләр фатирларның ябык ишекләре артында – гаилә эчендә була. Шундый фаҗига Казанның Мәскәү районындагы бер фатирда булды. 40 яшьлек хатын кызы белән бергә үзенең яшүсмер улын буып үтерде. Бер-ике көннән, вөҗдан газабы кичергән 17 яшьлек кыз үз-үзенә кул салырга ниятләп 6 нчы каттагы фатирлары балконыннан түбәнгә ташлана. Тикшерү-оператив төркеме бу бәхетсез балаларның әнисен кулга алды. Беренче тикшерү мәгълүматларына караганда, фаҗига дини җирлектә булган саташулар нәтиҗәсе.

Уенчык урынына май

Казан уенчык фабрикасы эшчеләренә 1 февральдән яңадан эш урыннарына чыгарга чакырып язылган открыткалар килде. Элек йомшак уенчыклар – этләр, чебурашкалар ясаган кешеләр хәзер майлау материалларын махсус савытларга тутыра торган Португалия линияләрендә эшләячәкләр, чөнки фабрика "Шелл" маркалы мотор мае җитештерү турында килешү төзеде. Моннан соң Татарстан автомобиль йөртүчеләре мотор маена рәхәтләнәчәк.

Ә менә Татарстан балалары уенчыкларга интегәчәк, чөнки фабрикада аларны җитештерү өчен эшче куллар да, җитештерү мәйданнары да калмый.

("КП").

Сәяси әләк үзәге

Казанда Татарстан Хөкүмәте тарафыннан 5 ел элек төзелгән Социаль проблемалар үзәге белән бөйле низаг килеп чыкты. "Эфир" телекомпаниясе хәбәрчеләре югары эш хакы алучы 116 хезмәткәрдән торган шушы үзәкнең, социаль проблемаларны тикшерү белән бергә, җирле матбугат чараларында чыккан мәгълүматларны сәяси яктан цензуралау вазифасын үтәвен раслаган документлар таптылар. Республика Президенты һәм аның аппараты өчен көн саен махсус үткәрелә торган контент-анализлар, телекомпания хәбәрчеләре раславы буенча, сәяси әләк рухында әзерләнә. Бу Үзәк гаммәви матбугат чараларында республика хакимияте адресына карата хәтта мактау сүзләренә тәреп әйтелгән тәнкыйтьне дә "югарыга" җиткереп баралар.

("НГ").

Төлке сарык абзарында

Балык Бистәсе районы Колга авылында бер шәхси хуҗалыкның сарык абзарына котырган төлке кереп, биш сарыкны тешләгән. Абзардагы шаушуны ишетеп, хуҗа килеп җиткән һәм таяк белән сугып төлкене миңрәүләткән. Авыл ветеринарына сарыкларга котыру авыруына каршы вакцина белән укол кадарга туры килгән. Мондый хәл Татарстанда беренче тапкыр гына түгел: инде биш шундый очрак теркәлгән. Болары Теләче һәм Саба районнарында булган.

Чит ил "пистолет"ына кызыкмагыз!

Казан күз табиблары соңгы вакытта борчуга төште: пластик ядрә белән ата торган кытай уенчык пистолетлары шактый балаларга бәла-каза китерде. Шул уенчыклардан күз ярасы алган балалар күбәеп китте, күзгә зыян килү 2,5 мәртәбәгә артты. Табиблар яраланган балаларның күзләрен дәвалау өчен кулларыннан килгәннең барын да эшли, ләкин, кызганычка, күп очракта һәр өченче бала сукырая. Шәһәрдә уннарча малайлар күрү бәхетеннән мәхрүм калды инде. Чөнки карап торуга кечкенә генә ядрә күзгә тию белән күз челтәренә кан савуга сәбәп була. Әти-әниләр, балаларга мондый пистолетлар белән уйнауның куркыныч булуын онытмагыз.

Әби белән бабай ни бүлешә?

Дәрвишләр бистәсендә дә шундый бер фаҗига булды. Анда алты дистәне ваклаган карт белән карчык, бик ямьсез исерешкәч, үзара мөнәсәбәтләрне ачыкларга керешәләр. Фикер каршылыклары аркасында тавыш зурга китә. Карт кухня пычагын алып карчыгына ташлана, аны берничә җирдән яралый. Кан күреп, бераз күзеннән пәрдә күтәрелгәч, карчыгын коткару исәбенә керешеп, "Ашыгыч ярдәм" машинасы чакыра. Табиблар милициягә хәбәр итә. Нәтиҗәдә карт "кутузка"га, карчык – хастаханәгә озатыла.

("КВ").

Бандитлар белән үзең көрәш

Казан эшкуары Дмитрий Бердников сүзләренчә, ул җитәкли торган "Җинаятьчелек һәм законсызлыкка каршы" хәрәкәт башкалабызда табигый рәвештә оешкан. 1992 елда яшь эшкуар "Гратис" фирмасын төзегән иде. Криминаль структураларга "ясак" түләмәгән өчен Бердниковны берничә тапкыр кыйнап ташладылар, милициягә биргән гаризалары нәтиҗәсез кала бирде. Хәтта, киресенчә, 1995 елда аның үзенә суд эше ачтылар. Янәсе, суд тикшерүе барганда ярдәм итүдән баш тарткан. Аны башта 30 тәүлеккә утырттылар, аннан туп-туры "юләрләр йорты"на озаттылар. Мондагы табиблар (заманнар үзгәрде!) аны саусәламәт дип хастаханәдән чыгардылар. Бу җинаять һәм башбаштаклык өчен хокук саклау органнарында беркем дә җаваплылыкка тартылмады, фирма чыгымнарын каплаучы да табылмады.

Ләкин эш моның белән генә бетмәде. Хастаханәдән чыгуына берничә көн үтүгә үк, "Гратис" фирмасына баштанаяк коралланган сигез әзмәвер килеп керде. Бердниковны хезмәткәрләре алдында кыйнап, офисны тар-мар итеп киттеләр. Бу инде сабырлыкның чиге иде. Бердников милиция чакырды, ләкин иң элек телевидениегә шалтыратты. Сюжет телеэкранда күрсәтелде. Икенче көнне эшмәкәр янына шундый ук һөҗүм кичергән кешеләр килә башлады. Һәм Бердников катгый карарга килде: әгәр бандитлар белән милиция бергәләп эш итә икән, аларның корбаннары да (алар шактый!) берләшеп көрәшергә тиеш. "Җинаятьчелеккә һәм законсызлыкка каршы" хәрәкәтенә шулай нигез салынды. Эшмәкәрләргә хокук саклаучылар да ярдәмгә килде. Хәзер бу оешма көчәеп килә. Аңа теләгән һәр кеше керә ала. Бүген аның берничә бүлекчәсе бар, алар хәтта Мәскәүдә дә бүлек ачтылар. Русиянең төрле шәһәрләрендә бу оешмага 100дән артык эшмәкәр язылды.

("ЛГ").

Күлләрдә дә кеше язмышлары

Элек табигатьнең гүзәл һәйкәле булган Лаеш күле табигать сөючеләр игътибарыннан читтә кала килде. Монда машина юарга теләүчеләр килде, һәм чүп түгүче машиналар йөкләрен аударып китkәләделәр. Авыл Советы күлгә кул селтәде, мохитне саклау хезмәте инспекторларының да бер 20 ел күл янына аяк басканнары булмады.

Күлнең гомере шулай өзелгән дә булыр иде... әгәр күл янында Татарстан Президенты үзенә коттедж салырга уйламаган булса... Көн аралаш күлнең чисталыгын тикшерә башладылар, табигатьне саклау хезмәте әһелләре, санэпидстанция хезмәткәрләре күлнең ярларын да, суын да,төбен дә тикшерделәр. Хәтта табигать һәйкәле булган бу күл язмышына багышланган киңәшмәләр дә узгалады. Шуның нәтиҗәсендә, күлнең ярлары чистартылды, күл тирәсен пычраткан гаепләләр җаваплылыкка тартылды. Димәк, күлләребез, елгаларыбыз исән-сау, чиста булсын өчен алар ярында Президент коттеджларын күбрәк төзергә кирәк. Шул чакта Кәвәл күле дә пычратылмас, Җиде күл урманына да рөхсәтсез дачалар, ат сарайлары, гаражлар салмаслар иде.

("Правда").

Бер камерада – ике милиция хезмәткәре

Идел буе эчке эшләр идарәсенең "Промышленный" бүлекчәсе өлкән оперуполномоченные Мозаффаров наркотиклар белән кулга алынды. Ул Әфганстан-Урта Азия-Татарстан маршруты белән илгә үтеп кергән озын наркочылбырның "бер бөҗрасы" булса кирәк. Әле күптән түгел 2кг опий һәм марихуана (бәясе 100 млн. – иске акчаларда) табылган "КамАЗ" туктатылган иде. Мозаффаровны шул "йөк" белән дә бәйле дип уйлыйлар. Бу милиция бүлекчәсеннән тагын бер хезмәткәр – өлкән участок милиционеры Гарифуллин да кулга алынды. Анысы миллион сум ришвәт алуда гаепләнә. Ике милиционер да бер камерада утыралар.

("ВК")



Анатолий БАБЫКИН рәсеме.

("КП").

Татар энциклопедиясе битләреннән

ӘМИНОВ Юныс Шәриф улы (1921-1982), драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1981). Иҗаты: "Сатучылар", "Тамырлар" (1961), "Язылмаган законнар" (1950), "Гөлҗәннәтнең җәннәте" (1969), "Кан кардәшләр" (1974), "Сафура бураннары" (1991) пьесалары.

ӘМИРОВ Мирсәяф Мәсалим улы (Мирсәй Әмир) (1907-1980), язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1967), Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1974). Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе (1937, 1961-1968), РСФСР Югары Советы депутаты (1967-1971). Иҗаты: "Агыйдел" повесте (1936), "Саф күңел" романы (1954-1960), "Миңлекамал" пьесасы (1944), "Тормыш җыры" (1947), "Минем хатын" (1955), "Әсәрләр"енең өч томлыгы (1986-1987), тәрҗемәләр.

ӘМИРИ Кәрим Хөсәен улы (1893-1962), шагыйрь, драматург, балалар язучысы. Иҗаты: "Казан кызы" (1924), "Печән базары" (1925), "Таң вакыты" җыентыгы (1969).

ӘМИРОВ Кәшшаф Сафиулла улы (1922-1996), драматург. Иҗаты: ""Вөҗдан өмере" (1979), "Зөлфия" (1983), "Шөгер моңнары" (1987).

ӘМИРОВ Шәүкәт Сабир улы (1947 елда туган), балалайкачы, педагог. РСФСРның атказанган артисты (1989). Бөтенсоюз һәм Бөтенрусия конкурслары лауреаты (1974, 1979). Казан консерваториясендә укыта, укыту эшләре буенча проректор (1990), профессор (1992).

ӘМИРХАН Фатих (Әмирханов Мөхәммәтфатих Мөхәммәтзариф улы) (1886-1926), мәшһүр әдип, җәмәгать эшлеклесе, Г.Тукайның якын дусты. Иҗаты: "Фәтхулла хәзрәт" (1909), "Хәят" (1911) хикәяләре, "Яшьләр" һәм "Тигезсезләр" пьесалары (1913, 1915), "Урталыкта" романы (1912), "Сәмигулла абзый" (1926), "Әсәрләр"е 4 томда (1984-86), XX гасыр башы татар тормышкөнкүрешен зур осталык белән тасвирлаган шәхес. "Әл-Ислах" гәзитен оештыручы.

ӘМИРХАННАР (19-20 йөзләр), дин, мәдәният, әдәбиятсәнгать һәм җәмәгать эшлеклеләре гаиләсе.

ӘПСӘЛӘМОВ Габдрахман Сафа улы (1911-79), язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1959). Иҗаты: "Алтын йолдыз" (1949), "Газинур" (1951), "Мәңгелек кеше" (1961), "Сүнмәс утлар" (1958), "Ак чәчәкләр" (1965), "Күк күкрәр" (1975), "Агыла болыт" (1980). Татарчага А.Гайдар, Э.Казакевич, Н.Лесков, А.Фадеев әсәрләрен тәрҗемә иткән. 1968-72 елларда "Сайланма әсәрләр"е басыла. СССР Югары Советы депутаты (1962-66).

ӘПСӘЛӘМОВ Минзакир Әпсәләм улы (1896-1981), генерал-майор, хәрби фәннәр докторы. Иранда хәрби эшләр буенча вәкил, Кавказ армиясе разведка бүлеге җитәкчесе, сугыш вакытында укчылар бригадасында, соңрак Совет Армиясе командиры.

ӘРДАШИР бине Ишгали (Чалкакый Болгари) (XIX йөз), шагыйрь. Иҗаты: "Кыяфәтнамә". "Рисаләт фи бәян кыяфәт җенсел-кисан" (Казан, 1858).

